**КАЗАН (ИДЕЛ  БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ
АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ**

**ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ ТАРИХ ФАКУЛЬТЕТЫ
ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ**



***Яшәсен татар әдәбияты,***

***Яшәсен туган тел!***

**Г. Тукай**

# КАУРЫЙ КАЛӘМ

**студентларның һәм укучыларның**

**Бөтенрәсәй (халыкара катнашу белән)**

**иҗади эшләр конкурсы**

**АЛАБУГА  2017**

*Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты (филиалы) редакция-нәшрият советы карары белән басыла*
*(беркетмә № 13, 20 март 2017 ел)*

ББК 84 (2 Р-6Т)
УДК 821.512.145
К 30

Җаваплы мөхәррир: Хәйруллина Ә.С. – филология фәннәре кандидаты, өлкән укытучы

Бәяләүчеләр: Галләмов Ф.Г. - филология фәннәре докторы, КФУның Алабуга институты профессоры;
Галиуллин Р.Р. – филология фәннәре кандидаты, Яр Чаллы педагогия университеты доценты

**РЕДКОЛЛЕГИЯ:**

Әхмәдгалиева Г.Г. – филология фәннәре кандидаты, доцент
Галләмов Ф.Г. – филология фәннәре докторы, профессор
Габидуллина Ф.И. – филология фәннәре кандидаты, доцент
Даутов Г.Ф. – филология фәннәре кандидаты, доцент
Камаева Р.Б. – филология фәннәре кандидаты, доцент
Мөхәммәтҗанова А.Х. – филология фәннәре кандидаты, доцент
Хәйруллина Ә.С. – филология фәннәре кандидаты, өлкән укытучы
Саттарова Г.Г – ассистент

КАУРЫЙ КАЛӘМ:
*Студентларның һәм укучыларның Бөтенрәсәй (халыкара катнашу белән) иҗади эшләр конкурсы материаллары.* – Алабуга: 2017. – 180 б.

Җыентыкта Татарстан, Башкортостан республикалары, Пермь крае югары һәм махсус урта уку йортлары студентларының һәм урта гомумбелем бирү мәктәпләре, татар гимназияләре укучыларының иҗади эшләре тупланып бирелде.

*(Редколлегиядән: мәкаләләрдә киткән стиль һәм хәреф хаталары өчен авторлар үзләре җаваплы).*

Казан ( Идел буе) федераль университетының
Алабуга институты, 2017

## ЯХШЫ САБАК

**(әкият)**

*Айдашев Камил, Алабуга шәһәре 4 нче гимназиянең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Фаттахова Р.М.*

Борын-борын заманда, бик матур бер урманда, яшәгән ди бер Әни-Аю. Аның Алпай исемле бик матур бер малае булган. Әни-Аю малаен бик яраткан. Аны һәрвакыт тәмле-тәмле ризыклар белән генә сыйлаган. Әнисе Алпайның тирә-юньдәгеләргә карата шәфкатьле, көчсезләргә ярдәмчел булып үсүен теләгән. Тик Алпай әнисе әйткәннәрнең берсен дә тыңламаган, үзенчә эшли торган булган. Алпай үзенең зур гәүдәле, көчле булуы белән масайган. Көчле булу тик гәүдәгә генә карый, ә инде кечкенә гәүдәлеләрдән бернинди дә файда юк дип уйлаган. Алпай йокысы туйганчы йоклаган, аннан соң көннәр буе урманда йөргән, әнисенә гел булышмаган  Алпай тырыш кырмыскалардан, уңган балкортларыннан көлгән генә.

Көннәрдән-беркөнне, урманда җиләк җыеп йөргәндә, Алпайның әнисенең күзенә чүп эләгә. Әни-Аю көч –хәл белән генә өенә кайтып керә. Алпайның кайтуына ашарга да пешерә алмый, күзе авыртуына түзә алмый ята.

Менә Алпай кайта. Әнисенең мондый хәлдә ятуын ул беренче тапкыр күрә, Алпай бик курка һәм елый башлый. Алпай шундый каты кычкырып елый, барча урман хайваннары, бөҗәкләре бу тавышны ишетеп җыелалар. Тик шунда гына Алпай үзенең әнисенә берничек тә булыша ала алмаганын, үзенең көчсезлеген аңлап ала. Тик кечкенә генә кырмыска кызы Төенчек югалып калмый. Ул тиз генә әни аюның күзенә үрмәләп менә һәм нечкә генә куллары белән күздәге чүпне ала. Әни-Аю җиңел сулап куя. Алпай да елаудан туктый. Алпай Төенчекнең бу хезмәтенә шакката, аңа рәхмәтләр укый. Аңа бик оят була. Бу хәлдән соң Алпай гел үзгәрә. Үзенең дөрес фикердә булмавын аңлый. Урмандагы һәр бөҗәккә, һәр хайванга ихтирам белән карый башлый.
Менә шулай, дусларым, файдалы эш эшләү өчен зур гәүдәле булу бик әһәмиятле түгел икән.

## ТЫЧКАН МАЛАЕ

**(әкият)**

Яшәгән ди бер Әни-Тычкан. Аның бер кечкенә Тычкан малае булган. Тычкан малаеның әле акылы да, зирәклеге дә булмаган. Алар әнисе белән икәү тыныч кына яшәгәннәр. Өй хуҗасының ишек алдында бик күп маллары булган.

Әни-Тычкан малаена урамга чыгарга кушмаган.

Менә салкын кыш үткән, ямьле яз җиткән. Әни-Тычкан өйдә булмаган. Тычкан малае ишек алдына чыгып киткән. Йорт хайваннарын күреп ул шаккаткан,“дуслар таптым!”-дип сөенгән.

Ул зур гәүдәле, дүрт аяклы, озын койрыклы, мөгезле бер хайван янына килгән. Аның белән исәнләшкән. Ә тегесе дәшмәгән, сагыз чәйнәвен дәвам иткән.

Тычкан малае ике тәпиле, бик эре кыяфәтле, матур койрыклы, төрле төстәге камзул һәм башына кызыл түбәтәй кигән икенче берәүне күреп алган. Ләкин ул да дуслашырга теләмәгән. Тычкан малае моңаеп калган.

Шунда  аның күзе рәхәтләнеп кояшта йоклап  ятучыга төшкән. Ул бик матур, йомшак йонлы, озын мыеклы булган.  И-и  сөенгән ди, Тычкан малае. Ул аны уятырга теләгән. Шунда Тычкан малаен әнисе күреп алган һәм өйләренә алып кереп киткән. Тычкан малае ни күргәннәрен әнисенә сөйләп биргән.
Әнисе аны ачуланган, ә берсе янына якын да бармаска кушкан.
Ягез әле, әйтеп карагыз: Тычкан малае кемнәрне күргән?

## МИН ИШЕТӘМ СИНЕҢ АДЫМЫҢ

*Аиткулова Фәридә, Нурлат шәһәре 3 нче урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Баһаветдинова Л.И.*

Мин ишетәм синең адымың,
Син гел яннарымда йөрисең.
Мин ишетәм синең сулышың,
Фәрештә кебек мине саклыйсың.
Мин утыргач, синңа карыйм кебек,
Һәм син мине еракларда күрәсең.
Тик нигәдер сине күрә алмыйм,
Син бик еракларда йөрисең.
Мин тоямын синең сулышың,
Син янымда, артта йөрисең.
Әллә инде фәрештә булып килеп,
Бәхетсезлектән мине саклыйсың.

* * *

Мин бәхетле булганда гына,
Күп иде шул якын дусларым.
Бернәрсәдән дә курыкмаганда гына,
Күп иде янымда туганнарым.
Ләкин кайгым белән калган чакта,
Белдем мин дусларымны – ташладылар.
Туганнарыма өметләнеп барган чакта,
Алар да бит кире кактылар.
Тик шунысын белдем:
Бәхетле булсаң гына яныңда,
Хәсрәт белән тулган вакытта,
Аның белән калырсың берүзең.

## ИССЫК-КУЛ ТУРЫНДА РИВАЯТЬ

*Алыбаева Даткайым , «Б.Н. Ельцин» исемендәге Кыргыз Рәсәй*
*Славян университеты студенты, Бишкек*

«Кыргызстанның мәрҗәне» - Ыссык –Күл турында шулай диләр бездә. Бу күл белән бәйле бик күп риваятьләр, әкиятләр иҗат иткән минем халкым. Шуларның берсе бик усал ил хуҗасының искиткеч гүзәл кызга гыйшкы турында бәян итә. Хуҗа кызны авылыннан урлап, үзенен сараена алып килергә куша, чөнки гүзәл кыз хан мәхәббәтен кире кага. Гүзәл кыз көтүче егеткә гашыйк булган була, шуңа да хан мәхәббәтен кабул итми. Көтүче егет, тылсымлы Тулпар атта килеп, сөклесен коткара.

Хан бу хакта белгәч бик ачуланып, үзенең сугышчыларын алар артыннан җибәрә. Кызны тотып, хан сарена алып киләләр. Әмма горур кыз үлемне яхшы күрә һәм бикләнгән бүлмәсенең тәрәзәсеннән аска сикерә.

Хан эшләгән явызлыгы өчен җәзасыз калмый. Бу җинаятьтән соң, бөтен хан сарае торган үзәнлекне таудан килгән чиста су басып китә. Хан сарае су астында кала. Үзәнлектә зур күл барлыкка килә.

Су астында калган корылмалар турында сөйләгәннән чыгып шуны әйтергә кирәк, Ыссык-Күл төбендә чынлап та монастырь җимерекләре бар диләр. Кем тарафыннан җимерелгән, ничек ташланган бу монастырь - белүче юк. Әмма, бу җирдә синтоизм, христиан, Будда диннәре хөкем сөргән диләр.

Халкым Ыссык–күлне  Тимер Әмир белән бәйләп тә сөйли. Риваятьләрдә, Ыссык-Күл аша узган саен бөек Тимер узенен сугышчыларына берәр таш алып салырга куша торган булган. Шулай итеп ул, суышчылар саны барланган булырга тиеш. Көнчыгыш яр буенда шуңа ошаган ташлар рәте бар. Анны халыкта Сан ташы (Санташ) дип йөртәләр.

Моннан тыш, кыргыз халкы Чыңгых хан турында бик күп, кызыклы риваятьләр иҗат иткән. Бүгенге көнгә кадәр аның кайда җирләнгәнен белүче юк. Имеш, ул үзе әйтеп калдырган буенча  Чынгыз ханны кеше күрми, белми торган җирдә җирләгәннәр.

Әлбәттә, халыкта төрле фикерләр йөри. Ә безнең аксакаллар фикеренчә, ул Ыссык-Күл яры буенда җирләнгән булырга тиеш.

Ыссык-Күл тирәсендә булганыгыз юкмы?  Чынгыз хан үзе килеп чыкмасын! Кызык, ни уйлар иде микән, заманында бөтен дөньяны калтыратып тоткан Чыңгыз хан? Хәер, бу бөтенләй икенче очрак, башка чор, гасыр.

Менә шулай, дустым! Кыргыз халкы иленә, халкына бәйле булган вакыйгаларны онытмый. Риваятьләр, әкиятләр, җырларында аларның батырлыгы турында сөйли, яшь буынга җиткерә, өйрәтә. Бар халыкларның да шундый мәрҗәннәре бар, чал гасырлар да киртә була алмый.

## МИНЕМ ШАЯН ПЕСИЕМ...

*Анисин Иван, "Советлар Союзы герое  генерал-полковник  Василий Николай улы Гордов исемендәге Минзәлә кадет мәктәп-интернаты укучысы*
*Җитәкче: Хамматова Г.Г.*

Бар безнең песи баласы,
Үзе шаян, үзе шук.
Бөтен җиргә дә менә ул,
Үрелмәгән җире юк!
Йөгереп килә, менеп китә,
Йөри мендәр өстеннән.
Нәни булса да ул үзе,
Ходай аңа көч биргән!!!
Китапларны, дәфтәрләрне
Әллә ничә актара.
Әйтерсеңлә, ул-укучы,
Янә мәктәпкә бара!?!
"Шуктуган " дип исем куштым,
Килешә аңа бигрәк.
Шундый яратам мин аны,
Андыйлар җирдә сирәк!?!

## ХӘЕРЛЕ ИРТӘ ТЕЛИМ

Мин яшимен матур, гүзәл илдә
Саф татарча яхшы сөйләшәм.
Иртә таңнан изге ният белән
Бар җиһанга бүген мин дәшәм:
Хәерле иртә, илкәем,
Хәерле иртә, әни!
Хәерле иртә, җиркәем,
Хәерле иртә, әти!
Мин бәхетле, һәркөн иртә таңнан
Атам-анам дәшә, иркәләп.

Табигать тә шуңа сөенә бит,
Әйтерсең лә язгы күбәләк.
Хәерле иртә, Ватаным,
Хәерле иртә, сабый!
Хәерле иртә, дусларым,
Хәерле иртә, җаный!
.Мин гашыйкмын, кояш нурларына,
Тыныч тормыш, матур гаиләмә.
Иртәләрнең мәңге хәерлесен
Теләп калам һәркөн галәмгә.
Хәерле иртә, илкәем,
Хәерле иртә, әни!
Хәерле иртә, җиркәем,
Хәерле иртә, әти!

## ТАТАР ТЕЛЕ-ТУГАН ТЕЛЕМ

Бик күп телләр арасыннан
Татар телен яратам.
Көннән-көн хөрмәтем арта
Туган телгә карата.
Татар телен яратам.
Әти, әни, күршеләрдә
Гел татарча сөйләшә.
Дядя Саша гынабезне
Анлыйалмый, көнләшә,
Ул гелрусча сөйләшә.
Урыслар көнләшепяши,
Белгәнгәикетелне.
Татар теле -бабам теле,
Шуңа улбиккадерле.
Ә мин бик -бик бәхетле.

## КЫШ АЙЛАРЫ

Салкын кышта тугангадыр.
Яратам кыш айларын.
Салкын, карлы бураннарын.
Җепшек, йомшак карларын.
Яңа яуган йомшак карлар
Керфегемә куналар.
Әйтерсең, мине матурлап,
Бизәмәкче булалар?!
Агачларны да иркәләп,
Бәсләргә төреп китә.
Ак шәлләрен ябындыра.
Матурлыкка ни җитә?
Тышта салкын. Ә шулай да
Күңелләр моңга тула.
Табигатьнен һәр фасылы
Үзенчә матур була.

## АЛАБУГАМ

*Ахкамеев Тимерлан, Әлмәт һөнәри көллиятенең I курс студенты*
*Җитәкче: Захарова З.Э.*

Татарстанның бер почмагы,
Була минем туган ил.
Алабуга – борынгы шәһәр,
Була минем торган җир.
Алабугам, синдә тудым,
Белем, тәрбия алдым.
Сиңа булган хисләремне,
Аңлатып бетерә алмадым.
Шәһәремнең кешеләре дә,
Бик гади һәм тырышлар.
Ачык йөзле, тәмле телле,
Зур хөрмәтле кешеләр.
Табигате искиткеч бай,
Урманнарга, кырларга.
Болыннарга, елгаларга,
Төнбоеклы күлләргә.
Шәһәремне бик яратам,
Хөрмәтлим һәм зурлыйм мин.
Табигатенең гүзәллегенә
Һич сокланып туймыйм мин.

## ТУГАН ЯГЫМ

*Әбүзәрова Гөлүзә, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Саттарова Г.Г.*

Туган ягым синдәй гүзәл
Авыллар бармы икән?
Азга гына аерылсам да,
Кайтыр көннәрне көтәм.
Челтерәп аккан чишмәләрең
Дәрт өсти күңелемә.
Авылдан читтәгеләрнең
Керсен ул төшләренә.
Биек тауларыңа менеп,
Көч алам йөрәгемә.
Сихри, саф урман һавасы
Бөркелә йөзләремә.
Туган авылы һәр кешегә
Газиз бит ул, кадерле
Туган ягын ташлап киткән
Буладыр таш бәгыръле.

## БӘХЕТ

Бәхет артыннан куабыз
Алны – артны карамый.
Бәхет өчен көрәшүдә
Хәрамләшү ярамый.

Чын бәхетнең ни икәнен
Аңлый белергә кирәк.
Әти-әни, якын дуслар,
Гаиләң булсын гел терәк.
Бәхетле булу теләген
Җимерә алмый берни.
“Мин бәхетле!” – диючеләр
Мондый хисләрне белми.
Бәхетең үз кулыңда, дип
Җырламыйлар бит юкка.
Үз бәхетеңне якларга
Кирәкле бул син утка.
Утлар-сулар кичеп тапкан
Бәхет була татлысы.
Бәх(е)тен югалтканны көтә
Сагышларның ачысы.

## ГОМЕР АГЫШЫ

*Әбүзәрова Илүзә, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Нуриева А.Р.*

Эх, гомерләр, нигә шулай кыска,
Нигә шулай бик аз буласыз?
Көтмәгәндә Кеше тормышына,
Сиздермичә нокт акуясыз.
Китеп бара кеше, исемнәре,
Йөрәкләрдә кала уелып.
Үкенәбез, нигә болай диеп,
Яшибез гел шуна боегып.
Кайтарасы иде минутларны,
Узып киткән матур мизгелне.
Йөрәгемә бик тә якын булган
Бик кадерле газиз кешене.
Уйламыйбыз бу көн турында без,
Гомеркәйнең күркен күрмибез.
Туганнарның, газиз кешеләрнең,
Хәлләрен дә хәтта белмибез.
Кирәк икән Кеше тормышының,
Мизгелләрен сөеп яшәргә.
Туганнарның, күрше-күләннәрнең,
Хәлләрен гел белеп яшәргә.

## БӘХЕТ ЭЗЛӘП

Бәхетемне эзләп юлга чыктым.
Таба алмый озак мин йөрдем.
Өмет уты сүнгән мизгелләрдә,
Якты бер нур алда мин күрдем.
Күңелемә авыр булганда да,
Алга бардым, горур атладым.
Тормыш сыный, мин сыналам дидем,
Сыналмыйча бәхет тапмадым.

Инде таптым, менә бәхет дидем,
Юк икән шул, алдан сөендем.
Мизгел генә булды бәхеткәем,
Бәхетемне бигрәк тиз җуйдым.

## АК ҺӘМ КАРА

*Әхмәдишина Алина, Стәрлетамак шәһәре, БДУның Стәрлетамак филиалы*
*4 нче курс талибәсе*
*Җитәкче: Габбасова Г.З.*

Максатыбыз безнең бу дөньяда –
Акны карадан аера белү.
Нәрсә кара соң? Нәрсә ул ак?
Тормыш юлында килә ул җавап.
Һәр яхшы, изге эш кылырга:
Ата-ананы хөрмәт итәргә,
Өлкәннәргә ярдәм кулын сузарга
Кешене ак көчләр күндерә.
Әмма бел! Яхшылык кылганда,
Булмаса ихласлык йөрәгендә,
Бер мизгел эчендә ул агы
Мөмкин карага әйләнергә.

## УКЫТУЧЫ ТУРЫНДА ШИГЫРЬ

Укытучы – ул җитди, җаваплы,
Намуслы, акыллы,
Тырыш, ягымлы,
Шәфкатьле кеше.
Ул безне укырга, уйларга,
Язарга, санарга,
Җырларга, биергә өйрәтә.
Файдалы дәресләр бирә,
Безгә яхшы үрнәк күрсәтә.
Укытучы булу – ул горурлык
Иң кирәклесе аларга – сабырлык!
Шушы ямьле октябрь көнендә
Котлы булсын бәйрәмегез,
Сөенечләр генә тормыш китерсен!
Ходай яхшы укучылар бирсен!

Барган идек урманга
Җиләк-җимеш җыярга.
Әти белән күп йөреп,
Ике кәрзин тутыра алдык.
Өйгә кайткач әни безне
Мактады да, сыйлады –
Елмаеп каршы алды.
Өйдә бераз ял иткәч,
Өй эшләрен карагач,

Дуслар мине чакыргач,
Чыктым алар янына
Рәхәтләнеп уйнарга.

## СИН

Синең зөбәрҗәт күзләр,
Оныта алмаслык йөзең.
Беренче очрашудан ук
Йөрәгемне кузгалттың.
Хәзер инде уйланам...
Ничек сиңа охшарга?
Чәчәкләр алып килимме?
Бәлки шигырь язарга?
Мәхәббәтемне аңлатырга
Ихлас хисләрем булыр...
Ә син шул хисләремнең
Тоярсыңмы сафлыгын?!

## ТУГАН ҖИРЕМ

Туган җирем! Якты кояшың,
Куе урманнарың, киң яланнарың,
Челтрәп аккан көмеш чишмәләрең -
Бары да күңелемә якын минем.
Туган җирдән ерак булганда,
Күңелем моңсулана.
Күпме генә читтә йөрсәм дә,
Туган ягым үзенә чакыра.

## САГЫШЛЫ ЯЗ

*Әхмәдуллина Ләйсән, Чирмешән районы Иске Кади урта мәктәбенең*
*11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Мортазин М. Г.*

Таң ата. Ерактагы офыкта кызарып-алланып, бар дөньяны үзенең мәхәбәт нурына күмеп, кояш чыга. Ачык тәрәзә форточкасыннан иртәнге саф һава бар бүлмәгә тулып тәнгә рәхәт өсти. Мондый иртәнге вакытта юрганга төренеп, изрәп йокларга яратам мин, ләкин бүген никтер йокым килмәде. Башка көннәрне әни уята алмыйча,арып бетә иде, мин үзем дә тормый ята идем, чөнки беренчедән үлеп йокым килсә, икенчедән әни килеп, йомшак куллары белән бит, яңак, муен турыларымны  сыпырып,кызым тор инде, мәктәпкә соңга каласың, аннары өлгермисең дигәнен көтеп ята идем. Ә бүген менә сиңа,Тансылу уянган да, уйланып ята, әллә инде имтихан алды булгангамы, әллә күңел нәрсәдер көткәнгәме, әниемнең ялкау кызы таң әтәче шикелле күзләрен, иртәнге сәгать биштә үк ачкан иде.

Шулай уйланып, тыңлап ятам,әнәәни Фәния апа белән нидер сойләшә,бар сүзләре форточка аша минем колагыма килеп эләгә.Чишмәгә барган әни,мин иртән татлы чишмә суы белән чәй эчеп китсен дип, ул шулай һәр иртәдә чишмәгә суга бара, шуннан кайтканда курше Фәния апаны очрата, ул да һәрвакыт улларын кайгыртып яши. Әнигә этисез бик авыр,юк уйламагыз безнен эти исән, ләкин ул без кечкенә чакта, абыема ун, ә мина ике яшь булганда, эш эзләргә дип чыгып киткән. Беренче вакытларын безгә һәракыт  акча жибәреп, хатлар язып торган,ә соңыннан хәбәре дә юк, үзе дә. Әниебез этинең шулай эшләвен бик авыр кичергән, ләкин моңаерга аңа жай табылмаган, янәшәсендә  ике баласы, ике киләчәге, ике канаты, без булган.

Имтиханнарымны яхшы гына тапшырып, кулыма аттестатымны алгач миннән дә бәхетле кеше юк иде бу дөньяда, шатлыгымнан әллә кайларда, күкнең жиденче катында ук йөзеп йөри идем мин. Ләкин миннән дә нык сөенгән кеше ул – әнием иде, һәрчак терәк була белде ул миңа. Чыгарылыш кичәсендә миннән дә матуррак кыз юк иде,Әлфия апам теккән ак күлмәк бигрәк килешеп тора иде үземә. Барысыда миңа соклана, мактый, тик дус кызым Нина гына, әллә нишләде, нindидер усал күз белән карый башлады. Янымда әни булуга карамастан, иптәшләрем арасында мин үземне ялгызрак хис итә идем, чөнки һәрберсенең диярлек яннарында әтиләре бар иде. Ичмасам абый да кайтмады бит дип үз эчемнән сүгә идем мин аны,каядыр эш буенча Себер якларына жибәргәннәр дип хат язган иде. Казанга китәсе көнне мин, медицина институтына укырга кереп, тулай торакка урнашкач та әтине эзләргә барасымны бик яхшы белә идем. Бу зур шәһәрдә аны ничек табармын, ул мине ничек каршылар, үз итәрме дигән сораулар мине борчымый иде,тик аның күзләренә карап ни өчен әти, ни өчен син безне шулай ташладын, безгә ярым ятим үсәргә рөхсәт бирдең дигән сорауларга гына жавап көтә идем мин. Минем сәер икәненме әни сизде сизүен, ләкин асылына төшенеп житмәде шул. Әни күрмәгәндә, стенкадагы тартма ишеген ачып,әтинен унбиш ел элек жибәргән хатыннан адресын бер бит кәгазъгә күчереп яздым да, сумкамның бер кечкенә кесәсенә салып, әни сизмәсен дип бар әйберне жыйнаклап үз халәтенә кайтарып, бернидә булмаган төсле янына чыктым.

Инде китәргә дә вакыт. Ишек алдына чыкканда Нинаның әтисе ыгы-зыгы килә, машина багажнигына нindидер әйберләр ташый иде. Карале син бу Нинаны, ничек күп әйбер жыйган да, үзе дә ташырга булышмый дядя Ромадан ташыта, ләкин әтисе бер сүз дә әйтми, ярата ул кызын, тик минем дустым гына, үз атасының кадерен белми иде. Ул бит хәтта бер күлмәкне дә ике тапкыр кими, имеш аны кешеләр күргән. Әти-әнисе бер киемне кат-кат кидермәс иде, чөнки ул аларның бердән-бер газиз балалары, аларның таянычы. Ярый күпме генә сөйләсәм дә ул минем иң якын дустым, шунын өчен дә икәү бергә бер уку йортына барырга булдык.

Нинаның апаларында бер атна торып, тәмам Казанны өйрәнеп бетердек. Хәзер инде маршрутка дигәненә дә курыкмыйча утырабыз. Бер атнадан соң мин тулай торакка урнаштым. Тулай тороктагы дус кызларым да бик яхшы булып чыктылар үзләре, икесе дә татар. Берсе – Алсу исемле, зифа гына буйлы, сөйкемле, сул як битендә кечкенә генә миңе бар иде. Икенчесе – Фәридә – бик шигъри жанлы кеше ул, ярдәмчел, гел нур сирпеп тора анын йөзе, ә үзе жырлый, жыр-моңга гашыйк, талантлы кеше ул. Шулай укый торгач, институт-тулай торак арасын таптый -таптый тәмам хәлдән тайдык без. Укулар үзе авыр да, җинел дә кебек тоела, ләкин мине гел бер сорау борчый иде, ничекләр итеп әтине табарга соң. Үзебезнең авылда яшәгәндә, хыялланып белгән шәһәр түгел иде бу Казан, чынлыкта ыгы-ыгылы, шау-шулы зур башкала.

Җомга көнне укулар өйлә вакытына тәмамланды, мин бар көчемне жыеп, үземә ышанып теге адреска бармакчы булдым. Кайгыруымнан тирләп чыккан, кайнар уч төбемдә кыршылып, юешләнеп беткән кәгазь бите тәмам үз хәрефләрен бөтенләй диярлек югалткан иде. Я ни диям инде мин ана? Кем соң мин әтигә? - дигән сораулар юл буе башымны аптырата иде.

Менә ниһаять күпме ел күрешмәгәннән соң, мин үз әтиемне күрәм, нинди бәхетле мин. Картайган микән, безнен турыда шушы еллар буе, уйлап яшәгән микән ул? Калтыраган, нечкә бармакларым звонокка курка-курка гына бастылар һәм бик тиз арада минем каршыма бер утыз яшьлек бер ханым чыгып та басты, әллә инде мине көткәннәр микән дип тә уйлап куйдым.

- Сезгә кем кирәк ? - дип сорады ул миннән.

Мин дәшми торганга курә, русчалатып :

- Вы что-то хотели ? - дип тә сорады .

- Мин, ни, Гыйльманов Рөстәмне эзләп килгән идем, ул мондамы? Монда булса чакырыгыз зинһар, анда сиңа кызың, Таңсылу, Таңсылу Гыйльманова, Рәшидә кызы килгәндиегез.

- Гафу итегез, ләкин мин бер нинди Рөстәмне белмим, бәлкем сез адресыгыз белән ялгышкансыздыр?

- Юк, менә, улица Гагарина, дом шестнадцать, квартира тридцать восемь, - дигән.

- Мин сезгә бернәрсә белән дә булыша алмыйм, гафу итегез, саубулыгыз,- дигән тавыш, янгырады да, шап итеп тимер ишек ябылды. Шул минутта минем соңгы өметем чәлпәрәмә килде. Мин подъезд ишек төбендә утыручы бер әбидән мин, әтиемнең фотосурәтен күрсәтеп, бу кешене белмисезме, бу тирәдә күргәнегез булмадымы дип сорадым һәм ул мина әтинең яңа адресын бирде .Сонгы арада сәламәтлеге дә зәгыйфьләнде аның, бик үкенеп яшәде ул, сезне сагынып диде.

Якшәмбе көнне, иртән, теге адреска барып бик начар хәбәр ишеттем мин, әтине йөрәк өянәге белән, хастаханәгә алып киткәннәр. Бер дә уйлап тормыйча мин, шунда юнәлдем. Өченче этажга менеп, өстәл артында, ак халаттан, башын монсу гына иеп, утырган шәфкать туташыннан:

- Гафу итегез, мина Гыйльманов Рөстәм кирәк иде, аның кайсы палатада ятканын әйтә алмассыз микән?-дип сорадым.

- Ә сез ана кем буласыз аңа ?- диде ул.

- Мин аның кызы Таңсылу? - дидем мин.

- Соңаргансыз шул, әтиегез унбиш минут элек кенә вафат булды, гафу итегез инде мине, сезгә шундый, кайгылы хәбәрне житкергәнем өчен.

Бу сүзләр минем йөрәгемне тетрәндерде, күңелемә сары сагыш өстәде, болай күзгә-күз күрешмичә, ничә еллар буе өзелеп көткән әтием, бер мизгел арасында бөтенләйгә югалды.

Ике көннән соң без әтиебезне, үзебезнен авыл зиратына жирләдек, матур иде бу көн, кояшлы иде, ләкин аның бер дә яме юк иде, чөнки шушы вакыт безнең иң кайгылы чагыбыз иде. Әтиебез шулай безне ташлап китсә дә, безгә ярым ятим үсү кыен булса да, без аны гафу иткән идек. Нинди генә булса да, ул безнең әти, газиз әтиебез иде. Ә әнигә, әнигә килгәндә, яраткан икән ул безнең әтиебезне, кичергән икән. Үлгәч тә бик үксеп елады ул, бик сагышланды.

Шактый вакыт үтте, көзләр жәйне, кышлар көзне алмаштырып килде, әтиебезнең кабере өстендә ялгыз каен талгын гына искән жилдә салмак кына тирбәлә иде.

## НУР ТАРАЛСЫН БӨЕК КИЕКЛЕМӘ

*Әхмәтова Әдилә, Нурлат районы Киекле авылы урта мәктәбенең 10 сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Халитова И.В.*

Кайсы яктан юллар килсәләр дә,
Очрашалар синдә, Киеклем.
Кырларыңны, урман-суларыңны
Яратам мин синең, Киеклем.

Иртәләрен изге эшкә дәшеп,
Хәерле көн теләп уяттың,
Авылга да җылы, йомшак җилләр
Синең аша исә, Киеклем.

Яхшы атлар таудга чабып менә,
Яхшы атлар юлны югалтмый.
Кире яшьлек кайтмый дисәләр дә,
Яшәрсең син мәңге, Киеклем.

Яшик әле туган җирне бизәп,
Сәлам биреп ерак дусларга.
Кояш та безгә карап елмайсын,
Нур таралсын бөек Киеклемә.

## БЕР УТЫРЫП УЙЛАР УЙЛАДЫМ...

(эссе)

*Әхмәтова Гөлгенә, Алабуга районы Иске Юраш мәктәбенең 11нче сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Гайнетдинова К.Ф.*

*Кереш*

Мин татарның тузан бөртеге кадәр бер кисәкчеге генә булсам да, халкым, илем язмышына берничек тә битараф түгелмен. Халкымның үткәне, аның ачы язмышы турында еш кына уйланам. Шушы уйлар мине газета-журнал, төрледән-төрле сериаллар, тарихи әсәрләр белән дуслаштырды; әдәбият, тарих фәннәренә игътибарымны арттырды, хыялга баетты. Минем хыялым  мәркәзебез  Казанга сәяхәт кылу иде. Ниһаять, бу хыялым да тормышка ашты. Без гаиләбез белән Казанда булып кайттык.

Бу вакыйгадан соң шактый вакыт  узды, әмма Казанда үткәргән мизгелләр хәтергә килгәндә, җанымны тетрәткән эчке бер дулкынланудан айный алмыйм. Күңелдә аңлап, тоемлап бетергесез хисләр өермәсе кузгала. Кайчагында ул хис шом белән алышына, шул ук вакытта халкыма сокланам да, аның белән горурланам да.

*Юлда уйланулар*

Без юлда. Алда – Казан. Борынгы бабаларыбызның тәүге башкаласы, кайчандыр дөньяның барлык почмакларыннан килгән сәүдә  кәрваннары, ярминкәләр гөрләп торган, һөнәрчелек, кәсеп-кәсәбә, әдәбият, мәдәният шаулап чәчәк аткан җир. Күпме кыерсытылулар, эзәрлекләүләр кичергән. Шуңа да карамастан, бүгенге көндә Казаныбыз - чын тарихи шәһәр. Бу бөек шәһәргә сәяхәт кылу миңа күпме рухи азык бирәчәк.

Еллар, гасырлар, чорлар-дәверләр алышынган, әмма халкыбыз  моннан мең ел элек төзелгән борынгы башкаласын, аның тарихи урыннарын онытмый. Риваятьләр, дастаннар, күпме тарихи истәлекләр белән өртелгән бу җирләргә ел әйләнәсендә ил сукмагы өзелми. Аның тарихи, истәлекле урыннарына күпме кеше килә, күпме кеше үзенең хәтерен яңарта, күңел дөньясын баета, халык язмышы турында күпме мәгълүмат туплый, тарихын өйрәнә.

Ул гына да түгел, шушы истәлекле урыннарда йөреп, халкыбызның элек-электән килгән күпме йолалары, гореф-гадәтләре, әхлагы, мәдәнияте, сәнгате белән танышасың, аларны күңел күзе белән күзәтәсең һәм хәтер сандыгына салып куясың. Шулар хакында уйланасың да, күңелдә эчке бер горурлык хисе уяна.

Әйе, без, бүгенге яшьләр, халкыбызның ерак үткәндәге бөеклеге, аның мәгърур тарихы белән якыннан танышырга, аны белергә һәм хөрмәт итәргә тиешбез. Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк.

Менә шундый уйлар белән без мәркәзебезгә килеп кердек. Туганнар безне якты йөз, ачык чырай, сый-хөрмәт белән каршы алдылар. Шундый күңел күтәренкелеге кайтып киткәнчегә хәтле дәвам итте.

*Рухи яктан баю*

Таң атты. Көн матур, кояшлы булырга охшаган. Эчкә җылы йөгерде. Көньяк тарафтан талгын гына җил исә. Алдан уйлаганча, без иртәнге якта ук Казан буйлап сәяхәткә чыктык. Казанның матурлыгы безне таң калдырды, әйтерсең ул бәйрәм күлмәге кигән. Ямь-яшел чиксез урамнарга ак, кызыл, зәңгәр, сары төстәге биниһая зур чәчәкләр сипкәннәрмени.

Күңелдә шатлык хисе катыш дулкынлану. Иң элек без Сөембикә манарасы, аннан Кол Шәриф мәчетенә кердек. Иң таң калдырганы Кол Шәриф мәчете булды. Анда зәвык белән эшләнгән, күз явын алырдай бәллүр люстралар, чын хакыйкатьне сөйли торган тарихи истәлекләр безне өнсез калдырды. Бу хатирәләр минем күңел җепләрен Кол Шәриф яшәгән

Казан ханлыгы чоры белән тоташтырды. Халкымның ачы язмышы, Явыз Иванның кылган вәхшилекләре бер-бер артлы күз алдымнан узды. Камай морза кебек хыянәтчеләр булу минем күңелемне әрнетә. Андый кешеләрнең бүгенге көндә дә булуы бөтенләй йөрәгемне ярсыта.

Сәяхәтебезне дәвам иттек. Безне данлы һәм шәүкәтле Казан шәһәренең Ирек мәйданындагы һәйкәл каршы алды. Һәйкәлгә карап, Тукай турында уйланасың... 27 ел гомер... Җирдә бары 27 ел гына яшәп, 8 ел гына иҗат итеп, шундый зур мирас калдыру өчен гадәти кеше генә булу җитәме икән?! Юктыр, мөгаен. Әгәр дә без Г. Тукайның тормыш юлын тагын бер мәртәбә күз алдыннан кичерсәк, аның, чыннан да, гадәти генә кеше булмавына инанырбыз. Аның иҗаты, иҗаты гына да түгел, тулы тормышы – зур батырлык.

Тукай - һәр буын тарафыннан хөрмәт ителәчәк шагыйрь. Ул сине туган көнеңнән алып гомереңнең ахырына кадәр озата бара...

Менә шундый уйлар белән кайттым мин мәркәзебез Казаннан.

*Безнең бурыч-чын кеше булу*

Әйе, без бүгенге көндә үзгәрешләр заманында яшибез, тормыш дулкыннары вакыйгаларның төрлесенә илтеп ташлавы ихтимал. Җиңә алмаслык көчле ташкыннар да очрарга мөмкин юлыбызда. Кем булуга карамастан, укучымы, эшчеме, олымы, кечеме, телисеңме, теләмисеңме син иң элек заман агышына иярергә тиеш буласың. Ләкин ничек кенә булмасын, адәм баласының үз фикере, үз максаты, тормышта авырлыкларны җиңәрдәй идеалы, иманы булырга тиеш. Ансыз яшәү мөмкин түгел. Кешене дә, җәмгыятьне дә шул яшәтә кебек миңа. Тарихыбыз кешелек ата-бабаларыбыз рухы белән бәйләп торган телебезне, гореф-гадәтләребезне бүгенге көннәргә хәтле китереп җиткергән. Без шуны аңларга, истә тотарга, Чын Кеше булырга тиешбез.

## МИН ЯРАТАМ СИНЕ, ТАТАР ТЕЛЕМ!

*Әюпова Регина, Стәрлетамак шәһәре БДУның Стәрлетамак филиалының*
*5 нче курс студенты*
*Җитәкче: Габбасова Г. З.*

Мин яратам сине, татар телем,
Саф булганың өчен яратам!
Әдәбият елы уңаеннан
Сиңа да сүзләр яңг(ы)ратам!

Мин яратам сине, татар телем,
Җырлы булганың өчен яратам!
Кайгысын да, шатлыгын да халкым
Җырга салып, күң(е)лен юаткан.

Мин яратам сине, газиз телем,
Моңлы булганың өчен яратам!
Бишек җыры аша анам теле
Йөрәгемә сеңгән бала чактан.

Мин яратам сине, туган телем,
Син булганага, бай бит күңелем.
Өмет-ышанычым һәм киләчәгем
Белән, хыял гына түгелен.

Мин яратам сине, татар телем,
Бар булганың өчен яратам!
Әдәбият елы уңаеннан
Сиңа дан сүзләре яңг(ы)ратам.

## СӘНГАТЬ, ӘДӘБИЯТ, МӘДӘНИЯТ...

Сәнгать, әдәбият, мәдәният...
Җырга мохтаҗ түгел яшәгәндә.
Инсафлы тел җирендә яшәгәндә,
Моңга сусап үтмәс гомерләр.
Мәдәният, сәнгать, әдәбият –
Шәҗәрәм, бар гореф-гадәт тә.
Бабам мирасына тугры калу
Кечкенәдән кергән гадәткә.
Әдәбият, сәнгать, мәдәният –
Тел байлыгы – милләт берлеге.
Чәчкән орлык шытып чыксын өчен
Уңдырышлы булсын җирлеге.

## 9 МАЙ – ҖИҢҮ КӨНЕ!

Ашыга-ашыга ак болытлар йөзә
Иңләп-буйлап зәңгәр күкләрне,
Искитмәле дөнья, болытларның
Аккошларга охшаш йөзүләре.

Яз сулышы җиргә кабынуга,
Кошлар кайта туган якларга.
Ничә еллар ана көтә: Улы
Киткән иде илен сакларга...

Авыр сугыш елларының эзе
Маңгаеннан сырлап үткәннәр.
Өчпочмаклы кайгы хатлары да
Таушалыпып беткәннәр.

Күк йөзе дә зәңгәр, тик җанына
Ана һич табалмый дәвалар.
Үзәкләрен өзә, кайталмыйча
Яуда башын салган балалар.

Язлар – күркәм, язлар – өметлеләр
70 нче Җиңү язларым.
Ак болытка охшап аккош оча
Туган якны ямьләп, назланып.

70 нче Җиңү! Җиңү язы
Шатландыра бүген күпләрне.
Ашыга-ашыга ак болытлар йөзә
Иңләп-буйлап зәңгәр күкләрне.

## ИШЕТТЕҢМЕ МИНЕ? /HAVE YOU HEARD ME?
**(Тәрҗемә)**

*Большакова Вероника, Яр Чаллы шәһәре7нче урта мәктәбе*
*Җитәкче: Камаева Р.Р.*

Әнием җырчы иде. Бик еш кына кичләрен өйдә ялгызымны калдыра иде ул. Шулай бервакыт радионы ачтым да әниемнең тавышын ишеттем. Ул моңсу гына җырлый иде. Миңа бик тә ямансу булып китте. Күземә яшь тыгылды. Түзмәдем, радиога капландым:

– Әни, әнием, тизрәк кайт инде өйгә-ә...

Җыр тәмамланды. Яшьләремне сөртергә дә өлгермәдем – ишек ачылып китте. Бусагада әнием басып тора.

– Шундый тиз кайтып җиттең! – дип куандым мин. – Чакыруымны ишеттеңме, әнием?!

Радиода тавыш язмалары булуын да, радионың телефон кебек эшли алмавын да белми идем шул әле ул чакта. *(Әхәт Мушинский)*

My mother was a singer and she often left me home alone in the evenings. One day I turned on the radio and heard her voice. She sang a sad song. I got so lonely that I spoke into the speaker with tears in my eyes:

Mommy, come quickly…

–The song was over. I had no time to wipe tears, the door opened – the mother stood on the threshold.

– How did you here so fast! – I was glad. – Have you heard me?

At that time I didn't know that there is a record on the radio and that radio couldn't work as the phone.

## КОЙМА ЯНЫНДА / AT THE FENCE

Ул кыз миннән биш-алты яшькә зуррак иде бугай. Мәктәпкә дә йөрми идем әле ул чакта.

Һәркөн саен койма янында очраша идек без. Мин бер якта, ул икенче якта. Сәгатьләр буе басып тора идек шулай. Ул кычкырып китап укый, мин тыңлыйм.

Белми идем мин аны. Ул да мине белмәгәндер. Тавышыннан гына таный идем. Ә ул тыңлаганымны тоя иде бугай.

Көннәрдән беркөнне коймага тишек тиштем.

Ул көнне нәрсә укыганын хәтерләмим. Озын керфекле зур күзләре, изүендәге сары брошь-күбәләге һаман да күз алдымда.

The girl was five years older than me. And I didn't still go in school.

Every day we met with her at deaf fence, separating our yards. I was on the one hand, and she was the other hand.

We stood for hours together. She read the book aloud and I listened to her.

We didn't know each other. I knew only her voice, and she knew that I listened.

Then I dig the hole up in the fence.

I don't remember what she read. Just I remember: She had big eyes, covered lashes, and big butterfly – brooch on the breast.

## НӘРСӘ БИК КИРӘК?

*Буланова Анастасия, Түбән Кама муниципаль районы Югары Чаллы урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Хәйретдинова Р.Җ.*

Борын-борын заманда яшәгән ди бер хуҗалыкта йорт хайваннары һәм йорт кошлары. Бу хуҗалыкта нинди генә хайваннар, кошлар булмаган ди: әтәч, тавык, сарык, дуңгыз, сыер, ат, эт һәм мәче. Бу хуҗалыкта ат кешнәгән, йөк ташышкан. Сыер көтүгә йөргән, күп итеп сөт биргән. Сарык иртән көтүгә чыгып киткән, кич бәкелдәп кайткан. Дуңгыз да хуҗа биргән ризыкны ашаган, сазлыгына кереп су коенган. Тавык бодай ашый, җырлап йомырка сала икән. Әтәч иртән иртүк тора, көр тавышы белән хуҗаны йокыдан уята. Мондагы хайваннар башкалардан бернәрсә белән дә аерылмаганнар, тыныч кына, үз көйләренә яшәп ятканнар.

Көннәрдән бер көнне алар арасында бәхәс чыккан. Кошлар һәм хайваннар үзләреннән канәгать түгел икән. Алар үзләрен өстен куя башлаганнар. Сыер: “Мин кешегә сөт бирәм. Кеше сөт эчмәсә, көче булмас иде. Ул эш эшли, сезгә азык таба алмас иде. Бу хуҗалыкта мин иң кирәкле хайван”, – дигән. Хуҗалыкта мин булмасам, сезгә бик кыен булыр иде, чөнки кеше әзерләгән азык - төлекне нәрсә ташый. Мин булмасам, ачка үләсез дип сүзгә кушылган ат. Ә сарык: “Кеше минем йонымнан җылы киемнәр бәйли. Ә кыш көне ул киемнәр булмаса, кеше авырый. Мин аны салкыннан саклаучы, киендерүче хайван. Шулай булгач, мин бик кирәк”. Тавык та үз чиратында сүзгә кушылган: “Мин аз ашыйм, шуңа карамастан, көндә йомырка салам, файда китерәм. Йомыркасыз кеше бернәрсә дә пешерә алмый. Мин иң кирәкле, кадерле кош”. Ә дуңгыз мыркылдап бәхәсне куерткан: “Монда үзегезне генә мактап тормагыз, мин дә хуҗалыкта кирәк, чөнки мин ит бирәм. Ә ит иң кыйммәтле азык ул, сезнең сөтегез, йомыркагыз бер читтә торсын”. Мәче: “Мин дә бик кирәк. Мин булмасам, күсе - тычканнар бу хуҗалыкны басып киткән булырлар иде”. Эт тә алардан калышмыйча: “Әлбәттә, мин иң кирәклесе. Хуҗалыкны әгәр мин тугры эт сакламасам, сезне күптән караклар урлар иде. Минем аркада көн күрәсез” – дип тә өстәгән. Әтәч аларны тыңлап, азакка кадәр түзеп торган да, яңгыравыклы тавышы белән “кикрикүк” дип кычкырып җибәргән. “Миннән дә кирәклерәк һич булмас. Минем генә көчле тавышым бар. Мин хуҗаны иртүк эшкә уятам, ул сезгә ашарга бирергә чыга. Мин булмасам, ач каласыз бит”. Берсен-берсе уздырып бәхәсләшкәннән соң, китте талаш, китте сугыш. Син күр дә, мин ишет.

Ходай бу хәлне тыныч кына күреп, тыңлап торган. Бу хәлгә ул нокта куйган. Икенче көнне йокыларыннан торсалар, бу йортта көн күрүчеләр бер-берсенең гәүдәләре белән алышканнар. Сыер тавык белән, дуңгыз эт белән, әтәч сарык, ә мәче ат белән икән. Нишләргә белмиләр? Мондагы хикмәткә түз генә! Сыер тавык шикелле кыткылдый, ә тавык исә сыер кебек мөгри. Дуңгыз өрә, эт мыркылдый. Әтәч сарык кебек бәәлди, ә сарык әтәч булып кычкыра. Мәче ат кебек кешни, ә ат мияулый. Нишләргә? Шулай яши башлыйлар. Сыер тавык гәүдәсендә, дуңгыз этнекендә, әтәч сарыкныкында, ә мәче атныкында.

Алсу таң атты, сарык әтәч булып кычкырды, хуҗаны татлы йокысыннан уятты. Сарыкның “кикрикүк” дип кычкыруын күргәч, ул шаккатты. Мондый хәлне аның күргәне дә, ишеткәне дә булмады. Урамга чыгып караса, әтәч “бәәлдәп”, мәче “кешнәп”, тавык “мөгрәп” көтүгә чыгып баралар. Ә капка төбендә дуңгыз эт тавышы чыгарып өрә, койрыгын кашый, койрыгы артыннан йөгерә. Сарайга керсә, ат белән сыер көтүдән калганнар. Хуҗа, нишләргә белмичә, кич белән күз күрер дип, эшкә китә.

Йорт-курада тормыш шулай дәвам итә. Капка төбендә дуңгыз чит кешеләрне өйгә кертми, ырылдый. Тик әллә ни эш майтара алмый, өйне начар саклый. Бу эш аны туйдырды. Эт сазда коенды. Ул коенуын коенды, бу пычракны үзеннән ничек коярга белмәде. Җитмәсә, кечкенә балалар эттән эчләре катып көлделәр, эчен пошырдылар. Этнең өреп кенә ятасы килә башлый, ләкин кирегә юл юк шул. Мәче авызы белән салам ташырга маташа. Ничек

кенә тырышмасын, ат кебек булдыра алмый, арып бетә. Ат көне буе тычканны саклый, тычкан аңа койрыгын гына күрсәтә. Сарык ярма ашый, тамагы туймый. Аның сусыл үлән ашыйсы, иркендә йөрисе килә башлый. Әтәчне көтүлек, яшел чирәм туйдыра, өйдә хуҗа биргән ярма сагындыра. Сыер җим эзли. Ул, чуар тавык кебек, йомырка саласы була, әмма булдыра алмый. Кич җиткәч, тавык көтүдән кайта, тик сөте генә юк.

Хуҗа уйга кала... Аларны базарга алып барып сатарга була. Бу шомлы хәбәрне ишеткәч, кош-кортлар, хайваннар куркуга калалар. Бөтен нәрсә үз урынына кайтсын өчен, ходайдан сорыйлар, аңа ялвара башлыйлар. Ходай аларның хаталарын аңлаганнарын күреп, үз хәлләренә кайтара.

Шул көннән башлап, бу йортта яшәүче кошлар, хайваннар арасында татулык урнаша. Тормышлары көйле бара. Барысы да хуҗага тырышып хезмәт итәләр. Берсе дә үзен өстен куймый икән. Һәрнәрсә үз урынында булса, барысы өчен дә яхшы.

## ӘНИ

*Васильева Регина, Мамадыш шәһәре политехник көллиятенең 11 Т төркем укучысы*
*Җитәкче: Әхмәтшина А.Д.*

Минем әни бик әйбәт –
Яхшыданда, яхшырак.
Тәмле ашлар пешерә
Барсынада өлгерә.

Киендерә, ашата
Дәресләрдә карата.
Эшенәдә өлгерә –
Миннән алдан йөгерә.

Миндә аңа булышам –
Табак-савыт юышам.
Балаларда карашам.
Мин бит әнине бик яратам!

Әни карнында йөрткән –
Сине назлап үстергән.
Иркәләгән, ул сөйгән
Игелекле кеше бул дигән.

Күпме генә булышсак та,
Күпме генә тырышсак та –
Без әниләр алдында,
Һәрвакытта бурычта.

Әни безне кичерер,
Башларыбыздан ул сөяр.
Балабызга күз тимәсен дип
Башларыбызга тоз сибәр.

Бишек җырын тыңлап үстек –
Әнкәй, сиңа мең рәхмәт!
Аллам бирсен озын гомер
Гомереңдә бәрәкәт!

## ЯШЬЛЕК

Яшьлегем – җүләрлегем дип,
Әйтмиләр юкка гына.
Әбиләрдә булганнар бит –

Матур яшь кызлар гына.
Яшьүсмер дә булганнар
Унсигезне көткәннәр.
Басуларда эшләгәннәр,
Клубларда ял иткәннәр.
Кияүгә дә чыкканнар,
Әниләрне тапканнар,
Балаларда үскәннәр –
Оныклар бүләк иткәннәр.
Матур яшь кызларыбыз – әби булып беткәннәр.
Алар һич тә үзгәрмәгәннәр,
Картайганнар шул әбиләр –
Алар иң сөйкемле кешеләр.
Бабайларны да онытмыйк, алар турында да языйк.
Аларда булганнар бит, бик ягымлы егетләр.
Клубларда да йөргәннәр, үзләренә гашыйк иткәннәр –
Кызлар күзләп сөйгәннәр, гаилә корып җибәргәннәр.
Миндә үсеп җитәрмен -
Әни булып китәрмен.
Балаларым үсеп җитәр -
Анысын да сизмәмен.
Улларым, кызларым
Бүләк итәрләр онык.
Карармын – үстерермен
Йөрәк җылымны бирермен.
Бу әле яшьлек хыялы гына.
Әбиләр дә, бабайлар да хыялланганнардыр бу хакта.
Яшьлек бит ул бик кыска –
Уздырмыйк әле бушка.
Ходай кушса, бар да булыр
Гомер бит ул олы сәхнә –
Тап төшерми генә яшик
Җефә ак яулыкка!

## ТУГАН АВЫЛЫМ

(Фәрдия әбием истәлегенә)

*Вахитова Әлфиназ, Әлмәт дәүләт нефть институтының 46-81 төркем студенты*
*Җитәкче: Гобәйдуллина Г.Т.*

Туган авылымның намусын яклап
Килдем, дуслар, сезне күрергә:
Сезне генә түгел, авылымның ямен,
Чишмәбезнең тәмен белергә.
Авылыбыз кечкенә булса да,
Авыр көрәш юлын уздырган,
Көрәш юлын дәвам итәрдәй
Баһадир балалар тудырган.
Машинага түгел, чуманга утырып,
Гәйсә агай колхоз төзеде,
Әнә шул чор нәниләре булып

Үскән кызлар – менә без инде.
Колхозыбыз “Чишмә” исемен алды,
Бу исемдә шундый өстенлек!
Ташларыннан нигез ташы өеп,
Күпме буыннарны үстердек.
Шул буыннар рухы, көче белән
Колхозыбыз алга атлады,
“Чишмә” суы “Авангардка” кушылып,
Авылыбыз үрләр яулады.
Бу буыннар безгә яшәү дәрте –
Тормыш дәрте өсти килделәр,
Авыр еллар килгәч, каеннары
Бөдрә чәчен җиргә иделәр.
Без укырга йөрдек ялан тәпи,
Киндер күлмәк иде өсләрдә,
Язын күтәрмәдә, җәй чабата киеп
Кимсенмәде бер дә хисләр дә.
Өстә – бишмәт, киндер сумка тагып,
Бара идек кышын мәктәпкә,
Корымнан ясалган кара коста,
Каләм сынса – инде нишләргә?
Агач юнып, яңа каләм ясап,
Тик тормадык: язып утырдык,
Шулай белем алдык без тырышып –
Шунда инде безнең горурлык!
Зур тырышлык аша кеше булып,
Кырык елдан артык укыттык,
Хезмәтеңә тугры булып яшәү, –
Аннан артык юктыр горурлык!
Бу без әле, ә бит авылымның
Бик күпләре кемнәр булмады?!
Алар югарыга атлап, зур кешеләр булды,
Авылыбызга сыеп тормады...
Мин горурмын бүген әбием белән,
Барыбыз да бүген горурбыз:
Тырыш хезмәт аша авылыбызга
Ныклы терәк булып торырбыз.
Шул буыннар нәселе авылымда,
Һәр буыны – безгә истәлек,
Истәлекләр аша авылыбызны
Чәчәк кебек итеп бизәдек.
Мин дә яшим авылыбызның
Бер кисәге булып күгендә,
Авылымның табигате кочагында
Үскән өчен горур бүген дә.
Мин горурмын бүген сезнең янда
Бәйге аша серем сөйләргә,
Җирдә Тынычлыкны теләп, бу дөньяда
Бәхет диңгезендә йөзәргә.
Кайнар хисләр аша чыккан сүзем

Авылыма мәңге ямь бирсен,
Бу яшьләргә, барлык туганнарга
Мәңге сүнмәс яшәү китерсен!

## ӘНИЕМНЕҢ «ДӘҮ ӘТИ»СЕ

(Бөек Ватан сугышы ветераны, бабамның бертуган абыйсы Кәшбиев Валихан Кәшбелгаян улының якты истәлегенә багышлыйм )

*Вәгыйзова Гүзәл,Алабуга шәһәре 1 нче гимназиянең 11 сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Вәгыйзова Л.Г.*

Валихан Кәшбелгаян улы Кәшбиевнең фани дөньядан китүенә дә бу көннәрдә 30 ел була. Валихан абыйны күмәк хуҗалык рәисе буларак та, сугыш ветераны буларак та зур хөрмәткә лаек хезмәтләр калдырган олы шәхес дияр идем мин. Ләкин ни кызганыч, миңа аның үзен күрергә насыйп булмады. Сугышта алган яралары кабат кузгалып, 1997 елда, мин туганчы ук, бу якты дөнья белән саубуллашкан иде инде ул. Мин аның вафатына күп еллар узгач кына бу якты дөньяга аваз салганмын. Ул минем әниемнең «дәү әти»се, ягъни бабамның абыйсы. Әниемә ул абый тиешле булса да, әни аны бик яратканга күрә, «дәү әти» дип йөрткән.

Валихан абыйны әниемнең туган ягы Мөслим районында белмәгән кеше юктыр. Ул 17 яшендә үз теләге белән гариза язып, 1941 нче елны сугышка китә. Аңа җиде ел буе дөньяның кайсы төбәкләрендә генә булырга туры килми. Авыр чагында да туган-тумачаларга сиздермичә, дошман пулясыннан алган яраларга да бирешмичә, күкрәк тутырып медальләр тагып, исән-сау туган якларына әйләнеп кайтырга насыйп була аңа. Аннан соң ул бик күп еллар Мөслим районының Максим Горький исемендәге күмәк хуҗалыгын җитәкли. Дүрт авылны берләштергән зур колхозны җитәкләп бару, әлбәттә җиңел булмагандыр. Ләкин авылдашлары телендә әле бүген дә Валихан абыйның җор теле, аның белән булган кызыклы хәлләр турында төрле вакыйгалар искә төшерелә.

Валихан абый турында язарга әзерләнгәндә, әниемнең китапханәсенән «Ватаным Татарстан» газетасының 2003 ел 8 май 71 нче номер белән чыккан санын табып алдым. Заманча альбомга беркетелсә дә саргаеп беткән бу газет минем өчен искиткеч зур ачыш булды. Мөслимнән Әхсән Шәрипов дигән корреспондентның мәкаләсе иде ул. Мин аны үзгәртмичә нәкъ шул килеш тәкъдим итәргә булдым. Чөнки бу язма минем мәкаләмнең чынлыгын ачып бирә торган дәлил дә булып тора.

«1972 ел. Ноябрь ае төгәлләнеп килә. Районда дәүләткә йомырка сату планының үтәлеше куркыныч астында икән. Максим Горький исемендәге колхозда исә план яртылаш кына үтәлгән. Мин ул чакта районда авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сыйфат буенча баш дәүләт инспекторы булып эшли идем. Шушы мәсьәләдә колхоз рәисе Вәлихан Кәшбиев белән сөйләшәбез. Планны үтәү өчен нинди чаралар күреләчәген, нинди мөмкинлекләр барлыгын сорыйм.

– Чарасы алдан күрелгән. Ике мең баш тавык бар. Инде алты айлык булдылар. Массовый төстә йомырка сала башлаячаклар. Икенең берсе генә салса да, көнгә бер меңнән артык йомырка дигән сүз. Ел ахырына план һичшиксез үтәләчәк, – дигән ышаныч белдерде.

Ноябрь дә үтте, декабрьнең яртысы җитте. Статистика бүлеге отчетыннан күренгәнчә, бу хуҗалыктан дәүләтебезгә нибары ике меңданә йомырка сатылган. Киттем аңлашырга. Рәис бүлмәсендә шактый җитди итеп сүз башладым. Вәлихан Кәшбиевка үзенең сүзләрен исенә төшердем. Ә ул мине тыңлап торды да: "И-и, иптәш Шәрипов, тавыклар яшь бит әле, йомырка салырга куркалар", – диде. Мәрхүмкәй, ул шундый җор сүзле кеше иде. Шуннан соң аның белән ничек әрләшәсең ди инде?»

Ул рәислек иткән чорда ул җитәкләгән күмәк хуҗалыкка кергән авылларда (районда беренчеләрдән булып!) яңа клублар, магазиннар үсеп чыга. Әле әнием туган авыл Бәкәбездә

аның дәү әтисе төзеткән клуб бүгенге көндә дә гөрләп эшли. Ләкин бүгенге көн мәдәният сарайлары белән чагыштырганда ул кечкенә күренә. Ә минем әбиемнәр яшь чагында ул тирә-якта дан тоткан иң зур клуб булган. Безнең авылга Казанның үзеннән танылган артистлар - Әлфия Авзаловалар, Илһам Шакировлар бик еш килә торган булган. Хәзер бу клубка зур концертлар килми инде. Яшьләр дә бик авылда калмый. Шуңадырмы яңа мәдәният учагын тергезергә атлыгып торучылар да юк.

Халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы кеше буларак Валихан абыйның исемен гел зур хөрмәт һәм ярату хисләре белән искә алалар. Без әбиемнәргә кайткан саен авыл зиратына барабыз. Анда әниемнең бик күп туганнары ята. Минем бабам да шунда. Ә бабам кабере янында гына Валихан абый ята. Туганлык хисләрен теге дөньяда да дәвам итәргә теләгәндәй, янәшә каберләр дә мәңгелек йокыга талганнар. Калган туганнар да алардан бик еракка китмичә, якын-тирәгә сыенышканнар. Тыныч йоклагыз, кадерлеләребез. Сезнең тынычлыкны мылтык тавышлары бүлмәсен. Илләребез имин, елларыбыз тыныч, ә җаннарыгыз җәннәттә, урыннарыгыз оҗмахта булсын!

Сүз ахыры. Шушы язмамны басмага әзерләгәндә, 88 яшендә кадерле әбием дә гүр иясе булды. Ул соңгы айларда Алабуга шәһәрендә, безнең яныбызда яшәде. Әлбәттә инде язмам өчен чыганаклар әзерләүдә аның да өлеше зур булды. «Дәү әтиебез» янәшәсендә тагын бер яңа кабер калкып чыкты. Әбием - нәселебездән сугыш чорының бөтен авырлыкларын үз җилкәсендә татыган соңгы кеше иде…

## ҮЗЕҢ НӘТИҖӘ ЯСА, БАЛАМ!

(хикәя)

*Вәлеева Лиана, Алексеевск районы Чишмә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 сыйныф укучысы*

*Җитәкче: Рәхмәтуллина Р.Р.*

Азатка “Әниеңнең сүзен тыңла!”,“Әниеңә булыш!” дигән сүзләрне бик еш ишетергә туры килә. Ләкин бу сүзләр аңа бик сәер булып тоела,чөнки әнисенә сирәк булса да булыша,тыңлый бит ул. Әмма, уйнарга чыгып китеп,уйный-уйный кич җиткәнен дә сизмичә калган көннәре еш була.Әнисе һәркөнне аны эзләп алып кайта. Әле анда да дуслар янында әни белән кайтып китәргә читенсенеп,карышып тора. “Нигә эзләдең мине”,- дип кайткач үпкәсен белдерә. Әнисе: ”Үскәч аңларсың”,- дип кенә куя да, арып-талып бүлмәсенә кереп ята. Ә бит ана кеше баласына беркайчан да начарлык теләми.

Ә беркөнне дусты кич белән аланга туп тибәргә чакыра.Азат әнисенең бер йорт аша торган әбиләренә нәрсәдер сорарга кереп киткәненнән файдаланып чыгып сыза.Әмма ул чагында уенга ашыкмаган булса... Ә бит шул көнне генә әнисе: “Бүген өйдә торырсың”,- дип кисәтеп куйган иде.

Азат килгәндә, аланлыкта нигәдер беркем дә юк иде. “Бәлки,аңлап җитмәгәнмендер кайсы аланга чакырганын”,-дип уйлап,аптыраган рәвештә, юлны кыскартып, бакча аша гына чишмә янындагы аланга юл тота. Шулай ашыга-ашыга йөгереп барганда,кинәт, җир убылып аска төшеп киткән кебек тоела. Күзләрен ачканда инде, караңгы төшкән була. Капшана-капшана Азат үзенең бәрәңге базында ятканын абайлап ала. Әмма ничек кенә чыгарга талпынса да,ул аннан чыга алмый. Азатның йөрәге чыгардай булып тибә. Куркуыннан ул: “Әни!Әнием!”- дип кычкырып җибәрүен үзе дә сизмичә кала. Шулчак бөтен тирәне яктылыкка күмеп ниндидер ут күренә. “Улым, балам”,- дигән тавышлар ишетелә.Улының кайтуын көтеп-көтеп тә, түземлелеге беткән ана, ни булганын тиз аңлап, эзләргә чыккан икән. Юк, ул Азатны орышмады, тиргәмәде дә. Ә кыска итеп кенә “Үзең нәтиҗә ясa, балам”,- диде.

Шул көнне Азат: “Моннан кала әнинең сүзенә һәрвакыт колак салырга кирәк”,- дигән нәтиҗәгә килде. Юкса, мондый хәлгә тагын төшүең ихтимал...

## ТУГАН ТЕЛЕМ

(шигырь)

*Вәлиева Рузилә, Нурлат шәһәре 3 нче урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Садыйкова З.У*

Гомеремдә җыйдым гыйлем
Мөгаллимнәр бирде белем.
Күңелемә якын итеп
Алган сабак – Туган телем.
Син минем туган телем,
Син минем киләчәгем.
Тик синдә газиз туган тел,
Бәхетем, киләчәгем.
Тел булганда адашмыйбыз,
Юлым туры, нурлы көнем.
Күз карасы кебек саклыйм,
Анам телен – Татар телен.

## ВАКЫТЫНДА БИР СИН ҮГЕТНЕ

*Вәлиева Чулпан, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Әхмәдгалиева Г.Г.*

Сөеп, кулга алып йөрәк бәбкәен
“Бала, – диеп, – Ходай бүләге!”
Күрсәтсәче һәр ана да бала өчен,
Өлге булган яшәү үрнәген.
Туры юлдан тайпылмасын балаң дисәң,
Вакытында, ана, тырыш син!
Картлык көнең тыныч булсын дисәң,
Акыл биреп, аңа булыш син.
Ялгыш адымына күзең йомма,
“Минем балам, – димә, – өметле”.
Адашмаска тормыш юлларында
Вакытында бир син үгетне!

## ӘДИП

*Вәлишина Алсу, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Хәйруллина Ә.С.*

Шагыйрь ия зур бер көчкә
Икедән бер дөнья куя тудырып.
Тик башыңны күтәр, кара куккә -
Ходай биргән сәләт тутырып.
Кулга керсә каләм,
Алда торса кәгазь кисәге.
Туктап кала бөтен галәм,
Чу, әнә туа яна тормыш чәчәге.
Шулай итеп күпме әдип
Ак кәгазьдә каләм тибрәткән.
Сызып-бозып, күпме кешеләрне,
Тудырган да, кабат юк иткән.

Әдип яза, яна язмыш сыза.
Ерак булыр микән барасы…
Илһам ташый, каләм кыза,
Тик урынлы булсын ноктасы.

## АПАМА

*Вәлишина Алсу, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Миңнуллина Р.Ф.*

Күпме булса җирдә изге теләк
Мин телимен сиңа барсын да.
Тик иң мөһиме сәламәтлек кирәк-
Шуны сора, Аллаһ каршында.
Һәр туган таңга сөенеп яшә
Булдыралсаң туган хәлен белеш.
Күрше сиңа бәйрәм саен дәшә,
Син дә аның белән йөреш.
Кайгы килсә, бирешмә син.
Җиңеп чыгып була барсын да.
Хәлең авыр булса, яныңда мин,
Бергә булсак,узар барсы да.

## ЯРАТАБЫЗ БЕЗ АНЫ
**(Габдулла Тукайга багышлана)**

*Габидуллина Алсу, Мамадыш районы Түбән Сөн урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы.*
*Җит5әкчесе: Сахапова Л.И.*

Тукай килгән дөньяга.
Телебезне яратканга
Дан җырлыйбыз без аңа.
Иркәләү-наз күрмәсә дә,
Үз юлын тапкан Тукай.
Әкиятләр дөньясында
Яшәгәндер ул шулай.
Бөек шагыйрь исеме белән
Телләребез ачылды.
“Су анасы”, “Шүрәле”ләр
Йокыбызны качырды.
Тукай телен яратабыз,
Без аның шәкертләре.
Күңел түрендә саклыйбыз
Шигырь-әкиятләрен.

## ТУГАН АВЫЛЫМ

Туган авылым – газиз җирем,
Бик якын күңелемә.
Аның матур табигате
Тартып тора үзенә.
Сөяп куйган тауларында
Пешеп тора җәен җиләк.

Ә кышын чаңгы шуарга
Безгә тагын шул тау кирәк.
Челтерәп ага чишмә суы,
Җанга якын хәтфә болын,
Саф һавлы зәңгәр күгең –
Китмәсләр минем уемнан,
Тибрәндереп күңел кылым.

## ДӘҮ ӘБИЕМ КӘҖӘСЕ

Минем бар дәү әбием,
Яши ул бик еракта.
Өен, кәҗәсен сагына,
Безгә килгәч кунакка.
Ялгыз яши әбием,
Мут кәҗәсе – юаныч.
Арканда да тормый үзе,
Аның белән харап эш.
Күршеләрнең лапасларын
Урап чыга әйләнеп.
Төрле хәлләргә юлыга,
Бар нәрсәгә бәйләнеп.
Мут булса да яраттыра,
Йөри ул көязләнеп.
“Кәҗә сөте – дәва!”-диеп,
Яши әби сөенеп.

## ИГЕЗӘК МАЛАЙЛАР ЯЗМЫШЫ

*Габтенурова Гөлназ, Алабуга шәһәре 2 нче гимназиясенең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Аслямова Г.Ф.*

Бүген Галимовлар гаиләсендә зур бәйрәм – бәби туе. Бу гаиләдә көтеп алган балалар - игезәк малайлар туды. Бүген аларга исем кую ашы уздырыла. Өйдә бәйрәм хисе сизелеп тора, казанда - аш, мичтә бәлеш пешә. Өстәлләрдә нинди генә ризыклар юк! Чакырылган кунаклар да күчтәнәчләр, бүләкләр белән килгән. Барысының да йөзләрендә елмаю, телләрендә матур, изге теләкләр: “Бәхетле-тәүфикълы, сау-сәламәт булып үссеннәр”,“Әти-әниләренә терәк булсыннар”. Балаларның әти-әнисе дә бик шат.Һәрбер изге теләккә: “Әмин, әмин,”-дип кушылып утыралар.

Балаларга Гамил һәм Камил дигән исемнәр бирәләр. Гамил бик тә тыныч була, ашый да йоклап изрәп китә.Камил исә тынгысызрак бала булып үсә. Бер-бер артлы көннәр, айлар уза. Әни кешенең көннән-көн мәшакәтьләре дә арта тора. Камил бик җитез,кыю,торып баса башлый, ә Гамилнең кыюлыгы җитми әле. Камил караватына тотынып баса да ыгы-ыгы дип атына, үзенә исеме белән эндәшкәч көлә башлый. Әнисе икесен бертөрле киендереп куйгач, беренче карашка аларны аерып та булмый төсле. Әмма холыклары төрле була аларның.Гамил йомшаграк һәм тыныч та. Ул бераз игезәк сыңары Камилдән калыша. Бер яшь тулганда Камил тәпи йөреп китә, ә Гамил үрмәли генә, бераз караватъ янына тотынып йөри йөрүен. Камилгә бөтен нәрсә кызык,һәммә әйберне тарткалый,йолыккалый,аныңча булмаса, кычкырып елап куркыта. Бераз соңарып Гамил дә тәпи китә. Ул уенчыклары белән дә тәртипле генә уйный, ярамый дигәнне дә аңлый.

Менә шулай малайлар үсеп җитәләр, мәктәпкә укырга керәләр.Мәктәптә укыганда да, малайлар холыклары белән бик нык аерылып тора. Камил кыю,җитез, бераз мактанырга да ярата торган егеткә әйләнә, ә Гамил һаман шулай тыныч,уйлап эш итә, укуын да яхшы һәм тиз үзләштерә. Егетләр үсеп җитеп, авылдан чыгып китәләр,үзләре сайлаган һөнәр буенча эшли башлыйлар. Камилгә шәһәр тормышы, андагы шау-шулы кичәләр ныграк ошый.Ул туган авылына да сирәгрәк кайта башлый, төрле сәбәпләр табып аклана. Ә Гамил, киресенчә, атна саен кайта, әти-әнисенә булыша, аларның ышанычлы кешесенә әйләнә. Ул аларның хәлләрен белешеп,булышып тора. Авылдашлары да бу хәлләрне күреп-белеп торалар. Көннәрдән бер көнне Гамил авылның бик уңган, чибәр кызына өйләнеп,матур тормыш корып җибәрә. Ә Камил, гөлдән-гөлгә кунган күбәләк шикелле,кызларны сайлый торгач,берсенә өйләнеп карый, икенчесенә, әмма берсе белән дә озак яши алмый. Кызлар егетнең матурлыгына, тәмле теленә кызыгып чыгалар да, булдыксыз икәнен белгәч,яшиселәре килми аерылалар. Юкка гына: “Матурлык – ул күлмәк белән сәдәфтә түгел, әоят белән әдәптә,”- димиләр бит. Матур булыр өчен тышкы матурлык кына җитми шул, эчке матурлык та кирәк.

Кешеләр белән генә түгел, кошлар арасында да моңа ошаган хәлләр була икән.

Минем сүзем саесканнар турында. Алар бераз ала каргаларга охшаган, әмма саесканнар нәфисрәк, матуррак. Мин аларны ялтырап торган әйберләрдән башка бернәрсәгә дә тимиләр дип уйлый идем. Әмма фикеремне бер булган хәл бик нык үзгәртте. Җәй көне мин әбиемә авылга кайттым. Ул кечкенә чебиләр алган иде. Алар ишек алдындагы яшел чирәмдә, сары йомгак кебек, йөгереп йөриләр, чеп-чеп килеп, чирәм чүплиләр. Әбием аларга җим сала, су бирә. Чебиләр тамак ялгап алалар да бер урынга җыелып ял итәләр. Беркөнне мин шулай чебиләрне ашаттым да күзәтеп утырам. Бер саескан очып төште. Мин: “Җим ашарга, яки су эчәргә төшкәндер,”- дип уйладым. Ләкин саескан чебигә таба бара башлады. Мин аны куркытып җибәрдем. Йөгереп кереп әбигә күргәннәремне сөйләдем. “Әйе, кызым, саесканнар карап торганда гына матур күренәләр. Алар ялтырап торган әйберләрне урларга яраталар, кош ояларын туздырып йомырка урлыйлар, хәтта кош балаларын да ашыйлар,”- диде әбием. Чырык-чырык кычкырып, нинди дә булса хәбәр таратып һавада очкан, я булмаса, җирдә сикергәләп йөрүче бу кошларга - саесканнарга карата фикерем нык үзгәрде. Юкка гына: “Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар,”- димиләр икән.

## ОНЫТЫРГА МОНЫ ЯРАМЫЙ!

*Гайнетдинова Алиса, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең 10 сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Фатыйхова Ф.Ә.*

Офыклардан төтен таралды да,
Алсуланып, җиргә таң атты.
Шәһәр урамыннан атлый егет,
Җирдә тыныч, күңел – канатлы.

Күптән көтеп алган Җиңү килде.
Кайтты солдат туган иленә.
Туганнары каршы ала дисә,
Буш нигезләр генә күренә...

Күпме еллар үткән, сугыш кыры
Һаман төшкә кереп җафалый.

Җиребезнең тавышын ишетәм мин:
- Онытырга моны ярамый!
Хакыбыз юк, юк, юк, ярамый!

## ТУКАЙ АБЫЙ

Тукай абый әкиятләрең укып,
Өйрәндем мин әкият сөяргә.
Шигырь юлларыңны ятлый-ятлый,
Сәхнәләргә чыгып сөйләргә.
Күп нәрсәгә алар өйрәтәләр,
Балачактан безне белергә.
Туган телне, Туган илне сөеп,
Белем үрләренә менәргә.
"Су анасы" кила тәрәзәгә
Алыр өчен алтын тарагын,
Малай шунда гына аңлап ала,
"Кыек" юлдан үзенең барганын.
Тукай абый, синең шигырьләрең
Бирә безгә яшәү үрнәген.
Мин аларны күп тапкырлар укыйм,
Аңлар өчен тормыш серләрен.

## КӨТТЕРМӘСКӘ ИДЕ ӘНКӘЙЛӘРНЕ…

(хикәя)

*Гайнуллина Айгөл, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Хәйруллина Ә.С.*

Рөстәм мәктәптән өенә кайтканда, әнисе капка төбендә уйга чумып кояш баюын күзәтә иде. Яз башы. Көннәр озынайды, кояш соңрак бата, җылы яктан беренче булып туган якларына кайткан кошлар кояш нурларына коенып яз килүенә сөенә-сөенә очалар, оя коралар. Ләйлә апа йөрәге өзгәләнеп шул кошларны күзәтте. Шул кошлар белән кызлары да туган якка кайтып, туган йортка җыелып, аны сөендерүләрен көтте ул. Шулай уйга чумып, малаеның мәктәптән кайтканын күрмичә дә калды. Рөстәм әнисенең җилкәләреннән кочаклап алгач, Ләйлә апа кинәт сискәнеп китте.

- Әйдә әнкәй өйгә керик, хәзер әти эштән кайта, чәй җылыта торырбыз, дип, Рөстәм әнисен өйгә керергә үгетли башлады.

Ничек кенә өзгәләнмәсен соң ул үзәк?! Уртанчы кызы Линараның туган йортын, туган ягын ташлап киткәненә быел бит инде биш ел була. Себергә бер егеткә ияреп киткәннән бирле Ләйлә апаның аны күргәне юк, телефон аша гына аралаша, хәтта олы кызы Лиананың да күрше авылда торып та әнисенең хәлен белеп килергә вакыты юк. Ләйлә апа аның шулай булганына аптырамый да, чөнки үзе төп йортка килен булып төшкән, төп йортның нәрсә икәнен бик яхшы белә. Сез бием начар булган дип уйларсыз, юк, биеме бик яхшы иде, ире, ире көнче булды Ләйлә апаның. Ләйлә апа үзе бик яхшы, нечкә күңелле эш ярата торган булса да, туйның икенче көненнән бирле көнләшеп яшәде ире, бер кайда да чыгарасы килмәде аның, хәтта күрше авылдагы әнисе янына барып кайтуына да тавыш чыгарды. Бием исән чакта, әллә малае начар холыклы булганга, әллә килене бик нечкә күңелле булганга, гел киленне яклады, әнисенә барганына да сүз әйтмәде, өйдәге эшне дә үзе эшләргә тырышты. Ә тора-бара, биеме бакыйлыкка киткәч Ләйлә апаны ире бөтенләй өйдән чыгармады, гел кыйнады, бикләп тотты, санламады. Кызлары да, малае да моны күреп үстеләр. Әллә шушы

тавышка туйганлыктанмы, кызлары мәктәпне бетерү белән унсигез яшьләре тулуга бер-бер артлы, ата-ана нигезен ташлап кияүгә чыгып киттеләр. Аларның тормыш иптәшләре дус кызларының әтиләре шикелле үрнәк булачак, әтисе шикелле өйгә эчеп кайтып, хатынын кыйнамый торган ир булачагына бик ышандылар алар. Тик бөтен кешегә дә бер төрле язмыш язылмаган бит. Әтиләре әнисеннән гомер буе көнләшеп гомер итсә, Лианага да шундый язмыш бүләк итте тормыш.

Лиананың биеме бик начар холыклы кеше иде. Лианага гел эш кушып торды, кибеткә чыгып баласына тәмле әйбер алганына да, «ник акча туздырып йөрисең», дип кенә кычкырды. Ә ире бик йомышак күңелле, әнисе сүзеннән чыкмады. Шуңа күрә башка чыгып та китә алмадылар алар.

Үз әнисе янына да бик сирәк барды кыз. Өйдә гел бием хуҗа булып килде.

Ә Ләйлә апаның икенче кызлары Линараның ире киресенчә, бик яхшы, үз сүзен һәр вакытта да бастырып әйтә торган ир, акчаны да көрәп алды, Линараны да бик яратып, хөрмәт итеп яшәде, эштән кайтканда балаларына да тәмле ризыкларны күп итеп алып кайтты, уенчыкларга да акча кызганмады, хатынына да чәчәк бәйләмен алырга онытмый иде. Бик яхшы яшәделәр, тик гел әнисен юксынып яшәде Линара, ireннән генә качып елый торган булды. Бәхете өчен бик еракка киткән иде шул кыз…

Ләйлә апа белән Рөстәм өйгә кереп чәй куйдылар, инде акыл кергән, хәзер хатынына кул күтәрми торган ире дә эштән кайтып керде. Бергәләп чәй эчәргә утырдылар. Кинәт урам капкасы ачылган тавыш ишетелде. Рөстәм урынынан торып тәрәзәдән таныш йөзләрне күргәч сөенеченнән телсез калды. Әнисенең кем бар анда улым дигән сорауына:

- Апа, апалар кайтты! - диде дә, урамга чыгып йөгерде. Аның артыннан Ләйлә апа белән ире дә иярделәр.

- Менә бит, нинди шатлык, нинди сөенеч!- диде ире. Ананың сөенечтән күзләреннән яшьләре атылып чыкты. Ни утырырга, ни каршы алырга белмичә тик бер урында таптанды, аяк куллары калтырый башлады. Кинәт өй ишеге ачылып китте, беренче булып ишектән ак бантиклы, кечкенә кызны җитәкләгән Линара, аның артыннан 4 яшьләр тирәсендәге малае белән кияү дә күренде. Күп тә узмады күрше авылдан олы кызлары Лиана, ире һәм балалары белән менеп җиттеләр. Менә бит нинди шатлык! Өйгә язгы кояш нурларыдай яктылык керде, кошлар белән бергә балалар туган йортларына кайттылар, әнкәйләре янына җыелыштылар.

## **ҺӘЙКӘЛ КУЯР ИДЕМ**

(очерк)

*Гайнуллина Гөлия, Алабуга районы Иске Юраш урта мәктәбенең 10нчы сыйныф укучысы*

*Җитәкче: Юнусова Л.М.*

Еллар үтә, буыннар алмашына. Без – бәхетле чор балалары. Тыныч тормышта яшибез. Дөньяның, табигатьнең матурлыгына сокланабыз.Табыннарыбыз тулы ризык, өстебез бөтен, эти-әниләр назын күреп яшибез. Белем алып, киләчәк тормышта хыялларыбызны тормышка ашыру өчен дә, безгә дәүләт тарафыннан бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Без боларны “шулай тиеш” дип кабул итәргә күнеккән. Ә тарихка күз салсак, шушы матур тормыш өчен, туган җиребездә әле кайчан гына сугыш булып узган, күпме кан, күз яшьләре түгелгән. Халык моңарчы кешелек дөньясы күрмәгән авыр сугышны үз иңнәрендә күтәргән. Әйе, без бу турыда онытмыйбыз: сугыш турында кинолар да карыйбыз, китаплар да укыйбыз. Аңлыйбыз да: сугыш коточкыч нәрсә, безгә мондый хәлләрне күрергә язмасын. Әмма сугыш китергән михнәтне бөтен ваклыклары белән аңлап бетерә алмыйбыз икән. Күптән түгел без тыл каһарманнары белән очрашу үткәрдек, аларның хатирәләрен тыңладык. Менә монысы бөтенләй башка нәрсә!.. Алар сугыш чорында күргәннәрен бүген күргәндәй сөйләделәр, гүя бу 71 ел аралык бөтенләй булмаган.Ә бу хәлләр аларның йөрәкләренә еллар үтеп тә җуелмаслык булып кереп калган. Каршыбызда утырган, без күреп

белгән бу - чәчләренә ак бәс сарган әби-бабайларыбыз безгә "зур батырлык ияләре" булып күренделәр. Чыннан да, бу шулай. Аларның һәркайсы, Җиңүне якынайтам дип, нинди генә зур батырлыкларга тиң эшләр эшләмәгәннәр! Ә үзләре нинди тыйнаклар, без "менә шулай эшләдек" дип күкрәк кагып та йөрмиләр. Булган хәлләрне сөйләгәндә дә, Җиңүдә безнең дә өлешебез зур, дип тә мактанмыйлар. Аларның исемнәре батырлар исемлегендә дә юк. Ә үзләре Бөек Җиңүгә үзләреннән нинди зур өлеш керткәннәр...

Аларның хатирәләрен тыңлау күңелдә тыеп булмаслык хисләр өермәсе куптарды. Я, Ходаа, әсәр һәм кино геройлары безнең арадагы әби-бабайлар икән бит! Минем кызыксынуым чиксез иде. Алар турында мәгълүмат тупламыйча кала алмадым. Гомере буе укытучы булып эшләгән Валиева Кадрия әбигә юнәлдем.

90 яшькә җитеп килүче Кадрия әби мине самими мөләемлык һәм кунакчыллык белән елмаеп каршы алды. Аксыл тукымага эре-эре лалә чәчәкләре төшкән күлмәк, башына ак яулык япкан Кадрия әбине күргәч, күңел ничектер йомшарып китте. Әйе, әйе, нәкъ без әсәрләрдә укыган "ак әби" образындагы кебек иде ул. Аның үзеннән дә аклык, сафлык бөркелә сыман. Әби уйларымны бүлеп, чын татарча итеп, исәнләшергә кулын сузды. Килүемнең сәбәбен аңлаткач, күңеле тулып, күз яшьләрен сөртеп алды.

1928 нче елда туганКадрия әбинең балачагы, үсмер еллары авыр сугыш елларына туры килә.12 яшеннән ул, юньләп йокы да, ял да күрмичә, карт-корылар белән басуда эшли. Утау утый, көлтә бәйли, чүмәлә куя. "Барысы да фронт өчен, Бөек Җиңү өчен!" девизы астында ачлы-туклы килеш, төрле авыр эшләр башкарганнан соң, төннәр буе әби-апалар белән фронт өчен йон оекбаш, бияләйләр бәйли.Рухи яктан ныклы холыкка ия, гадел, кыю, тырыш гаиләдә тәрбияләнгән кыз үзе дә югары әхлаклы, эшчән булып үсә.

Җаваплы, һәр эшне җиренә җиткереп эшләүчән, максатчан Кадрия гомерен, барлык эшләрен иң олы гамәлгә - балаларны аң-белемле һәм тәрбияле итәргә багышларга хыяллана. Шул хыялларын тормышка ашыру максатыннан, 16 яшьлек кыз Алабуга педагогия училищесына укырга бара. Авылдан алар ике малай һәм дүрт кыз китәләр. Бер дә якмаган гомумторакта торалар, бер тапкыр да якмаган класста укыйлар. Өстән "пәлтә"ләре, кулдан бияләйләре төшми. Авырлыкларга түзә алмыйча, иптәшләре кайтып китә. Кадрия 1946 нчы елда уку йортын берүзе генә тәмамлый. 18 яшьлек кызны Илмәт башлангыч мәктәбенә укытучы итеп җибәрәләр. Бу ел сугыш елларына караганда да авыррак ел була.

1946 нчы елның җәе бик коры килгәнлектән, ни ашлык, ни бәрәңге булмый. Әйтеп бетергесез ачлык килә. Кешеләр кычыткан ашы, басудан черегән бәрәңге җыеп, алабута оны кушып, күмәч пешереп ашыйлар.

Язмыш Кадрияне әйтерсең сынаган өстенә сыный. Авырлыклар берсен-берсе уза-уза килә сыман. 1943 нче елны әтисен, 1946 нчы елны әнисен җирләгән Кадриягә ничек тә дүрт баланы ачлыктан саклап калырга кирәк була. Әбалаларны ашатырга бер уч та он юк. Бакчада бәрәңге чәчәк ата башлаган чак. Шул чәчәк аткан төпне эзләп, йомырка сарысы зурлыгындагы бәрәңгеләрне җыя ул. Шулай туганнарын ачлыктан саклап кала. Әйтеп, язып бетермәслек авыр еллар булса да, әти-әнисе үрнәгендә тәрбияләнгән кыз, эне-сеңелләренә төпле белем, тәрбия биреп, олы тормыш юлына аяк бастыра.

Үз тормышына килгәндә, тормыш давылларында сыналган Кадрияне инде бернәрсә дә куркытмый. Ул белә: бар нәрсәдән дә чыгу юллары бар, бары тик авырлыклар алдында сыгылып төшмәскә генә кирәк. Кадрия бөтен тырышлыгын Илмәт, Иске Юраш мәктәпләрендә балаларга белем-тәрбия бирүгә багышлый. 1965нче елда Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Утыз ел буена иң алдынгы укытучылар сафында була. Аңа методик берләшмә җитәкчесе эшен дә ышанып тапшыралар. Ул балаларның да, җитәкчеләрнең дә ышанычына, таянычына әверелә.Район һәм мәгариф идарәсе җитәкчеләреаның эшен югары бәяли. Эшендәге югары күрсәткечләре өчен,күпсанлы мактау кәгазьләре, медальләрбелән бүләкләнә.1963 нче елда "Халык мәгарифе алдынгысы" исеменә лаек була, 1967 нче елда "РСФСРның атказанган укытучысы" исеме бирелә.

Халкымның ныклы ихтыярлы, югары әхлаклы вәкиле белән очрашу миндә горурулык хисләре уятты.Әйе, менә ни өчен җиңә алмаган фашизм безнең халыкны!Юк, мондый халыкны беркем җиңә алмый. Безгә, XXI гасыр вәкилләренә дә, өлкән буыннан үрнәк алып, югары әхлак сыйфатларына ия булырга кирәк. Миңа калса, мин мондый каһарманнарга кылган гамәлләре өчен һәйкәл куяр идем.

## МЕЛОМАН

*Галәветдинова Диләрә, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Әхмәдгалиева Г.Г.*

«Современный» студентлар дөньяда булган техник үзгәрешләрдән бер дә артка калмый - ә шул үзгәрешләр белән бергә, ә юк, хәтта яңалыклардан алдарак та атлыйлар! Яшьләрнең колакларында «наушник» күрү гаҗәп нәрсә түгел, ә гадәти күренешкә кереп бара. Ә яшьләр бер-берсе белән күрешкәндә, элекке замандагы кебек эшләпә түгел, ә наушник салып «исәнләшәләр». Бу үзенә күрә сәламләшкән кешегә булган хөрмәтне күрсәтү кебек килеп чыга.

Дөнья үзгәрешләре белән бергә атлаган яшьләр арасында Камил дә бар иде. Ул үзенең яраткан университетына, колагына наушник тыккан килеш, барырга ярата иде. Юл ерак булмаса да, 15 минутлык, ике адым араны ул көй тәэсирендә уздыра иде. Ә җырлары - берсеннән-берсе матур, араларында чит телдә җырланганнары да бар. Нәрсә сөйләгәннәрен анламаса да, көе матур шул.

Иртәнге якта бигрәк гөжли шул уку йорты. Студентлар, укытучылар агыла гына. Читтән карап торганда, кырмыска оясын хәтерләтә. Шушы кайнап торган «кырмыска оясына» ашыкмый гына килеп керде Камил. Колагында иң яраткан җыры бара. Бу җыр испан телендә җырланылса да, егет анда татар сүзләренә охшаш авазлар ишетә иде.

- Әәә, безнең пара 69 дамыни,- дип үзалдына сөйләнеп аудиториягә таба бара. Колагындагы көе шундый матур иде ки, ул егетнең күңелен шундый күтәреп җибәрде, Камил үзе сизмәстән «Хоп… опа.. ап итте» дип коридорны тутырырлык тавыш катыш көй белән кычкырып җибәрде. Әгәр Камил узып киткән 43 нче аудиториядән чыкканда абынып егылган Сара Маликовна булмаса, аның бу кычкыруына группадашларының исе китмәс иде. Алар инде егетнең кызык-мызык сүзләренә, гадәтләренә күнеккән …

Камилнең курсташлары, бер-берсенә төрткәли-төрткәли, үзләренең ниндидер «жестлары» белән Камилне кисәтергә тырыштылар:

- Нишли инде ул!?

- Ник шул наушнигын салмый икән? Бер дә булмаса монда… - диешә- диешә, кызлар маңгайларын тоталар.

Бу кадәр ишарәләрдән соң Камил артына борылып карарга булды… Шундук анын карашы укытучыга төште. Ә Сара апасынын күзләреннән «Бүген икенче паран миндә, шунда кем-кемнән көлер микән?» - дигән уйны укып була иде. Үзенең ни кычкырганын, ул сүзләрне укытучысы үзеннән көлү итеп кабул иткәнен абайлап алуга, аның өстенә салкын су койгандай булды… һәм ул күзен ачып җибәрде. Ә анда кулына чәчәкләргә сусиптергеч тоткан сеңлесе басып тора:

- Абый, бүген якшәмбе дигәч тә, уникегә кадәр йокларга дигән сүз түгел бит, - дип әйтүе булды, Камил аны кочаклап алды да:

- Бүген миннән сиңа бер шоколад!!! – дип, сөенечен эченә сыйдыра алмыйча, көлеп җибәрде.

## ТЫЙНАК КАРА ИКМӘК ҺӘМ ҺАВАЛЫ АК КҮМӘЧ

(әкият)

*Галеев Риназ, Олы Шүрнәк урта мәктәбе 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Галеева Л.Х.*

Әйтик, бер заманда, түгәрәк өстәл өстендә яшәгәннәр ди Кара икмәк белән Ак күмәч. Икесе дә бик кадерле булганнар ди алар, икесе дә бик дус булганнар ди алар. Кара икмәк белән аш, ботка, бәрәңге, ит ризыкларын бик тәмләп ашаганнар. Ак күмәч бал-майга ягылып, чәй вакытында бик хуш килгән.

Бер дә бер көнне тигез генә яшәп ятканда, әллә нидән юкка гына Ак күмәч һаваланып китте.

- Кара әле, Кара икмәк, нигә мине синең белән бертигез бер савытка салалар? Мин бит нинди матур, ак тәнле, хуш исле, мәмердәп торам, авызга кергәч, конфит төсле эреп китәм, - дигән. Юк-юк, дөрес эшләмиләр, мин тәмлерәк булгач, тәмлерәк! Мине балалар бик тә яраталар.

- Әйе, яраталар, сүз юк, тик сине еш кына өстәл валчыгы буларак, ашлы-су чиләгенә дә салалар, - дип сабыр гына җавап кайтарган Кара икмәк.

Бу сүзләр инә кебек Ак күмәчнең йөрәгенә кадалган. Кисәк кенә җилләп кибеп китеп, бөтенләй катып калган.

Шунда Хуҗабикә аны күреп:

- Тукта әле, Ак күмәчне мичкә тыгып, сохари киптерим әле, - дигән.

Мичтән чыкканда, Ак күмәчнең йөзенә көрән-саргылт төс кергән, кибеп, кечерәеп калган. Инде ашасалар да, бал-май ягып түгел, чәйгә салып, эретеп капканнар. Җәелеп изелгәнен кайчагында ашамыйча да, ашлы-су чиләгенә салганнар. Ә Кара икмәкнең өстәлдәге урыны һәрвакыттагыча кирәкле торган. Ул бик кадерле булса да, тәкәбберләнмәгән, һаваланмаган. Үз көне һәм кирәклеге белән канәгать торган.

Ак күмәч, сохариланганнан соң, хатасын аңлап, Кара икмәктән бик нык оялган. Аның да бите-йөзе хәзер нәкъ Кара икмәкнеке төсле булган.

- Тиз ялтыраган тиз уңа, шуны онытма, туган! - дигән Кара икмәк сохариланган Ак күмәчкә.

## КАРАКАШНЫҢ ЙӨЗӘРГӘ ӨЙРӘНҮ ВАКЫЙГАСЫ

(әкият)

Борын-борын заманда, әй-ли юк, хәзерге заманда яшәгән ди бер каз малае. Күз өстендә кара таплар булганга, әнисе яратып, Каракашым дип дәшкән аңарга. Каракаш бик акыллы малай булган, ләкин бер кимчелеге бар икән: башка казлар кебек йөзә белми ди. Дөресрәге, судан курка. Курка дигәч тә инде, суның үзеннән түгел, су эченә кереп йөзүдән курка. Әмма дәген балык тотарга бик тә хирыс малай икән ул. Сез уйлыйсыздыр инде: “Үзе судан курка, ә балык ничек соң ул тота?”- дип. Хи-и, көнозын кармак белән Зәңгәр күлдә балык тота. Ә әнисе ул тоткан балык белән әтисенең яраткан балык бәлешен пешерә икән.

Күршедә генә Каракашның дусты үрдәк малае Күрди, кушаматы Былтый яши. Аңа гел бытылтап торганга шундый кушамат такканнар. Бытылтый-бытылтый Каракаш белән көн саен Зәңгәр күлгә бара, анда уйный, чума, йөзә ди бу. Каракаш дустын бик хөрмәт итә, чөнки ул аңардан бер дә көлмәгән, йөзә белмәү серен дә, бытылтык булса да, беркемгә дә сөйләмәгән.

Менә беркөнне үрдәк малае Күрди-Былтыйның атасының туган көне килеп җиткән. Әнкә каз Каракашына бер чиләк тутырып, балык тотып кайтырга кушкан. Чөнки инде әнисе күршесе хөрмәтенә хуш исле, майлы, үзенең “фирменный” балык бәлешен пешереп керергә уйлаган. Иртүк таңнан Каракаш белән Күрди-Былтый Зәңгәр күлгә юл тотканнар. Килеп

җитү белән, каз малае кармагын салып күлгә, рәхәтләнеп, җырлый-җырлый, балык тота башлаган:

Кыйгак-кыйгак утырам,
Күлдән балык мин тотам.
Кояш карый елмаеп,
Янда йөзә Күрди дус, бак-бак-бак.

Ә Күрди-Былтый Зәңгәр күлдә, чумып-чумып, йөзә ди, канаты белән дә, иңләп-иңләп,колачлап-колачлап, йөзә ди, бытылтый-бытылтый, чебен-черки белән сөйләшә ди. И-и-их, бигрәк оста йөзә шул, нәкъ чуртан балыгы, билләһи!
Шулай ял итеп йөзгәндә, Былтыйның әнисе әйткән сүзләре кылт итеп исенә төште:

- Улым, Күрдием, атаңның туган көненә, яшел бодайлы салатка күл төнбоеғының сусыл яшел сабагы кирәк иде, алып кайталмассыңмы, җаным!

- Үзем иң сусылын, иң тәмлесен сайлап алып катырмын, әнием, күңелең тыныч булсын, кадерлем! - дигән Күрди-Былтый.
Күз ачып йомганчы, су төбенә дә чумды Былтый. Каракаш: "Сөбханалла-машалла, күзләр генә тимәсен, менә дигән спортсмен чыга бу Күрдидән",- дип сокланып карап торган аңарга.

Балык тота торгач, Каракашның чиләге тулган. Ә теге чумудан Күрди һаман юк та, юк. Су төбендә Күрди иң озын, иң сусыл төнбоек сабагын эзләп тапкан. Ләкин сусыл сабак күл төбенә шундый нык берегеп үскән, һич йолкып чыгарып булмаган. Аптырап, Күрди урт тешләре белән өзеп алмакчы булган, барыбер һич өзелми икән. Һава суларга ике-өч минутка өскә калыккан да, тагын чумган.

Инде кайтырга да вакыт җиткән, ә Күрди-Былтый һаман юк.

- Күрди, әйдә, чык инде, чык, кайтыйк инде,- дигән Каракаш.

- Хәзер, Каракаш, сусыл сабакны өзим дә, чыгам,- дип кычкырган су төбеннән Күрди-Былтый.

Тегеләй дә итеп карый, болай да итеп карый, һич кенә дә өзелми ди сусыл төнбоек сабагы. Шулай үлән сабаклар арасында бөтерелә-бөтерелә торгач, аяклары уралып беткән, канатлары һәм койрыгына күл ләме йоккан, су төбе томаланып, бернәрсә күренмәс булган. Күрди-Былтый чыга алмыйча, бәргәләнә, һава куыгы чыгара башлаган. Бу күренешкә аптыраган Каракаш: "Күрди, батасың бит инде, чык Ходай өчен!"- дип, ялварып, күл яры буйлап йөгерә башлаган, ярдәмгә чакырган. Ләкин тирә-якта беркем дә юк ди.

Каракаш дустының батуыннан куркып, канатларын җилпеп күл өстенә күтәрелгән һәм ук аткан күк күл төбенә чумган. Болганчык күл төбендә Күрди-Былтыйның чирәмгә уралган хәлсез гәүдәсен күреп, шундук аңа таба йөзгән. Күрдине чирәмнән аралап, киң җилкәсенә салып, су өстенә калыккан. Аяклары белән суны тиз-тиз ишеп, яр буена чыккан. Тиз генә дустына ярдәм дә күрсәтә башлаган. Күрдинең бытылтавын ишеткәч, Каракаш бик сөенгән. Ә Күрди-Былтый һаман бытылтый ди: "Каракаш, дустым, син мине коткардың, син шундый батыр, син шундый оста йөзүче, минем дустым, минем дустым..."
Менә шулай юктан чыккан бер батырлык аркасында, үз куркуын җиңеп, Каракаш та йөзәргә өйрәнгән. Ә кичен, ике күрше гаиләләр Үрди атаның туган көненә җыелдылар. Әнкә каз үзенең "фирменный" балык бәлешен, әнкә үрдәк сусыл сабаклы, яшел бодайлы салатын, кыстый-кыстый, тәкъдим иткәндә, мин дә шунда булдым, бу вакыйганы үз күзләрем белән күрдем, бераз борчак та бугай шыттырдым...

## ЧЫРШЫЛАРЫМ

*Галиәкбәрова Эльвина, Бөгелмә шәһәре 2 нче лицейның 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Невметулина Г.Ф.*

Сагынып кайтам авылымны,
Күрим диеп җан дусларны.

Үсеп китәм сөенечтән,
Кабат күрсәм чыршыларны.
    Кайткан саен каршылыйлар
    Минем яшел чыршыларым.
    Китсән чакта, "кайт" дигәндәй,
    Моңсулана алар тагын.
Чыршылы юл буйларыннан
Уздым уйлап күпме тапкыр.
Һәрберсенең ботагыннан сыйпар идем,
Әгәр булса юлым такыр.
    Үсегез сез, яшь чыршылар,
    Һәр кешегә җан дус булып...
    Җәйләр җиткәч, кайтырмын мин,
    Күрешергә кулым сузып...

## ТЫЛСЫМЧЫ КЫЗ
**(зурлар өчен экият)**

*Галимова Лилия, Башкортостан Республикасы, Бакалы районы,*
*Камышлытамак урта мәктәбенең 8 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Яппарова Ф. З.*

Борын-борын заманда түгел, ә хәзерге вакытта яши ди Таңсылу исемле беркыз. Ул бик кызыксынучан, табигатьне яратучы, шат күңелле. Таңсылу көндә иртәнге сәгатьттә, табигатькә сокланып, йөреп кайтырга ярата. Менә бүген дә ул, уяну белән урамга чыкты. Иртә шундый матур, агачларда кошлар сайрый, яңа гына чыккан кояш үзенең нурлары белән кызның битен иркәли. Таңсылуның күңеле күтәрелеп китте һәм ул чиләкләрен алып чишмәгә суга барырга булды. Шулай әкрен генә, табигатькә сокланып, көйләп барганда, ул якындагы агачта утырган ике кошның сөйләшкәнен ишетеп калады.

– Ничек матур безнең чишмәбезнең тирә-ягы, карале, нинди матур чәчкәләр, үләннәр, куаклар, агачлар үсә, ә аларның яфраклары ямь-яшел. Ә һавасы... – дип ишетлде бер кошның тавышы.

– Әйе шул. Сокланып туймаслык! Кызганычка каршы бар җирдә дә табигать болай чиста түгел. Син бу тирәдә генә яшәгәч, белмисең шул. Менә миңа, яз көне туган якка кайтканда, шәһәр өстеннән очарга туры килде, белсәң андагы һаваның пычраклыгын, –диде икенчесе.

– Ә нигә соң ул пычрак?

– Анда завод-фабрикалар, машиналар күп һәм алардан чыккан төтен таралып, һаваны зарарлый. Хәтта шәһәр тирәсендәге елганың суы да тәмсез, чөнки шул ук завод-фабрикаларның зыянлы калдыклары елгага агызыла. Суның пычраклыгы балыкларга да зыян китерә бит әле.

– Ә безнең чишмәбез шундый чиста, матур, суы да тәмле, ә аның челтер-челтер аккан тавышы бер моңга тиң.

– Әйе инде, мәктәп балалары аны гел карап, тирә-ягын чистартып торалар. Таңсылу кошларның әңгәмәсен ишетеп таң калды һәм аларның сөйләшкәннәрен аңлагангай аптырады. Шушы көннән башлап ул барлык агачларның, куакларның, чәчкәләрнең, үләннәрнең, җәнлекләрнең, кошларның, хәтта балыкларның да сөйләшкәннәрен, аларның уй-фикерләрен аңлый башлады. Икенче көнне аның кәефе юк иде һәм ул су агышына карап тынычланырга теләп елга буена китте. Көн болытлы, җилле иде, әйтерсен лә табигатьтә кызның кәефен сизә. Җил искәнгә елга да шаулабырак ага. Кичәге чишмә тирәсендә булган хәлләр турында уйлап утырганда, елга буена кемдер китереп түккән чүпне күреп,

Таңсылуның җаны әрнеде, җитмәсә елгадан ниндидер чүпләр, пластик шешәләр агып килгәнен күрде. Ризасызлык белдергәндәй яңгыр да явып китте, табигать елаган төсле булды. Таңсылуның бар көченә кычкырасы килде: “Кешеләр! Сезгә яшәргә көч биргән, яшәү чыгынагы булган суны, табигатьне нигә пычратасыз!“ –дип.

Менә шулай кайда барса да Таңсылу җәнлекләрнең, үсемлекләнең тавышын ишетә торган була. Бервакыт урман тирәли җиләк җыеп йөргәндә, ул үләннәрнең, җиләкләрнең, куакларның һәм башка якын-тирәдәге үсемлекләрнең сөйләшкәннәрен тыңлый башлый. Алар зарланалар.

– Менә кешеләр чүп китереп түгәләр дә монда, ул озак, кайберләре еллар буе таркалмый, җиргә зарарлы әйберләре сеңә, безнең тамырлар аша үтеп керә, – ди кайсыдыр. Әйе, шуның өчен безгә дә зыян килә. Ә үзләре монда килеп җиләк-җимеш, гөмбә җыеп китәләр. Үз-үзләренә дә зыян китерәләр түгелме?!– диделәр җиләкләр.

– Ә менә безне бөтенләй төптән кисеп алып китәләр. Безнең яфраклар күпме кислород бүлеп чыгара бит, һаваны чистарта, начар газларны үзенә сеңдерә. Нинди файда булыр иде бит үзләренә күп итеп яңа үсентеләр утыртсалар, – дип кушылды агач-куаклар. Таңсылу борчулы уйлар белән кайтып китте. ”Ничек ярдәм итәргә?” –дип озак уйланды. Башында гел шушы уйлар бөтерелде: “Кешеләр, аңлагыз! Без бит табигать беләнербөтен. Аңа зыян салып, без үз-үзебезгә начарлык эшлибез, сәламәтлегебезне югалтабыз.” Көтмәгәндә ул үзендә тылсым көче барлыгын сизә. Ул бит кешеләрнең аңына шушы сүзләрне җиткерә ала. “Кешеләр аңлар, барсы да яхшы булыр”, – дигән изге өметләр белән ул тыныч сулап куя. Тылсымчы кызның такмаклап йөргән сүзләре һәркем өчен девиз булсын иде:

Табигать безнең анабыз,
Без моны яхшы аңлыйбыз.
Һәрвакыт аны саклрабыз,
Беркайчан зыян салмабыз.

## ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ, ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ

**(хикәя)**

*Галләмова Айгизә, Актаныш авылы Аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүле 2 нче урта мәктәбенең 10 нчы сыйны фукучысы*
*Җитәкче: Камаева Э.Р.*

Тышта ябалак-ябалак кар ява. Авыл өйләренең түбәләреннән җылы төтен күтәрелә. Авылның бер читендәге искерәк кенә өйдән инде ничәнче көн чыккан-кергән кеше күренми. Өйгә керүче сукмакны көрт басып киткән. Салкын өй эчен шомлы тынлык биләп алган. Сәгатьнең келт-келт итеп йөрүе генә өйдә кеше барлыгын искәртеп тора. Сәрвәр карт белән Гөлчирә карчык калын киенеп, юрганнарына төренеп, кемгәдер рәнҗегән, үпкәләгән кыяфәт белән караватта утыралар. Йа, ходаем, нәрсә булды соң аларга картлык көннәрендә? Нишләп мондый көнгә төштеләр соң алар?

Барысы да төпчек уллары Мирхәт өйләнгәч башланды. Карт белән карчык Зөһрәне беренче күрүдә үк ошатмадылар. Юк, кыз төскә-биткә төшеп калганнардан түгел, эшкә дисәң, авылда бер. Районда алдынгы сыер савучы булганга, берничә ел рәттән район советына депутат итеп сайладылар, Германиягә путевка белән бүләкләделәр.Тик Зөһрәнең бер “гаебе” бар: ул кияүдән аерылып кайткан. Бәлки аерылмаган да булыр иде, кияүгә чыккач, ире аны яшәргә Свердловск шәһәренә алып китте. Моңарчы авылдан беркая чыкмаган, гел әнисе белән яшәгән кыз туган авылын, ямьле Агыйдел буйларын сагынды. Сагынды, сагышка батты... һәм авырый башлады: кызның аяклары йөрмәс булдылар. Моңа кызның кечкенә чакта күргән газаплары, ачлык, ятимлек, торыр җирләре булмау да, 13-14 яшеннән авыр эштә эшләүнең дә тәэсире булгандыр, мөгаен. Моңарчы

үзенең дә беркая чыкканы булмаган Шәмсия карчык мең газаплар белән шәһәргә барып, кызын авылга алып кайтты. Төрле үләннәр җыеп, шулар ярдәмендә дәвалады, бер ел эчендә кызын аякка бастырды. Зөһрә кабат шәһәргә китү турында уйламады. Юк, яши алмаячак ул шәһәрдә. Яшел үләннәрдә яланаяк йөрүдән дә, туган як һавасын сулаудан да рәхәтрәк нәрсә бармы соң дөньяда? Бөтен җаны-тәне белән береккән ул авылга, ул – авыл баласы.

Кыз менә шулай авылда калды һәм язмыш аны Мирхәт белән очраштырды. Моңарчы бик күп кызларның башын әйләндергән, озын буйлы, дулкынланып торган куе кара чәчле Мирхәт, Зөһрәне күргәч, сихерләнгән кебек булып калды. Егетнең төн йокылары качты. Ап-ак булып ябалак-ябалак карлар явып торган кышкы бер көндә бизәкле чаналы атларга утыртып кызны үз йортына төшерде.

Егетнең эти-әнисе Сәрвәр карт белән Гөлчирә карчык кулларындагы хуҗалык дилбегәсен алай тиз генә киленгә бирергә теләмәделәр. Гомер-гомергә яшелчә үстереп көн күргән Гөлчирә карчык, язга чыгу белән бакчаны икегә бүлдерде: яртысына карты белән ул, ә икенче яртысына улы белән килене утыртты. Җай килгән саен төрттерү җаен тапты, ә кодагыйга, гомумән, бу өйгә килү тыелган иде. Олы уллары белән күршедә генә яшәүче кызлары керсә, киленне яманладылар, янәсе рәнҗетә, каршы әйтә, ашарга пешерә белми. Зөһрә соң бу вакытта каршы әйтерлек хәлдә идемени? Иртүк өчтән-дүрттән эшкә китеп, 25 сыерны кул белән савып кайтканда, абыйсының балалары килеп, өстәл тирәли тезелеп утырган булыр. Сүз әйтмичә, ашамыйча ихата тирәсендәге эшләрне карап кергәнче, төш вакыты җитә. Түзде Зөһрә, тешен кысып түзде. Бик рәнҗегән чакларында, бакча артындагы тирәк янына төшеп күз яшьләрен сөртте. Тормышның ачысын-төчесен татыган Шәмсия карчык кызын кызганып:

- Түз, кызым, сабыр ит. Сабыр төбе – сары алтын, диләр. Кияү дә бик яхшы кеше, кодалар да алай бик начар түгелләрдер әле. Бер булмаса, бер җай чыгар,-дип, юатудан битәр ары сүз табалмады.

Иң авыры алда булган икән. Көзге салкын көннәрнең берсендә Мирхәтнең абыйсы Шакир, эчкән баштан килеп, бик каты тавыш чыгарды:

- Сез әткәй белән әнкәйне рәнҗетәсез, карамыйсыз, хатыныңа әйт, телен тыйсын. Юкса нишләргә кирәкне белермен, -дип янады.

Мирхәт белән Зөһрә эштән кайтканда, әтисе белән әнисен Шакир алып чыгып киткән иде. Кышка каршы карт белән карчыкны авыл очындагы буш өйгә урнаштырган. Утынын китерермен, килеп йөрермен дисә дә, Шакир аларны бик тиз онытты. Мирхәт белән Зөһрә авылдашлары алдында гарьләнделәр, үзләре алданрак чыгып китмәгәнгә үкенделәр. Тик буласы булган иде.

Бөтен дөньясына хуҗа булыр кебек йөргән Сәрвәр карт белән Гөлчирә карчык, улы белән килененнән китеп, аерым тора башлагач, кулларыннан эш килмәвен аңладылар. Картаюларын шунда сизделәр. Төрлечә ярдәм итәрмен дигән олы уллары да, кызлары да күзгә-башка күренмәделәр. Менә шулай итеп, карт белән карчык ярык тагарак алдында калдылар: ягарга утын, ипи пешерергә он, ризык юк. Җитмәсә, карчыкның хәле көннән-көн начарлана бара. Күзләрен ишектән алмадылар, балаларын көттеләр. Менә ишектән Шакир килеп керер төсле тоелды.

...Кинәт ишек ачылып, салкын һава агымы, аның артыннан уллары Мирхәтнең килеп кергәнен күргәч, икесе дә бер-берсенә карап аптырап калдылар. Алар башка балаларын күрергә өметләнсәләр дә, Мирхәт килер дип көтмәгәннәр иде. Өйнең салкын булуы, карт белән карчыкның инде ничә көннәр җылы ризык күрмәгәннәре әллә каян күренеп тора иде. Мирхәт иң элек мичне тотып карады, аннан өстәл тирәсенә килеп:

- Их, әткәй-әнкәй,-диде ул.- Картлык көнегездә сез шушы хәлгә төшәргә тиеш кешеләр идегезме соң?! Кеше алдында үзегезне дә, мине дә хур иттегез.

Аның сүзләрендә этисе белән энисенә үпкә, шул ук вакытта аларны кызгану хисләре сизелә иде:

- Урыныгыз түрдә, җылы аш кына ашап ята идегез бит. Ни җитмәде соң сезгә?!

Карт белән карчык бу вакытта ни әйтергә белми, бер-берсенә сыенып үксеп-үксеп еладылар. Бу минутта алардан да кызганыч, мескен кеше юк иде. Әллә катырак әйтеп ташлады, Мирхәтнең үзенә дә бик авыр булып китте, бугазына төер утырды. Ничек килеп керсә, шул тизлек белән ишеккә юнәлде һәм:

- Әйберләрегезне җыя торыгыз, мин хәзер киләм,- дип чыгып китте. Күп тә үтмәде, чаналы ат белән эти-энисен туган нигезгә алып кайтты ул. Зөһрә берни булмагандай, этисе белән энисен каршы алды, йомшак урын-җир әзерләде һәм өстәл янына чакырды.

Түрдә булды Сәрвәр карт белән Гөлчирә карчыкның урыны. Булган хәлләрне берәүнең дә искә төшерәсе килмәде. Киленнәре Зөһрә аш пешерсә, иң элек биатасы белән бианасына куйды. Урын-җирләре һәрчак юылган, пөхтә булды. Ә Мирхәтнең беренче улы туганга, Сәрвәр карттан да ныграк сөенүче булмагандыр. Аның нәселен дәвам итүче беренче ир балага исемне дә картка уйларга куштылар.

Бер-бер артлы еллар үтте. Карт белән карчык олыгаеп, килене һәм улы тарафыннан кадер-хөрмәт күреп, бакый дөньяга күчтеләр. Үләр алдыннан Сәрвәр карт киленен чакырып алып:

- Рәхмәт килен, рәнҗемә безгә. Рәхәттә яшәгез, -дип фатихасын бирде.

Рәхәт яшәделәр, матур яшәделәр Мирхәт белән Зөһрә. Тырышып дөнья көттеләр. Әтиләреннән калган нигезне саклaverдылар, нәселне дәвам итәрлек акыллы балалар үстерделәр.

## ТОРМЫШ САБАГЫ...

(хикәя)

*Галләмова Диана, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Газеева Ф.С.*

Тормыш – бик кызык нәрсә инде.... Моңа мин тагын бер кат инандым әле.

Соңгы вакытта мине бер сорау борчый башлады: мәктәпне тәмамлагач, кем булырга, нинди һөнәр сайларга? Музыка һәм сәнгать мәктәпләрендә укуым заяга китмәсен, дип, әллә шул өлкәне сайлыйм микән, дигән уйлар да килә башка. Әти белән әни мине өннәрендә дә, төшләрендә дә адвокат итеп күрәләр.

Көтмәгәндә, уйламаганда бу мәсьәләне чишәргә әбиләрем ярдәм итте бит әле. Шулай көннәрнең берсендә безгә авылдан ике әбием килде, берсе – әниемнең әнисе, икенчесе – әниемнең әбисе. Нәкъ менә карт әбинең авырып китүе безгә килүләренең сәбәбе булган да инде. Карт әбиемә 85 яшь. Ул дәү әнием һәм дәү әтием белән бергә авылда тора.

Әтиемнең эти-әнисе шәһәрдә торганга күрә, без авылга сирәк кайтабыз, күбрәк әтинең туганнары белән аралашабыз. Җәйге ялны да я диңгез буенда, я чит илдә үткәрәбез. Шуңа күрә бу әбиләремне бик яхшы белмим дисәң дә була.

Кызганычка каршы, әбиләрнең килүләрен әтием бик хуп күрмәде, артык якты чырай да күрсәтмәде, әнием дә аннан калышмады.

Дәү әнием бик горур кеше булып чыкты, беркемгә дә ялынмыйча, миннән генә такси чакырттырды да, карт әбине хастаханәгә такси белән генә йөртте. Аннан соң, кемнеңдер киңәше белән, анализлар алырга, кардиограммалар, узилар ясатырга өйгә махсус ашыгыч ярдәм дә, башка ярдәм дә күрсәтә торган машина гына килә башлады. Дәү әнинең бу адымы да әтиемә ошамады, билгеле. Имеш, безнең өйгә теләсә кем керә ала.....

Ә миңа әбиләр белән аралашу шундый ошады. Аларның зирәклеге, тормыш тәҗрибәләренең байлыгы, һәрбер сүзне уйлап әйтүләре, ипләп кенә, бәйләп-бәйләп сөйләүләре, аңлатулары – мине таң калдырды. Мин хәтта өй эшләрен дә тиз генә эшләп,

әбиләрем белән аралашырга ашыга идем. Ә күпме тәмле милли ризыклар пешерергә өйрәттеләр алар мине!

Атна-ун көн үткә, анализлар тикшерелеп беткәч, әбиләр тагын табибка күренергә киттеләр, бу юлы мин дә алар белән бардым. Артык куанычлы хәбәрләр әйтмәде табиб,йөрәген ешрак тикшереп торырга дигән киңәш бирде.

Икенче көнне бабай килеп, әбиләрне авылга алып китте. Саубуллашканда, карт әбием миңа:

- Иң мөһиме, балам, нинди һөнәр сайлавыңда түгел, нинди кеше булуыңда, - диде.

Мин үзем өчен ике нәтиҗә ясадым: бернигә дә карамастан, әбиләрем кебек йомшак күңелле, кешелекле була белергә һәм, медицина университетына укырга кереп, тирән белем алып, яхшы табиб булырга.

Ә этием белән әниемә килгәндә, алар миңа тагын бер тормыш сабагы бирделәр. Кунаклар киткәч тә, эти өйне ныклап җыештырырга кушты, әнинең туганнарын якын арада күрергә теләмәвен белдерде. Мин, киресенчә, бу җәйне авылга кайтачагымны әйттем. Әни, бу сүземнән көлгәндәй:

- Нигә җәйне көтеп торасың, яз көне үк кайт, - диде.
- Дөрес эшләдемме, юкмы, белмим, мин дә җавапсыз калмадым:

Еллар үтеп, мин үзем дә, минем балаларым – сезнең оныкларыгыз, сезгә карата шушындый мөнәсәбәттә булса, ни әйтерсез, ә?- дип сорадым үзләреннән.

Алар эндәшмәде. Ә минем башыма, нигәдер, “бер буында табигать ял итә”, дигән әйтем искә төште.

## ТУГАН ҖИРЕМ – ГАЗИЗ ЯГЫМ

(публицистика)

*Галләмова Эльвина , Башкортостан республикасы Дүртөйле районы*
*Иванай урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Әхмәтова З.Ф*

*Кайдан соң башлана туган җир?*
*Беренче тамылган каныңнан.*
*Ә кайдан эз ала озын юл?*
*Беренче атлаган адымнан.*
*Хисами.*

Әй, Туган җир, Туган җир!.. Сахраларыңны ерып чыга алмаслык, яшел болыннарыңның иге-чиген күрә алмаслык, шифа суларыңны эчеп туя алмаслык газиз Туган җир! Шул изге җирдә гөрләп яшәүләргә ни җитә?!

Туган як, туган ил, туган җир һәммәбезгә дә якын, кадерле һәм мөһим. Һәр кешенең күңел түрендә җан тартып торган шундый җир почмагы урынлашкан. Ул безгә ямь, дәрт, көч өләшеп тора. Минем туган җирем – гүзәл Башкортостан. Аның матурлыгына сокланмаган кеше юктыр: горур Урал таулары, ямьле Дим һәм Агыйдел буйлары, киң далалар, куе урманнар... – кыскача әйткәндә, оҗмах бакчасы. Мондый искиткеч матур җирдә туып-үсү – үзе бер бәхет һәм мин, республикабызның башка яшәүчеләре белән беррәттән шушы бәхеткә лаекмын.

Минем кече туган җирем – Дүртөйле районында урнашкан Яңа Биектау авылы. Ул гүзәл табигать кочагында урын алган: бер яклап куе нарат урманы, бер яклап биек һәм горур Таштау, бер яклап – бормаланып аккан Агыйдел елгасы. Ул урманнарда төрле-төрле җәнлекләр яши, җәй һәм көз монда бик күп татлы җимешләр, шифалы үләннәр һәм тәмле гөмбәләр җыеп алырга була. Авылыбыз мондый яшеллеккә торенгәнгә күрә, һава бик саф һәм чиста, аны сулаган саен күңелгә рәхәтлек кереп урнаша. Таштау тавы исә бик күп серле риваятьләргәторенгән. Авылдашлар сөйләвенчә, аның иң биек ноктасында урнашкан урман-

яланлыклардан бернәрсә дә алып кайтып китеп булмый – кеше шул ук вакытта адаша, диләр. Ничек кенә булмасын, Таштау елның һәр мизгелендә дә матур: кышын ул ап-ак юрганга төренеп йокыга тала сыман, җәен ямь-яшел булып дөрләп утыра, ә алтын көздәтөрле төсләргә кереп күзнең явын ала. Ә инде бөтен республикабыз буенча тулып аккан гүзәл Агыйдел турында сөйләп торасы да юк! Аның буйларында үткәргән кичләр, суларыннан үткән пароход һәм теплоходлар, җәен җылы суында коенган көннәр...

Без нинди генә җирләрдә йөрсәк тә, нинди генә матур илләр күрсәк тә, безне һәрчак туган илебез, туган җиребез үзенә тартып тора. Әлбәттә һәр кешенең туган җире туган йорттан башлана. Монда без нәни чактан ук ата-ананың җылы кочагына сыенып үсәбез. Тора-бара,үскән кошчыклар канат каккандай, безгә дә җылы учагыбызны – туган нигезне, әти-әниләрне калдырып олы тормыш юлына аяк басарга вакыт җитә. Ләкин гомеребезнең нәкъ шул өйдә үткән мизгеле безгә зур тәэсир, йогынты ясый. Туган як турында сүз барганда, һичшиксез, тел турында да онытмаска кирәк. “Иле барның – теле бар”, диеп юкка гына әйтми халык мәкале. Туган илгә, туган телгә булган караш, хөрмәт һәм мәхәббәт тә гаилә эргәсендә тәрбияләнә. Безнең гаиләбездә дә туган телгә татар теленә карата хөрмәт бик зур. Без үз ара ана телебездә сөйләшәбез, үз телебездә җырлар тыңлыйбыз.

Җир йөзендә яшәгән һәр кеше үзенең Кеше булып җитлегүенә өч нәрсәгә бурычлы: Туган җиренә, туган теленә һәм әти-әнисенә. Шуны онытмыйча, аларны саклап, яратып, хөрмәт итеп туган җирләребездә гөрләшеп яшәргәдә яшәргә иде безгә!

## ТӨНБОЕК

(әкият)

*Гараев Алмаз, Алабуга шәһәре 4 нче гимназиянең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Айдашева К.А.*

Борын-борын заманда яшәгән ди бер Су патшасы. Барлык диңгезләр, елгалар, күлләр аның патшалыгына кергәннәр. Су патшасының бик матур Төнсылу исемле кызы булган. Төнсылуның чибәрлегеннән диңгез өсте көндез дә, төнлә дә җем-җем итеп торган.

Су патшасы кызына төнлә диңгез өстенә чыгарга кушмаган. Көннәрдән бер көнне Төнсылу әтисенең сүзен тыңламаган һәм диңгез өстенә чыккан. Зәңгәр күктәге йолдызларны, айны күреп ул шаккаткан.

Су патшасы кызының бу эшен сизеп алган һәм аны күл суына җибәргән. Качып китмәсен өчен су үләннәренә аны сакларга кушкан. Су үләннәре Су патшасыннан бик нык курыкканнар һәм Төнсылуның билен урап алганнар. Төнсылу боеккан һәм кайгысыннан төнбоек чәчәгенә әйләнгән.

## САКСЫЗЛЫК БӘЛАСЕ

(әкият)

Яшәгән ди, булган ди уенчыклар дөньясы. Алар үзара бик дус һәм тату яшәгәннәр. Тик Шар гына алардан аерылып торган. Ул үзенең матурлыгы белән масайган. Шар көннәр буе салмак кына искән җилдә очып йөргән.Теләсә һавага күтәрелгән, теләсә җиргә төшкән.

Башка уенчыклар аңа сак булырга киңәш биргәннәр. Ләкин Шар аларның киңәшләренә игътибар итмәгән. Минем матурлыгымнан көнләшәләр дип уйлаган.

Менә беркөнне каты давыл чыккан һәм Шарны бик еракларга очыртып алып киткән.Җил-давыл тынган,табигать тынычланган.Шар үзенең агач ботакларына эленеп калганын сизгән.

Шар шартлаган һәм инде бервакытта да һавага күтәрелә алмаган. Менә шушы вакыйгалардан соң сак һәм дус булырга кирәклеген онытмаска кирәк.

## УРМАН ҖЫРЫ

(әкият)

*Гарипова Элина, Әлмәт шәһәре 13нче урта мәктәбенең 10нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гарипова А.Ш.*

Урман аланында кечкенә генә Чикерткә яшәгән. Ул бик кызыксынучан булган.

Көннәрдән беркөнне ул йокысыннан торып, урман аланы буйлап йөрергә киткән. Кыңгырау чәчәккә сикереп менгән һәм тынып калган. "Нинди матур тавыш! – дип уйлаган ул эченнән. - Истә калдырырга кирәк!" Кинәт кенә җил исеп куйган һәм янәшәдә үскән кыңгырау чәчәге бик матур тавыш чыгарган: "диң-диң". "Бик кызык бит бу!" – дигән Чикерткә һәм икенче чәчәккә сикергән. Ул чәчәктән "доң-доң" дигән тавыш ишетелгән. "Диң-доң" – ничек матур яңгырый!!!

Ул алга таба киткән. Алан уртасында Куянкай утыра һәм агач төбенә тәпиләре белән суккалый икән: "тра-та-та-тра-та-та". Чикерткә уйга калган. Аннан соң чәчәкләр һәм Куянкай чыгарган авазларны бергә кушкан: "диң-доң-тра-та-та". "Бик матур авазлар кушылмасы!" – дип уйлаган Чикерткә.

Төшкә таба ул арып, агач төбенә ял итәргә яткан һәм бүген ишеткән авазларны исенә төшергән: "диң-доң-тра-та-та". "Барыбер нәрсәдер җитми!"- дип уйлаган Чикерткә һәм йокыга талган . Шулвакыт ул төш күргән. Төшендә агач ботагына утырган Сандугачның бик матур җырын ишеткән: "лә-лә-ләәә". Чикерткә уянып киткән һәм барлык авазларны бергә кушкан: "диң-доң-тра-та-та-лә-лә-ләәә".

Икенче көнгә ул аланга җилне, кыңгырау чәчәкләрен, Куянкайны һәм Сандугачны чакырган. Чикерткә аларга шушы авазларның барысын бер вакытта ишетергә теләвен әйткән. Җил исеп куйган, кыңгыраулар шалтырый башлаганнар, Куянкай тәпиләре белән агач төбенә суккалаган, Сандугач үзенең матур җырын сузган. Бик матур җыр килеп чыккан! Бу җырны тыңларга бөтен урман җәнлекләре, кошлары җыелган һәм кояш батканчы тыңлаганнар.

## ЯДКЯРЛӘРДӘ ТУКАЙ РУХЫ

*Гарифуллина Алинә Казан шәһәре 71 нче урта мәктәбенең 11 нче сыйныфы укучысы*
*Җитәкче: Кашапова Р.Р.*

Тынып калган шаулы Шамил йорты,
Гомер кичкән монда күп буын.
Салмак кына атлыйм баскычлардан.
Иңнәремдә тоям Тукай кулын.
Әйтерсең лә, Тукай музей буйлап
Сәяхәткә дәшә үземне.
Тукай рухын тоеп ядкярләрдән
Ала алмый карыйм күземне.
Балачактан моңсу караш ташлый
Милләтемнең бөекТукае.
Җиде буын мулла нәселенең
Тома ятим калган сабые.
Авыл өе, сәке, кашагалар,
Заманына күрә уенчык...
Әнкәсенең моңлы тавышына
Тирбәләдер сыман тал бишек.
Алга атлыйм, инде Тукай мине
Каршы ала бөек Җаекта.
Иңнәренә канат куйган "Мотыйгия"

Юлдашаңа олы тормышта.
Ятим Апуш хәзер ялгыз түгел,
Каләм аның изге юлдашы.
Гасырларга даны таралачак
Иҗатының, Җаек – юлбашы.
Ләкин хыялының иң изгесе:
Рухимәккә – Казан каласы.
Көндек каны тамган туфрагына
Җаны тарта адәм баласын.
Алга атлыйм, каршы ала мине
Урамнары шәһри Казанның.
Ядкярләрдә аерым урын били
Шәхси түбәтәе Тукайның.
Габдулланың җан җылысын тойган,
Бар әйбердә монда кадерле.
Юл кәрзине, фаянс тартмачыкта
Яңарталар кабатхәтерне.
Каләмдәше Әхмәтгәрәй бүләк иткән
Җиң каптырмаларының көмеше,
Петербургка баргач, сатып алган
Карандаш һәм кара савыты.
Вафатыннан соң,  нурлы йөзләреннән
Төшереп алынган гипс битлеге-
Тукай музееның кабатланмас,
Иң кадерле затлы ядкяре.
Чын сәяхәт кылам Тукай сукмагыннан:
Кушлавычы,  Өчилесе, Кырлай,
Арча өязенең Каенсары
Кочак җәеп  мине каршылый.
Диварларда Тукай рәсемнәре,
Бәләкәйдә, бераз үсмердә.
Татар әдәбиятының йөзек кашы
Дан-шөхрәтле бөек шагыйрьдә.
Ботак кеби бармаклары белән
Шаяртмакчы була Шүрәле.
Кеше әйберенә тию язык диеп,
Су анасы читтән шелтәли.
“Кәҗә белән сарык”, “Кисекбаш”ы
Хәтерләргә тирән уелган.
Нечкә лирик, публицист һәм сатирикның
Иҗат җимешләре куелган.
Тукай рухын һәрбер ядкяр саклый,
Моң, сагышка төреп тормышын.
Гасырларны кичеп барыр гасырларга
Аянычлы ачы язмышы.

## ТИЗДӘН ЯЗ КИЛЕР

*Гарифуллина Алия, Әлмәт шәһәре 17нче урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Ибраһимова Г.Ә.*

Өй кыегыннан ярышып,
Тама башлар тамчылар.
Елгаларны тутырып,
Агар язгы ташулар.

Кошлар да җырын сузар
Тирә якны күмдереп,
Яз безгә килеп җитәр,
Шау чәчәккә төренеп.

## ҖӘЙЛӘР ҖИТӘР

Җәй житкәч тә тирә ягым
Яшел күлмәген кияр.
Хуш исен безгә таратып,
Бакчада җиләк пешәр.

Күбәләкләр уйнап очар
Тугайларда, кырларда
Җәйге моңга кушылырлар
Барча җырчы кошлар да.

## БАБАМ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

*Гарифуллина Лия, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Хәйруллина Ә.С.*

Кайгы агач башыннан түгел,
Адәм башыннан йөри.
Язмышлары нинди буласын
берәү дә алдан белми..

Эх, бу язмыш дигәннәрең... Бер дә, адәм баласы уйлагандай, шома гына бармый икән лә ул тормыш арбасы. Кайчакта тәгәрмәчләр дә күчәрләреннән чыгар булып калтырыйлар. Кызык, никтер тормыш “арбасы” дип әйтергә яратабыз. Кемдер тормыш “бал түгел” - дип тә куя. Ник бал булмасын, балның нинди әле! Иң югары сыйфатлысы! Күпләр минем бу фикеремә аптырап карар, яисә кире кагар, кемдер бәлки килешер дә... Ник дисезме? Ә мин хәзер үз сүзләремне нигезләп язып карыйм әле. Шуннан үз нәтиҗәгезне ясарсыз.

Бер карашка, бал – бик татлы тәгам, авызга кабу белән эри дә үз юлын дәвам итә. Ә икенче яклап карасак, минем бабам әйткәнчә, яхшы бал тамак төбен кычыттырып, үзеннән соң үзенчәлекле әчкелтем тәм калдырырга тиеш. “Балның аның “самый татлысы шундый”, – дип әйтергә бик ярата иде ул. Әйе, тормышның әчесен-төчесен татыган кеше, минемчә, ялгыш фикер әйтмәс. Авырлыкларны җиңәргә, кеше булып калырга өйрәтә, акыллы киңәшләрен һәркемгә өләшә иде. “Әй, олан, яшь шул әле син. Гомер әле моның белән генә чикләнми, алда әле үтәсе юлларың. Син бирешеп, дошманнарыңны гына сөендерәсен, ник кирәк сиңа аларны куандыру? Бәхет-шатлык өчен адәм баласына Аллаһ тарафыннан башка нигъмәтләр дә бирелгән. Иң главные, балам – тазалык ул. Сабыр булырга өйрән. Бабайлар да “сабыр төбе – сары алтын” дип, сабыр булырга өндәгәннәр. Һәр нәрсәнең азагы бар аның, берни дә мәңгелек түгел. Авыр чакларың да узар, Алла боерса!”.

Җәй айларын, бигрәк тә җиләкле июньне сөя иде бабам. Печән чабарга барса, үзе белән һәрчак савыт ала, малларына да чалгы белән җиләкне чабып алып кайтып сыйлый иде. Урман-кыр, басу-тауларга җаны-тәне белән гашыйк башка андый кешене әлегә очратканым юк. Яшен дими, яңгыр дими, гел басуда була иде.

Ул көнне дә бабакай белән тау буйларын карап кайттык. Кояш иртәдән үз хезмәтендә – бик челлә көн иде. Бабам: “хәерлегә булсын инде, бигрәк кыздыра бүген кояш”, – дип уфтанып та куйды хәтта. Көн төшкә авышканда, һич көтмәгәндә, куе кара, калын-калын болытлар килеп, кояшны капладылар. Аксакалның сүзләре дөреслеккә туры килде: көчле давыл купты, күк йөзен яшен камчысы телгәләде, чиләкләп-чиләкләп бозлы яңгыр койды. Әлеге мәхшәр ничек тиз башланган булса, шулай узып та китте, яңадан елмаеп кояш чыкты. Яшелчәләрне карарга дип, бакчага чыккач, шактый зыян килүен күрдек. Бакча башыннан кечкенә елга ага, ярында ни гаҗәп, борынгы имән баһадирдай басып тора. Бабам шул тарафка карады да сүзен башлады. “Әйе, балам, гаҗәп инде бу дөнья, ис-акылың китәрлек. Әнә, кара, бер сәгать эчендә ниләр булды да куйды. Йә, ни әйтерсең? Шулай шул, балам, сүзсез калдың. Тормышта да шушы сәгатьтәге кебек. Күз сал әле әнә теге имәнгә. Бая давыл аны дөнья йөзеннән юк итәргә тырышты. Меңйәшәр имәннең ботакларын сындырган. Сындырган, балам. Тик имән тулысынча бирешмәгән бит, кәүсәсен, эчен саклап калган. Ә аның эчендә үзе бер дөнья яши бит. Кошлар, бөҗәкләр дөньясы, дигәндәй. Тормыш булгач, төрле чаклар булыр. Авырлыклар белән күзгә күз очрашканда, исеңә менә шушы имәнне төшер. Син аның төсле нык бул, рухыңны сындырма, иманыңны җуйма, балам. Имәнне табигать җиле сынады, сине язмыш җилләре сынар. Егылсаң да, торып басып, тормыш дилбегәсенә ябыш. Әйе, дилбегә синең кулда, син аны кай тарафка борсаң, язмыш яты да шул тарафка юл тотар. Һай, карале син аны, сөйләгән сүземнән ерак кителгән бит. Хәтер иске шул инде, иске. Әйе, әнә нинди куркыныч давылдан соң да елмаеп кояш чыкты, табигать җанланды. Бозлы яңгырдан зыян күргән яшелчәләр дә тернәкләнер, Алла боерса. Кеше дә шулай авырлыклардан көч туплап, яңадан аякка басарга тырышырга тиеш. Бер урында тик утырсаң, яисә таптанып торсаң, тормыш туктый, яшәү мәгънәсен югалта... Дөньялар тыныч булсын, балам, башка авырлыкларга тез чүкмәбез, ничек тә михнәт чытырманлыгын аралап чыгарбыз. Әй балам, балам, без күргәнне сезгә язмасын инде. Сугыш, кан коешлар булмасын, балам..”

Мең тугыз йөз кырык беренче елның егерме икенче июне. Ямьле җәйнең башка көннәреннән әллә ни аерылмый торган яңа көн туып килә. Авыл, аның тирә-ягы татлы йокысыннан уянып, күзләрен ача. Елга ярында яңа савылган сөттәй җылы томан да әкренләп тарала башлады. Әрәмәнең төнлә дә тынып торганы юк, инде сайрар кошлар тагын да җанланыбрак моңлы көйләрен суза башладылар. Таң алдыннан гына яңгыр явып, елга ярындагы мал тоягы эзләренә кечкенә күлләвекләр җыелган. Махсус урын диярсең, кечкенә кошчыклар шунда килеп, рәхәтләнеп су коендылар. Уңган бал кортлары инде иртә таңнан эштә, бер-бер артлы туган йортларыннан чәчәкле болынга бал җыярга таралышытылар. Чыклы үлән арасында чыштыр-пыштыр кәлтәләр, ниндидер бөҗәкләр дә уянып, иртәнге хәрәкәтне башладылар. Ис-акылың китәр бу табигатьнең хозурлыгына!

Дөнья шулай әкренләп яңа көнгә аяк баскан чакта, зар белмәс уңган хатын-кызлар, иртәнге савымны төгәлләп, терлекләрне көтүгә озаттылар. Күрше-күлән капка төбендә җыелышып, яңалыкларын бүлешеп, елмаеп көлешеп алдылар. Җәйге кояш бик җитез бит ул, офыктан сөңге буе күтәрелеп өлгермәс борын үз көчен күрсәтә башлый. Шуңа да ир-атлар иртәнге суык белән үк болынга, урман-кырларга печән чабарга таралыштылар. Тирә яктагы тугай-болыннар чалгы-кайрак чыңыннан, егетләрнең арысландай тавышларыннан дулкынланып торды. Табигатьтә җәй булган кебек, әлеге егетләрнең дә тормышлары чәчәк атып кына килә. Күбесенә уналты, өлкәнрәкләргә унсигез, егерме яшь.

“Алдагы көннәрдә һава торышы ничек булыр? Кояшлы көн торса, бик әйбәт булыр, пакуслар яхшылап кибәр иде. Яңгыр булса нишләрбез, печәнгә дым нык үтмәс микән?”

Авыл баласы авыл баласы шул инде. Аның канында авыл каны ага. Әле Яңа ел алдыннан гына уналтысын тутырган Яхъя да гап-гади авыл баласы. Шушындый уйлар белән чалгысын кайрый башлаганда, кинәт колхоз радиосы тавышы ишетелде. Колагына тик бер сүз кереп калды. “Сугыш”... Аяз күкне яшен суккандай, халык беравык аптырап калды. Нишләргә? Кая барырга? Ни булыр, безне ни көтә? Сораулар бик күп бөтерелсә дә, җаваплар табылмый торды. Район комиссариаты җавапны бик тиз тапты. “Барлык сугышка яраклы ир-атларны, яшенә-картына карамый, фронтка озатырга!” Унҗидесе тулмаган бабам да үз теләге белән сугышка китә.

Менә шул сугыш дигән кара афәт әчесен-төчесен биреп сыный да инде яшь егетне. Сталинградны дошман тырнагыннан азат итү өчен көрәш вакытында каты яраланып, госпитальгә эләгә. Сугышка типсә тимер өзәрдәй булып китә дә, инвалид булып кайта. Снаряд кыйпылчыклары аның эчен һәм уң кулын яралаган була. Госпитальдә бер ай чамасы дәваланганнан соң, яңадан явыз фашист гаскәрләренә каршы китә. Дошман тарафыннан шактый зыян күргән, тар-мар ителгән авыллар, кан-мәет тулы сугыш кырлары аша уза. Бабамның фикеренә әйләнеп кайтмый булдыра алмыйм. “Һәр нәрсәнең, шул исәптән авырлыкларның да бер чиге була, түземлек кенә кирәк.” Әйе, Совет гаскәрләре дә әлеге канкойгыч сугышка нокта куеп, Бөек Җиңү алып кайталар, җиң сызганып, илне яңарта башлыйлар.

Бабам да үзен инвалид дип тормый, колхоз эшенә керешә. Басу-кырларны, урман-тауларны җаны-тәне белән сөйгән, җир кешесе булган уңган егетне кешеләр белән ачык күңелле булганы өчен бригадир итеп сайлыйлар. Тормыш шулай әкренләп үз юлын дәвам итә. Әйе, вакыт алга бара, тик бабабыз гына безнең арада юк.

Тән яраларын вакыт дәвалый диләр, тик җан ярасына шифа юк. Сугыш кешеләргә тән яралары белән төзәлмәс җан ярасын китергән, күпме яшь йөрәкне кыйган, балалар ятим калган, илгә никадәр зыян салынган. Бихисап аналардан газиз балаларын тартып алып, йөрәкләрен телгәләгән. Бөек Ватан сугышы вакытында һәр йортка диярлек өчпочмаклы кара хат килгән. Бу хатларны әлеге көнгә кадәр саклаучылар бар. Алар гүя яшь буынга тынычлыкның кадерен белергә, якын кешеләрне кадерләргә өнди.

Инде илебезгә аяз күк йөзен бүләк иткән геройларыбыз да бик аз калып бара, аларны хөрмәтләп, ярдәм итеп яшәсәк иде. Без бәхетле буын. Беренчедән, андый сугышларны күрмәдек, икенчедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарын күргән соңгы буын вәкилләре бит без, егерме беренче гасыр яшьләре.

## АВЫЛ БАЛАСЫ МИН

*Гарифуллина Лия, КФУ ның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Нуриева А.Р.*

Гади генә авыл баласы мин,
Туган ягым – таулар арасы.
Күңел кылларымны моңлы иткән
Шифа тулы авыл һавасы.
Күңелемнең илһам чыганагы –
Урман-кырлар, елга буйлары.
Басыладыр хисләр, уйларым
Җәяү кайтсам басу буйлатып.

Йөгереп каршы чыгар балачагым
Чана шуган Тегермән тавыннан.
Тынар шул чак күңелем бураннары

Авыз итсәм чишмә суыннан.

## САГЫНУ

Үткән чакта басу капкасыннан,
Сез чыгарсыз кебек каршыга.
Сез бит һаман исән кебек әле,
Йөрисездер безнең арада...

Еллар узып, вакыт аккан саен,
Күңел сезне ныграк сагына.
Очып үтеп ике дөнья чиген,
Йөрәк күрешүгә ашкына.

Вакыт үткәннәрне оныттыра, диләр
Вакыт узгач табыла дәвалар.
Сезне югалту ул безнең өчен –
Мәңге төзәлмәс, җуелмас яралар.

Эх, якынайтып булса араны,
Кайтып булса узган вакытка.
Йөгереп барыр идем сезнең каршыга
Йөрәк әрнүләрем басарга.

Күңел ышанмый, вакыт узса да
Фани дөньядан сезнең киткәнгә.
Әле дә бер кайтырсыз кебек
Өмер биреп булмый йөрәккә.

Юк шул, анда бер киткәч,
Кире кайтыр юллар юк.
Җырлана бит җырларда да:
“Җир астыннан юллар юк”.

Кайтып башка күренмәсәгез дә,
Яшисез хәтер-күңелләрдә.
Мин ышанам, мин көтәм ул көнне –
Күрешербез әле, күрешербез, бәлки, төшләрдә..

## АБЫЕМА

Ни булса да янәшәмдә,
Һәрчак бергә атлыйсың.
Язмыш җилләре иссә дә,
Бөркет сыман саклыйсың.

Шундый абыем булганга
Рәхмәт әйтәм язмышка.
“Сеңлем”, – диеп яратуың
Көч бирә бит тормышта.

Үч итеп чит-ятларга,
Көнләштереп дошманны,
Бергә үтик сынауларны,
Ычкындырмыйк кулларны!

Колак салмый гайбәт сүзгә,
Урын куймый низагка,
Тырышыйк без “абый – сеңел”диеп
Туганлыкны сакларга.

Ни буласын беркем белми,
Әти-әни түгел мәңгелек.
Тормыш борылышларында безгә
Ярдәм итәр бердәмлек.

## ИСХАКЫЙ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП…

*Гафурова Гөлия, Чирмешән лицееның 11нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Закирова Л.Р.*

Җәйнең эссе көннәре,
Күк йөзе матур, аяз.
Яуширмә болынында
Берүзе уйный Гаяз.
Болында берүзе булгач,
Чумды тирән уйларга.
Шуңа күрә әкрен генә
Юнәлде ул авылга.
Сихри авыл табигате,
Яшәешең, үткәнең
Нәни генә Гаязның
Тетрәтәдер йөрәген.
Ул шундый үткен малай
Сорау гына бир аңа
Белем, төпле сүзе белән
Һәркемне шаккатыра.
Күтәрү өчен милләтне
Күпме газаплар күрде
Яшәсә дә чит илләрдә,
Дошманнарны ул җиңде.
Онытылмас якты шәхес
Таң нурларыдай балкый
Шуңа да аның исеме –
Бөек Гаяз Исхакый.

## «СӨННӘТЧЕ БАБАЙ» ӘСӘРЕН УКЫГАЧ…

«Сөннәтче бабай»ны укыйм да
Күңелемдә хисләр туа,
Шул бабайның сабырлыгы
Нинди китапка сыя?!

Ул инде өлкән бабай
Торагы да искергән
Өй янындагы һәммә нәрсә
Искелекне сеңдергән.
Ул бер үзе яши бирә,
Бар эшен эшләп бара:
Иртүк торып суга бара,
Миләше озатып кала.
Каршыдагы миләше дә
Үзе кебек картайган.
Кояш нурын йота-йота
Миләшләре кызарган…
Суынган бит аркасы
Калгач ялгыз башкае
Алса да башка хатын
Тынмаган шул җанкае.
Әби һичтә уңмаган
Өйрәнгән ул әзергә
Тоткан сөннәт пәкесен
Бәрәңгене әрчергә.
Күргәч шушы хәлләрне
Күтәрмәде йөрәге;
Үзе казыган гүргә
Халык аны җирләде…
Урам балалары йөри,
Миләшләргә кызыгып.
Каршы төптән үткәндә
Карыйлардыр борылып.
Үлсә дә үзе бабай,
Һәрнәрсә үзенә тарта;
Аның сихри агачлары
Дөньяны матурайта.

## МИНЕМ ГҮЗӘЛ ШӘҺӘРЕМ

*Гаффарова Алсу, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Хәйруллина Ә.С.*

Алабуга каласы
Бик борыңгы шәһәр ул,
1000 еллыгы булса да,
Тагын мең ел яшәр ул.
Иске-иске биналарың
Хәтерләтә бик күпне.
Ак мәчетең басып тора
Саклап, ни кадәр серне.
Килер шундый бер матур көн,
Ачарбыз һәр бер серен.
Гүзәл шәһәрне күрергә
Ашкынып торыр һәр кем.

## АНА

*Гәрәева Алинә, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Саттарова Г.Г.*

Бу дөньяда һәр баланың
Киләдер ул әни диясе,
Һәр ананың кешенекен тугел,
Үз баласын килә сөясе.
Үз сабые өчен кайгырасы ,
Сөю шатлыгында көясе,
Баласының куңел хәлен аңлап,
Ул яраткан төсне беләсе.
Дөрес түгел сүзләр өчен орышасы,
Ялгышлары өчен сүгәсе,
Авыр чакта таянычын сизеп,
Кочагына алып үбәсе.
Килә иртән назлап уятасы,
Иртәнге аш,чәйләр куясы,
Сабыеның моңа рәхмәт әйтеп,
Яратуын аның тоясы.
Әкият укый-укый кулда йоклап китеп,
Урынына илтеп саласы,
Шул вакытта аның көчсезлеген тоеп,
Тимер рәшә килә коясы.
Бала белән бергә ананың да,
Килә сабый чакка кире кайтасы
Дөрес тугел сәгать шалтырарга куеп,
Дәреслергә йоклап каласы.
Бала белән бергә ананың да,
Килә мәктәп елларына кайтасы,
Төнгә кадәр ой эшләрен эшләп,
Бишле, икелелэр аласы.
Инде картайса да, дөнья хәлен,
Сәгать буе килә сөйлисе,
Бишек жырын баласына тугел,
Оныгына килә көйлисе.
Һәр ял саен оныкларын көтеп,
Балаларын килә көйлисе,
Килә иртән коймак пешерәсе,
Жылы бияләйләр бәйлисе.
Хәлем авырайды,
Инде беттем дигәндә дә,
Килә янда бала тоясы,
Тик бу чакта кая баласы?

## УКЫТУЧЫМА!

*Герасимова Клара, Нурлат районы Урта Камышлы урта мәктәбенең*
*10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Абдулвалеева Г.И*

Кечкенәдән укырга өйрәткән,
Кечкенәдән язарга өйрәткән,

Кечкенәдән санарга өйрәткән,
Сез – укытучылар!
Сезне яратып тыңлаган,
Сезне хөрмәт иткән,
Сездән ярдәм сораган –
Без – укучылар.
Сезгә рәхмәтләр укып,
Сезгә шигырьләр язып,
Сезнең турында җырлар җырлап,
Мәңге туймастыр кеше!

## ЯЗМЫШ СЫНАУЛАРЫН ҮТКӘНДӘ
**(очерк)**

*Гильманова Фәридә, БДУның Стәрлетамак филиалы, 2 нчекурс студенты*
*Җитәкче: Мөкимова Н.Ә.*

*Карт әнием Гөлзифаның әтисе*
*Салишев Кәбир Мәүли улына багышлана.*

Егерме беренче гасырда яшибез. Туган илебездә тынычлык хакимлек итә. Моңа ирешкәнче халкыбызга ачлык-ялангачлык, революцияләр һәм сугышлар, җиңүләр һәм җиңелүләр аша үтәргә туры килә.

Күпләр белмәгән тарихлар һәм язмышлар да бар. Шуларның берсе – Салишев Кәбир Мәүли улының язмышы. Әтисе турында карт әнием сөйләгән бу тарих бәләкәй чакта миңа куркыныч әкият кебек тоела иде. Бабам үзенең авыр балачагы, гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы турында искә алырга яратмаган. Ә инде күңеле тулып, хатирәләр дулкыны ташканда, барысынбарлык нечкәлекләренә кадәр сөйләгән, боларның үткәннәрдә калуына шатланып күзләренә яшь килгән, бүгенге тыныч тормышка һәм якты кояшка сөенгән ул.

Минем бабам 1910 елда туган, картәтисе хөрмәтенә аңа Кәбир дип исем кушалар. Аның өч апасы һәм ике абыйсы була. Кәбирәгә җиде яшь тулганда, әнисе берьюлы өч сабыйга гомер биреп, үзе вафат була. Сабыйлар, әнисез дә булганлыктандыр инде, бер-бер артлы үлә. 1918 елгы гражданнар сугышында этиләре дә һәлак була. Әти-әнисез калган балаларга бик авырга туры килә, өлкән дигәннәренә дә ул вакытта нибары 15 яшь була. Алар Үзбәкстандагы ерак туганнарына китәргә карар итәләр. Балаларны бөтен авыл диярлек озата, чөнки эти-әниләрен уңган, кунакчыл, ярдәмчел, кешеләргә карата әйбәт мөнәсәбәттә булулары өчен авыл халкы бик хөрмәт иткән.

Юл бик ерак була... Кәбиргә поезд тәрәзәсеннән карап бару ошый: агачлар, өйләр, баганалар артта кала. Бер тәүлектән соң хәле начараеп аңын югалта... Проводниклар аны үлгән дип уйлый, шуңа күрә балаларны төшереп калдырырга телиләр, ләкин ятимнәргә мәрхәмәтлек күрсәтеп, өлкәннәрен калдыралар, һәм алар Ташкентка исән-сау барып җитәләр,ә аңын югалткан кечкенәләрен юл буендагы станцияләрнең берсендә эскәмиядә калдырып китәләр.

Бу дөнья изгелекле кешеләрсез түгел.. Яхшы кешеләр сигез яшьлек баланы дәваханәгә илтәләр. Кәбир алты көннән соң ак дивалар арасында һәм зур тәрәзәле бүлмәдә аңына килә, аны ак халатлы табиблар карый. Күзен ачканда, аңа мәчет картлары сөйләгән оҗмахка эләккәндәй тоела. Шәфкатьле, үз эшен оста белгән Сергей исемле табиб аякка басарга ярдәм итә. Табибның хатыны Екатерина – изге күңелле шәфкать туташы, кара күзле кечкенә малайны шундук үз итә.

Сергейның гаиләсе зур өйдә, җитеш тормышта яши. Тик аларның балалары булмый. Балалардан башка бәхет буламы инде?! Сергей белән Екатерина Кәбирне уллыкка алырга карар итә.

Малайны биек, якты өйгә алып кайталар. Табын әзерләнгән түгәрәк өстәлдә нинди генә ризык булмый: ак икмәк, сөт, яшелчә-җимеш... Өй янәшәсендә җиләк-җимеш агачлары һәм төрле яшелчәләр үскән зур бакча... Баланың гаҗәпләнүенең чиге булмый. Бу гаиләдә Кәбирне үз балалары кебек яраталар. Өйгә укытучы чакырып, укырга һәм язарга өйрәтәләр. Кәбир бик тырыш һәм зирәк булуына, чәчләренә чал кунган карт укытучы бик канәгать була, ә Сергей белән Екатерина уллары белән горурланалар. Яңа гаилә малайга бик ошый, әмма үз эти-әнисе, туган ягы еш кына төшенә керә. Авылының гүзәл табигате аның күз алдыннан китми. Кәбир этисе белән утынга баруын, абыйларының печән чабуын исенә төшерә.

Шулай өч ел үтеп тә китә... Сергей белән Екатерина тәрбиягә алган улларының христиан динен кабул итүен тели, әмма аларга күршеләре –мөселман кешесе комачаулый, һәрвакыт Кәбирне күргәндә ул аны чит динне кабул итмәскә, ә үзенең туганнары янына кайтырга үгетли.Тагын берничә ай үтә... Кәбир күзгә күренеп үзгәрә, үз-үзенә бикләнә. Ата-ана моны күрә, әлбәттә, тик эшнең нидә икәнен аңламыйлар, һәм Кәбирне туганнарына кунакка җибәрергә булалар. Әйберләрен җыеп, акча бирәләр, күп итеп күчтәнәчләр салалар. Кәбирне махсус ялланган кеше юлның буена озатырга тиеш була, әмма ул, баланы поездга утыртып, акча һәм күчтәнәчләр белән юкка чыга, ә Кәбир билгесез юнәлештә китә...

Кәбир үзенең соңгы тукталышта поездтан чыгарга тиешлеген генә белә. Поезд билгеләнгән урынга килеп җиткәч, ул күзе күргән якка карап китә. Юл аны чуваш авылына алып килә. Ул шунда калып, ялланып эшли башлый: утын кисә, көтү көтә, мал карый. Алты ел үтеп китә... Кәбир инде өлкән ат караучы булып эшли. Көннәрнең берсендә аны күрше авылга тегермәнгә җибәрәләр. Монда аңа һәр нәрсә: табигать тә, кешеләре дә ничектер таныш тоела. Авылда аны күргәч, олы абыйсы Солтанга охшаталар. Чынлап та, Кәбир туган авылына килеп чыга, ничә ел якында гына, туганнарыннан берничә чакрым ераклыкта яшәгән була...

Шулай итеп,Кәбир туганнарын һәм якыннарын таба. Ул үзенең туган авылы Айтуганга кайта, анда аны җылы кабул итәләр. Сергей белән Катерина биргән белем аңа тормышта бик кирәгә. Карт әтием эшен гадел башкара һәм тормышта күп нәрсәгә ирешә. Аны бригадир итеп тәгаенлиләр, тырышлыгы һәм хезмәт сөйгәне өчен күп тапкырлар Почет грамоталары белән бүләклиләр.

1929 елда авылның иң чибәр, акыллы Хафизә исемле кызына өйләнә ул. Ныклы гаилә барлыкка килә. Анда дүрт малай һәм бер кыз (минем карт әнием) туа.Барысы да үз чираты белән бара, балалар үсә, йорт-хуҗалык мул була, тик көнләшеп яшәүчеләр, аңа яла ягып, халык дошманы дип, 1939 елда төрмәгә утырталар. Кечкенә балалар белән хатыны өйдә япа-ялгыз калалар.

1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башлана... Ә карт әтине 1943 елның 10 маенда азат итеп, Айтуганга кайтаралар. Ул авылда гаиләсе янында бары ике көн генә торып өлгерә, аны фронтка алалар. 1945 елга кадәр ул миномент полкы составылда машина йөртүче булып хезмәт итә.

Тылда аны хатыны һәм биш баласы көтә. Аларга да күпләр күргәнне күреп, күпләр татыганны татып яшәргә туры килә. Бу елларда халыкка ничек кыен булуын күз алдына китерүе бик авыр: 10 яшьлек балаларга басуларда эшләргә, үлән чабарга, ашлык җыярга туры килә, ә кышын урманга утынга барырга һәм һәр көн яшәү өчен көрәшергә кирәк була. Карт әнием иртәдән төнгә кадәр колхозда эшли. Барлык мәшәкатьләргә карамастан, җылы оекбашлар, бияләйләр бәйләп фронтка озатырга да вакыт таба. Һәр хатын-кыз ирләренең, улларының, егетләренең исән-сау кайтыуна, ә сугышның тиздән тәмамлануына өметләнә. Әтиләренең кайда сугышканын балалар бик сирәк килгән хатлар аша гына белә. Шушы өчпочмаклы хатлар әниләр, хатыннар һәм балалар өчен бик зур байлык була. Дәһшәтле сугышта аларның якын кешеләренең исәнлеге турында хәбәр алудан да яхшырак нәрсә булды микән?!

Карт әнием өйләрендә кечкенә агач шкатулка булуын, анда әнисе хатлар, фоторәсемнәр, гәзитләрдән кисеп алынган язмалар, шулай ук чигелгән кулъяулыклар саклавын сөйләде. «Шул әйберләрне карап утырганда, ул күз яшьләрен тыя алмый иде, мәрхүм», – дип сөйләде карт әнием.

Ул чорда тормыш коточкыч була, чөнки сугышта өлкәннәр дә, балалар да һәлак була, фашистлар өйләрне яндыра, шәһәрләрне һәм авылларны җир белән тигезли, үзләрен барысыннан да өстен куеп, дөнья белән идарә итәргә телиләр. Бөек Ватан сугышында миллионлаган кеше һәлак була, күпләре хәбәрсез югала, әмма туганнары һәм якыннары аларны бер дә онытмый...

Карт әтием Берлинны алуда катнаша. Сугышны үтеп, ул 1946 елның көзендә кайта. “Германияне җиңгән өчен”, “Батырлык өчен” медальләре һәм юбилей медальләре белән бүләкләнә.

Мин карт әтием белән горурланам һәм аңа Җиңү өчен зур рәхмәт әйтәм. Кызганыч, мин аны күрә алмадым. Карт әнием сөйләгәннәрдән аның олы йөрәкле кеше булуы турында беләм, кешеләргә карата мәрхәмәтлелеге буыннар аша безгә тапшырылган. Мин, аның оныгының баласы, горурланып әйтә алам: ул батырларча гомер кичергән, бар көчен илебез ныклыгы һәм иминлеге хакына биргән.

Сугыш еллары елдан-ел ерагая бара. Җиңү яулау өчен күпме кешеләр корбан була, кан коела, якыннарыбызның бәхетле һәм тыныч тормышы хакына башын салуын онытмаска тиешбез. Безнең ата-бабаларыз үз җирләре өчен, ил тынычлыгы, киләчәк буын өчен көрәшкән, шуңа күрә җиңгәннәр дә.

Без, XXI гасыр балалары, сугыш булуын теләмибез! Әгәр миңа бер теләк теләргә рөхсәт итсәләр, бер нәрсә – җир шарында тынычлык булуын теләр идем. Күреп торабыз бит, бүгенге көндә дә җир шарыбызның төрле өлкәләрендә кан коюлар бара... Сугыш булмаса, халыклар арасында дошманлык, югалтулар һәм җимереклекләр дә булмас иде...

Илебез имин һәм тыныч булсын!

## МИНЕМ ТУГАН АВЫЛЫМ

*Гильфанова Сөмбел, Зәй районы Түбән Биш урта гомуми белем мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Шиһабетдинова Г.Р.*

Җанга якын, күңелгә сихәт
Туган авылым-минем Ашытым.

Мин гади бер авыл кызы. Авылым Татарстанның Зәй районында урнашкан. Рәсми кәгазьләрдә Куш-Елга, ә халык телендә Ашыт дип йөртәләр минем туган авылымны. Элек авыл Кушнарат-Елга һәм Ашыт дип аталган. Авылга беренче булып Ашыт исемле кеше нигез салган, шуңа аны Ашыт дип атаганнар. Ә икенче исеме авылның югары очыннан ике елга агып килеп бергә кушылган урында ике нарат үсеп утырганга, Кушнарат-Елга дип атаганнар. Куш-Елга авылының күренекле кешеләре булып Шәхиморад Хәзрәт, Фәхретдин Таҗетдин, аның улы – Файзулла Хәзрәт саналган.

Авылда элек данлыклы Ашыт җыены үткәрелгән. Бу бәйрәм бүгенге көндә дә үткәрелә. Аңа бик күп кунаклар кайта. Бөтен гореф-гадәт, йолалар яңартыла. Елдан–ел зураеп, матураеп бара авылым. Хәзер Куш-Елгада ике йөздән артык йорт бар. Йортларның күбесе кирпечтән төзелгән. Өйләргә газ, электр, телефон да кергән. 1991 елдан Мөхәммәт һадый мәчете эшли.

Һәр авылның күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйлибез без. Безнең авылда да күренекле шәхесләр бар. Ә кемнәр белән горурлана алабыз соң без? Менә алар: профессор, математика фәннәре галиме Гамбир Мөбәрәкҗанов, данлыклы чөгендер

игүче, Хезмәт даны ордены кавалеры, II. III дәрәҗә, ВДНХ ның алтын медаль иясе Мәсгуть Гыйлфанов.

Авылымның табигатенә килгәндә, ул бик матур. Үзе шушы матурлыкны күрмәгән кеше моны бервакытта да аңламаячак. Тугызынчы майга сирень, шомырт куаклары чәчәк ата. Бу вакытта безнең авыл әкият бакчасына охшап кала, бакча башыннан ук аланлык башлана, якында гына җитез чишмә үзенең моңлы җырын җырлап йөгерә, ул бер дә арымый: кышын да, җәен дә, язын да, көзен дә каядыр ашыга да ашыга. Минем туган ягым урманнары төрле-төрле җиләк-җимешкә, гөмбәләргә, дару ясый торган үләннәргә бай. Аларны барсында курыкмыйча кулланырга мөмкин, чөнки алар саф һавада, кеше аягы басмаган җирдә үскәннәр.

Әйе, бик яратам мин авылымны, аның табигатен, кешеләрен. Күңелемне бетмәс-төкәнмәс горурлык хисе били. Мин үземне чиксез бәхетле тоям!

Авылымны бик яратам,
Үз авылым булганга.
Яшеллеккә күмелгәнгә,
Кошлар сайрап торганга.
Табигатьнең һәр фасылы
Авылымны матурлый.
Авылымның матурлыгын
Кошлар җырында җырлый.

## ИРТӘ ЯЗДА ГОМЕР КӨЗЕ

*Гиниятуллина Рания, Чистан районыТатар Талкышы гомуми урта белем*
*бирү мәктәбенең 10 сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Ярмушева Р.Р.*

Драма 4 пәрдәдә

Катнашалар:

Айдар – 14 яшьләрдә, 8 сыйныф укучысы
Илдар- 35яшьләрдә, Айдарның әтисе.
Галия- 34яшьләрдә, Айдарның әнисе.
Алия-Айдарның сөйгән кызы
Нәфис, Ильназ, Нияз- 14-15яшьләрдә, Айдар белән бер сыйныфта укыйлар.

### 1 нче пәрдә

*(Айдарларның өйләре,өй матур итеп җиһазландырылган. Канәфи, диван, шкаф, компьютер өстәле. Айдар күңелсез генә өйгә килеп керә. Ул борчулы уйлар ятьмәсендә бәргәләнә. Ашарга утыра, тамагыннан аш үтми, компьютерга утырып карый, анда да күңеле ятмый. Бүлмәдә ишекле-түрле йөренә.)*

**Айдар.** Ачы, зәһәр җилнең, өзгәләнеп елый-елый, сызгыруы да минем күңелемне елата. (Б*итләрен ике учы белән каплый*) Әйтерсең, мин каядыр барыннан да читтә, берьялгызым, үземнең шомлы уйларым белән генә. Менә хәзер, хәзер әбиемюатыр, минем кайгымны таратыр иде. Кызганыч, әбиемдә күптән гүр иясе шул. (*Әбисенең рәсеме янына килеп*) И әбием, син миңа шулкадәр кирәк. Әти белән әни көн-төн эштә. Аларның минем белән сөйләшергә дә вакытлары юк. Эштән бик нык арып кайталар, хезмәттән соң да тавык та чүпләп бетермәслек эшләре өчен борчылып, ни турындадыр бәхәсләшәләр. Алар улларының нинди уйлар белән янганын сизсәләр иде...(*Кинәт сикереп тора да урамга чыгып китә. Илдар белән Галия кайтып керәләр. Галия өсләрен чишенеп аш-су әзерләргә кереп китә. Кинәт кенә Илдар янына чыга.)*

**Галия.** Илдар, кара әле соңгы вакытта Айдар берни дә ашамый, эчми, еш кына өйдә дә юк. Нишләптер, эчем поша, ул баланың берәр нинди кайгысы юк микән.

**Илдар**. Нинди кайгысы булсын, 14 яшьлек егеттә билгеле инде, кызлар кайгысы. Бәлки Алиясе белән бераз үпкәләшкәннәрдер. Мәхәббәт утында янулары шатлык та, күтәрә алмастай бәхет тә бит.Үзеңнең яшь вакытыңны искә төшер әле. Кача-поса очрашулар, кош теле генә хәтле булса да, хат алышулар...

**Галия.** Әйе, анысы шулай инде. Мин дә сине берәр көн күрми торсам, ул миңа ел төсле тоела иде. Ә синнән хат-мазар алсам да, күкнең җиденче катында кебек хис итә идем үземне. Хәзер генә уйласаң көлке кебек. Ә безнең мәхәббәтебез нинди саф иде. *(Хыялга бирелеп җырлап җибәрә Илдар да аңа кушыла.)*

**Илдар**. *(Галиясен кочаклап ала)*. Матурым, без нинди бәхетле. Нинди акыллы улыбыз үсеп килә. Сокланып туялмыйсың. Бәхете бездән генә көнләшмәсеннәр.

**2 нче пәрдә**

(Айдар белән Алия икәүләп тыныч кына сөйләшеп утыралар).

**Алия**. Айдар, мин сине аңламый башладым. Син кем турындадыр уйлыйсыңмы соң. Башка берәр кызга гашыйк булып куймагансыңдыр бит? Ә мин гел сине генә уйлыйм, синнән башкага минем йөрәгемдә урын юк...*(Шаярып Айдарның муенына сарылып битеннән үбеп ала. Ә Айдар барысына да битараф.Әйтерсең аның янында Алия дә юк, ул бары тик үзе генә.)*

**Айдар.** Алия, син шундый бәхетле. Мин беркайчан да бәхетле булмаячакмын.Син беләсеңме, мин бит упкынга тәгәрим. Миңа моннан чыгу юлы юк. Бары тик үлем генә коткарачак. Бу ярты ел элек булган хәл. Мине беренче тапкыр иптәшләрем үз тиңнәре кебек араларына алдылар. Минем фикеремне тыңладылар. Мин дә алар белән тигез, мин дә беренче тапкыр спайсның тәэсирен татып карадым бит... Гәрчә аның зарарын бик әйбәт белсәм дә, башкалар белән бертигез, үз кеше буласы килү көчле иде шул ул чакта. Ә хәзер ни эшләргә? Мин дә алар арасында. Аннан чыгу юлы юк... Ә киләчәктә мине ни көтә? И Алиякәем, безнең бергә була алмавыбыз турында мин әллә кайчан төшемдә күргән идем.

**Алия**. *(еламсырап)* Син, ни сөйлисең, Айдар.

Син бит минем кояшым, ә кояшсыз яшәү мөмкинме соң? Әле соң түгел, әйдә әти-әниләреңә сөйлик тә, алар уллары өчен гомерләрен дә бирергә әзер бит. Һичшиксез бергәләп сине бу упкыннан коткарачакбыз. Син генә кыю, сабыр бул, җимешем.

*(Шул чакта Айдарның әти-әнисе эштән кайтып керәләр.)*

**Галия**. Кунак бар икән, кызым Алия хәлләрегез ничек? (*Аңа якынрак килгәч*)Тукта, тукта, әллә инде елагансың, Айдар әллә син Алиягә берәр авыр сүз әйттеңме?

**Алия** (елап). Бу хәбәрне ишетсәгез, сез дә таудай, күтәрә алмаслык кайгы –хәсрәт сезнең ишекне шакуын аңларсыз.

*(Ата белән ана шашар дәрәҗәгә җитеп улларына текәләләр. Ә Айдар барысын да ташлап өйдән чыгып китә. Алар аптыраулы караш белән Алиягә карыйлар)*. Айдарыбыз наркотик матдәләргә ияләнеп бара. Аны без генә коткара алабыз. Әйдәгез кулга-кул тотынып без аны бу начар гадәтләрдән арындырыйк.

**Галия.** (*аптырап)* Алия син нәрсә юк-бар нәрсәләр сөйләп йөрисең, ул гел бишле билгеләренә генә укый, тәртипле, әдәпле бала.Ул безнең горурлыгыбыз.

**Илдар**. Ә нигә ул чыгып йөгерде, әнисе, бу дөреслек түгел микән...? *(Башын тотып утыра).*

*(Ул көнне дә әти белән әни моңа ышанмадылар.Чөнки аларның уллары иң акыллысы, иң матуры, иң кадерлесе. )*

**Галия.** Алия, син ничек оятсызларча безнең бердән беребезгә шундый яла ягасың. Ә без сине әдәпле кызга санап йөрибез тагын. Андый булсаң безнең өйдә эзең булмасын.(*Алия чыгып китә)*

**3 нче пәрдә**

*(Галия Айдар белән сөйләшергә тели, ә Айдар аңа тавыш күтәреп кычкыра гына. Шулчак егетләр килеп чыга. Алияне мыскыллап төрле сүзләр кычкыралар).*

**Нәфис**. Әй, чибәркәй, әллә мине эзләп килдеңме? Яратмаган кеше янында нигә чәбәләнәсең?

**Ильназ**. Менә миңа кара, кай җирем ким шушы Айдарыңнан? Менә дигән чибәр, ә бу каралган күз төпләре җайлана ул.

**Нияз.**Туктагыз әле, бәлки минем күзем төшкәндер? Телегезгә салынып торасыз.

**Алия**. Айдар, ә синең йөрәгеңдә аз гына булса да мәрхәмәт, ярату дигән нәрсә калмадымыни? (*Егетләр Алиягә бәйләнә башлыйлар, алардан көчкә качып котыла. Ә Айдар ничек утырган булса, кузгалмыйча утырып кала, әйтерсең җансыз курчак).*

**4 нче пәрдә**

*(Галия белән Илдар елап беткән күзләре белән бер ноктага текәлгәннәр.. Аларның өйләрендә нур да шатлык күренми. Көзгеләр ак материал белән капланган. Пәрдәләр ачылмаган)*

**Галия.** Илдар, безнең газизебез өчен гомеребезне бирергә әзер идек, сырхауханәдә табиблар аның гомерен саклап калырлар дип шулхәтле өметләнгән идек. Булмады шул. Берни дә ярдәм итмәде.

**Илдар**. Коткарып кала алмадылар...(*Күзләреннән яшен сөртеп.*) Айдарыбыз юк шул. Бердәнберебез өчен тырыштык бит, югыйсә. Бөтен акча, байлык шушы улыбыз өчен иде бит. Ни өчен шулай булды соң әле? Моңа кем гаепле? Киләчәктә нишләргә соң?..

**Галия**. Без бер әйберне аңлап бетерә алмаганбыз. Ул акча, алтын-көмеш җылытмый бит, салкын ул. Аңа безнең күңел җылыбыз җитмәгән икән. Без моны бик соң аңладык шул.Башка ата-аналар да безнең кебек ялгышлык җибәрә күрмәсеннәр. Кем өчендер бу гыйбрәт булыр бәлки...Ә безнең өчен гомерлек йөрәк ярасы.

**Илдар.** Без күрәсене кеше күрми, нишлисең. Әнә урамда көзге яңгыр да безнең белән бергә өзгәләнеп-өзгәләнеп елый. Кем уйлаган тормыш иртә язда улыбызга гомер көзен насыйп итәр дип...

**Пәрдә төшә**

## ДУСЛЫК

(хикәя)

*Гомәрова Алисә, Алабуга районы Иске Юраш мәктәбенең 9нчы сыйныф укучысы*

*Җитәкчесе: Гайнетдинова К.Ф.*

Офык читендә кап-кара болытлар күренеп-күренеп алды. Алсуланып кояш баеганда, дымсу салкын җил исте.Төннәрен берөзлексез тоташтан яңгыр яуды. Көзге җил, өермә куптарып, агачлардан соңгы яфракларны йолыккалый.

Биш катлы шифаханәнең дүртенче катында балалар дәвалана. Шул катның 5-палатасында үпкә авыруыннан интегүче кыз бала-Айгөл ята. Үпкә чире аны тәмам аяктан екккан. Ә әнисе бер адым да яныннан китми.

Иртәләрнең берсендә борчулы табиб, кашларын сикертеп кенә, Айгөлнең әнисен коридорга чакырып чыгарды.Термометрның терекөмешен төшерә-төшерә, ул:

-Үзе бик яшисе килсә генә, исән калырга мөмкин. Ләкин өмет меңгә бер генә. Бик авыр булса да, мин сезне кисәтеп куярга тиеш - диде.

Табибның бу сүзләре Ананың соңгы өметен өзде. Мескен Ана баласы йокымсырап киткәч, акрын гына Коръән укырга кереште. Үзе дә аңлап бетермәгән Коръәннең сүзләре, бигрәк тә шуның көе аның күңеленә йомшак бер җылылык бирде.Ул кулын догага күтәрде. Үзе белгән бөтен догаларны укып бетерде. Аның белән генә туктамады, кыска сүрәләр укыды.Бу догаларны йокы аралаш ишетеп яткан кызчыкнын гәүдәсенә әллә нинди әйтеп

бетерә алмаслык рәхәтлек таралды.Ана һаман татарчалап Аллага ялына, ялвара, баласын савыктыруда ярдәм кылуын сорый. Аның күңеле тагын моңая башлады, күзләре яшь белән тулды.Ул, йөзен сөртеп, догасын бетерде. Кыз шул көйгә әкрен генә йокыга талды.

Икенче көнне Айгөл янына дус кызы Рамилә килде. Алар икәү бергәләп сәнгать мәктәбенә йөриләр иде. Икесе дә рәсем ясарга, картиналар язарга яраталар. Айгөлнең хыялы туган ягы көзен язу иде. Кызганычка каршы, ул хыялын тормышка ашыра алмады.

Рамилә палатага килеп кергәндә, Айгөл тәрәз кырында боек кына басып тора, аның күзләре ерак-еракка төбәлгән. Ул кире якка таба нәрсәдер саный.

-Уналты, унбиш, ундүрт, унөч...

Зур күзләрен тәрәзәгә төбәп һаман санавын дәвам итте ул. Рамилә, аптырап, тәрәзәгә карады.Тәрәзәдән бары тик каршы яктагы йорт бакчасындагы нәни каен агачы гына күренеп тора иде. Ни саный ул? Һич кенә аңлап булмый.

-Ни саныйсың син, дустым,- дип сорады Рамилә, аптырап.

-Унике, - диде ишетелер-ишетелмәс кенә Айгөл. Хәзер алар бик тиз һәм бик күпләп өзелеп төшәчәкләр. Моннан өч көн элек кенә алар бик күп иде әле. Саный, саный башлар әйләнә иде. Хәзер санавы җиңел, чөнки алар бик аз калды. Әнә, күрәсеңме тагын берсе өзелеп төште. Соңгы яфрак өзелеп төшүгә, мин бу дөньядан китәчәкмен. Мин бик арыдым, уйлый-уйлый да алҗып беттем. Минем үземне тотып торган дөньядан аерыласым, менә шушы яфраклар кебек, аска очып төшәсем килә.

Рамилә дустын тынычландырырлык сүзләр табалмады, орышырга булды:

- Йокларга тырыш. Тынычлан. Нидидер каен агачыннан яфрак төшкән өчен генә кеше үлә димени? Шундый мәгънәсезлекне беренче мәртәбә ишетәм. Дусты орышканнан соң, Айгөл күзләрен йомып, йокымсырап киткән кебек булды. Аның янына төнгә тагын әнисе килде.

Төне буе карлы-бозлы яңгыр яуды, давыл-җил улады. Дустының әйткән сүзләре Рамиләгә тынгылык бирмәде.Ул ничек тә булса дустын исән калдыру турында уйлап, керфек какмый яфрак ясады, төнге салкында ялгызы аны шып-шыр, ялангач калган каенга беркетте. Салкын, карлы яңгырдан аның куллары күшегеп бетте. Өенә көч-хәлгә кайтып егылды. Икенче көнне ул инде башын да күтәрә алмады. Термометрның теркөмеш баганасы 40 градус күрсәтте. Әти-әниләре, ашыгыч ярдәм машинасын чакыртып, кызны шифаханәгә озаттылар.

Ә Айгөл таң атуга ук уянды. Ул, тонык күзләрен зур ачып, озак итеп тәрәзәне каплаган пәрдәгә карап торды.

- Күтәр әле, пәрдәне, әни, ничек таң атканын күрәсем килә,-диде ул, әнисенә сиздермәскә тырышып.

Ни күзләре белән күрсен: шундый карлы-бозлы яңгырдан, шундый көчле җил-давылдан соң да яфракларның берсе һаман асылынып тора. Соңгы яфрак... Үзе сап-сары. Әйтерсең аны Айгөл сагышы баскан. Шулай да ул әле һаман ботагына бик батыр бер кыяфәт белән ябышып тора.

- Бусы соңгысы. Бүген төшмәсә, иртәгә төшәр, - дип көрсенде Айгөл. Тик юатырга янында дусты гына юк иде. Ул аның килмәвенең сәбәбен белмәде. Һаман да үлем турында уйлавын дәвам итте.Теге дөньяга китәргә җыенып беткән күңел башка нәрсә уйламый икән шул...

Шулай көн үтеп китте, кич җитте. Ләкин соңгы яфрак һаман бирешергә теләмәде.

Икенче көнне таң атуга, Айгөл тагын пәрдәне күтәртте. Яфрак һаман өзелмәгән иде. Айгөл шул яфрактан күзен алмады.

- Әнием, миңа хәзер бераз тавык шулпасы да китерсәң буладыр. Нишләптер тамагым ачып киткәндәй булды,-диде ул.

Бу минутларда Гамилә апа күкнең бишенче катында кебек хис итте үзен. Ул тиз генә өйдән алып килгән тавык шулпасын җылытып алып килде, бәхет кошын ашатты, эчертте.

Сәгать уннарда дәвалаучы табиб хәл белергә керде. Температурасын, кан басымын үлчәде, үпкә-йөрәген тыңлады. Тагын ниндидер процедуралар билгеләде. Авыруның хәле яхшыруын әйтте.

Инде бөтен авырлыклар артта калды, сез үлемне җиңдегез.
Процедураларга үзегез дә йөри аласыз. Аннан сезгә үлемне җиңәргә ярдәм иткән дустыгызның хәлен дә белергә мөмкин, - диде.

Рамилә табибның сүзләренә төшенеп җитә алмады. Кая барырга, дусты аның кайда, ничек аны үлемнән алып калган? Аның башында мең дә бер сорау туды. Бары җавабын гына таба алмады. Ул аны барын да дусты янына төшкәч кенә аңлады. Алар шифаханәдән бергә чыктылар, бергәләп яшь каен янына бардылар, аның һаман да горур торган яфрагына озак кына бергәләп карап тордылар.

- Рәхмәт, сиңа, дустым, - диде Рамилә,- мин сине сайлаганда ялгышмаганмын, тикмәгә генә "дустың үзеңнән яхшырак булсын" димиләрдер. Дуслар авырлык килгәндә сынала икән, мин моңа хәзер чын мәгънәсендә ышандым. "Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын", диләр. Ә миңа берәү дә җиткән, башка дус кирәкми дә.

**ТӘРТИПСЕЗ МАЛАЙ**
**(пьеса)**

**Катнашучылар:**
Илнур Фәритович- мәктәп директоры.
Ләйсән Бариевна- уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары.
Илназ- 8-сыйныф укучысы.
Рәмзил-сыйныфташ малай.

*Директор бүлмәсе. Илнур Фәритович компьютер артында нәрсәдер эшләп утыра.Коридордан ишетелгән шау-шуга колак салып тора. Тыштагы тавышның сәбәбен ачыкларга теләп, урыныннан кузгалып, ишек янына килә башлауга, бүлмә ишеге шар ачылып китә дә мәктәпнең беренче тәртип бозучысы Хабибуллин Илназ ишектән килеп керә.Малай артыннан ук кызарынган-бүртенгән Ләйсән Бариевна күренә.*

**Завуч.** Илсур Фәритович!.. Бу бала белән нәрсә эшләргә?.. Үтерә бит бу безне. Кара син аны!.. Дәрес буе астан кәрәзле телефоны белән уйнап утырган... Егерме сигез ел укытып, минем дәрестә беркемнең дә кулы парта астына төшкәне булмады. Ә бу, күр инде! Укытучыга бернинди хөрмәт калмады. Кара, кара, кызармый да бит үзе... Я, нинди чарасын күрәбез, Илнур Фәритович? Бер минем дәрестә генә түгел, башка укытучылар да зарланалар үзеннән.

*(Шулай сөйләнә-сөйләнә, Ләйсән Бариевна, кулына килеп кергән беренче урындыкны эләктереп, директорның каршысына ук килеп утырды).*

**Директор**. Бер дә болай тузынганыгыз юк иде, Ләйсән Бариевна. Беренче тапкыр күрәм. Мин Сезне әле коллективның иң сабыр кешеләреннән санап йөри идем.( *Илназга карап)* Димәк, тузынырга ныклы сәбәп булган, шулай бит, Илназ. Хәер, уку елы башланганга да бер генә ай бит әле... Үзең җәй буе комбайнда эшләдең, әти-әниеңне сөендердең. Бер дә матур күренеш түгел бит әле бу, егет. Әти-әниеңне чакыртыргамы? Алай дисәң, әтиең ерак юлда бугай инде. Әниеңне әле кичә генә Алсу апаң чакырган иде бугай. Я, нишлибез инде синең белән? Бәлки, егетләрчә икәү генә сөйләшербез. Ләйсән Бариевна Сез чыгып торыгыз булмаса.

**Завуч** (*аптырабрак).* Ярый алайса. Мондый нәрсә бүтән кабатланмас дип ышанасы килә. (*ишекне ябып чыгып китә)*

**Директор.** Я, герой, сөйлә, эш нәрсәдә? Сиңа директор бүлмәсенә керү ошап китте, ахры. Ни кылдың инде бу юлы? *(Илназ директор тикле директорның шулай йомшак*

*эндәшүен көтмәгән кыяфәт ясап, бермәл тын гына басып тора).* Я, телеңне йоттың мәллә, ник дәшмисең? Мәктәп линейкасында ничә мәртәбә тикшерделәр үзеңне? Әле беркөнне генә мәктәп газетасына карикатураңны ясап куйганнар иде. Боларның берсенең дә файдасы тимәдимени соң сиңа? Үзең эшне дә бик яратасың, спорт турында әйтәсе дә юк. Рафил абыең мактап туя алмый үзеңне.

**Илназ**. Абый, мин бөтенесен дә аңладым. Ни... Мин бит кирәк нәрсә укыдым. Рамилә Ильдаровна безгә Фәнис Яруллинның "Җилкәннәр җилдә сынала" дигән әсәрен укырга биргән иде. Мин аны китапханәдән таба алмадым. Менә шул әсәрне интернеттан табып укый идем, Ләйсән Бариевна күреп алды.

**Директор**. Ну, ну нәрсә турында бара инде анда сүз? Сөйләп җибәр инде алайса. Кем инде аның төп герое? *(Сүз китапка күчкәч, Илназның күзләре очкынланып китә. Ул башын күтәреп, кыюланып, тураеп баса).*

**Илназ.** Аның төп герое - Фәнияр. Андагы ихтыяр көче ошый миңа, абый. Фәнияр бернинди каршылыклар алдында да югалып калмый.

**Директор**. Әгәр бу, чыннан да, шулай булса, бер дә начар түгел... Тик химия дәресендә әдәби әсәр укып утыру бер дә матур булмаган. Бу бит, Илназ, укытучыны да, аның фәнен дә яратмау дигән сүз. Өстәвенә әле уку-укыту эшләре буенча мөдир дәресендә.

**Илназ.** Ярар, абый, бүтән кабатланмас. Сүз бирәм.

**Директор**. Болай килешик без синең белән, Илназ. Бүген үзеңә каты шелтә эләкте дип уйла. Моннан соң дәрес вакытында китап уку бетсен. Очкыч ясап утырганыңны да ишетмим. Рәмзил урындыгына кнопка да куйма...

**Илназ**. Нигә, эләкләмәсен башка...

**Директор**. Ә син эләкләшергә юл калдырма. Кыскасы, шулай килешсәк кенә без Фәнис Яруллинның үлемсез тормышына лаек булырбыз. Ну, килештекме?

**Илназ.** Килештек, абый!..

**Директор**. Ә хәзер бар... Тик онытма: китапны укып чыгу белән туры минем янга кер. Ә Фәниярга ошарга тырышуың әйбәт.Хыял- яхшы нәрсә. Һәр эшнең башы - хыял. Хыял матурлык тудыра.Ул - кешенең иң алдан йөри торган юлдашы.

Шулай да син шуны онытма: кеше күңелендә, бөгәрләнгән мәчедәй, һәрвакыт нинди дер бунт ята. Сине рәнҗетсәләр, кешелегеңне кимсетсәләр, шушы бунт калкып чыга. Ул синең кешелегеңне яклап тартыша, бәргәләнә, ыргыла. Менә шуңа күрә син Ләйсән Бариевнаны аңларга тырыш инде, янына барып гафу үтен, чын егет булсаң, бүтән аны болай рәнҗетмә.

Ә Фәнис Яруллинның әсәрен һичшиксез укып бетер, тик башка укытучы дәресендә түгел... Ә аннан соң минем янга керерсең. Сөйләшәсе сүзләр бар, ярыймы?

**Илназ**. Ярый, абый! Рәхмәт Сезгә! Мин үзгәрергә сүз бирәм.

*Илназ күңеленә мөлдерәмә тулган сөенечен башка яшереп кала алмый, — бүлмәне балкытып елмаеп җибәрә. Аннары, кәрәзле телефонын, кесәсенә тыгып, ишеккә юнәлә.*

## КАЗ БӘБКӘСЕ ЧИРӘМДӘ

*Гыйльфанова Регина, Мөслим районы Салавыш-Мухан мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Латыйпова Г. Х.*

Сап-сары йомгак тәгәри,
Ямь-яшел үләндә.
Ул бит безнең каз бәбкәсе,
Уйный йомшак чирәмдә.
Иң башта башын боргалап,
Аякларын сузгалый.
Аннары йөгереп килеп,

Дусларын да кугалый.
Йөгерә торгач, хәле бетә,
Тизрәк суга чума ул.
Барлык җиргә су чәчрәтеп,
Көне буе уйный ул.
Менә шундый каз бәбкәсе,
Безнең чирәмдә йөри.
Шаярып, уйнаклап,
Күңелләрне ул бизи.

## ЯҢА ЕЛДАН НИЛӘР КӨТӘМ МИН?

Яңа елдан нәрсә көтәм?
Шатлык йөзе кешеләрдә.
Яңа ел дип, матур итеп,
Каршыларга бәйрәмне.
Яңа елда иң мөһиме:
Кыш бабай һәм Кар кызы.
Алар булмаса бәйрәмдә,
Яңа елның юк кызыгы.
Кыш бабай безнең өчен,
Бураннар да китерә.
Бөтен җирне карга күмеп,
Юлларны да бетерә.
Яңа елдан ни көтәм?
Шатлык, бәхет, куаныч,
Сәламәтлек, эшләрдә дә
Булсын иде зур уңыш.

## КЫШКЫ МАТУРЛЫК

Кышкы урман бигрәк матур,
Барлык дөнья ап-актан.
Агачлар да шәл ябынган,
Куркып кышкы суыктан.
Урмандагы җәнлекләр дә,
Төсләрен үзгәрткәннәр.
Куян белән тиеннәр дә,
Яңа кием кигәннәр.
Бүрегә дә ашарга юк,
Салкын кышкы урманда.
Төне буе улый-улый,
Йөри тәнге буранда.
Шулхәтле салкын буранда,
Нишләп йөри ул бүре?
Аюдан үрнәк алырга,
Йокларга кирәк иде!

## БАЛАЧАК ХАТИРӘЛӘРЕ

*Дәүләтшин Самат, БДУның Стәрлетамак филиалы студенты*
*Җитәкче: Габбасова Г.З.*

## ӘБИЕМ

Күптән саклаган серем:
Балачагыма кайтыр идем.

Анда ишегалдында елмаеп,
Көтә мине газиз Әбием.
Иң сөйкемле, иң яраткан,
Дөньяда бердәнбер булган.
Каршы алып мине сөйгән,
Минем өчен янган-көйгән.
Мин йөгерер идем каршына,
Бәхет диңгезенә чумарга.
Миңа сузып йомшак кулларын,
Алыр иде мине кочагына.
Чәчләремнән сыйпый-сыйпый:
Кара күзләремә карый.
- Балакаем, кер, торма бусагада
Авыз ит татлы ризыкларымнан, ди..
Күпме шатлык-куаныч
Әбием күзләрендә.
Игътибар итәм һәр сүзенә:
Күпме акыл салынган анда?!
Әбиемнең җан җылысын салган
Ризыкларыннан тәмлим.
Һәм акрын гына
Үткән көнемне сөйлим.
Юк инде күптән Әбием...
Сагынам, юксынам аны.
Кочагына сыенып, елар идем,
Татлы ризыкларын авыз итәр идем.
Истәлегең калды йөрәгем түрендә
Мәңге онытмамын Әбием...
Күптән саклаган серем бар:
Балачагыма кайтыр идем.
Ишегалдында елмаеп,
Көтә мине газиз ӘБИЕМ.

## КӨЧЕК

Ябалаклап яуган карга карап,
Сабый чагымны искә төшерәм:
Салкын җиргә ак “мамыклар”
Коела иде ерактагы күктән.
Хәтерлим балачагымда
Мондый вакыйга булды:
Безнең кар яуган урамда
Кечкенә көчек пәйда булды.
Һаман да шул исемдә:
Юл читеннән йөгерә
Каршыма минем.
Тик алга таба баралмый
Тәгәри карга чумып.
Әйе, бик кечкенә бит ул үзе,
Тәпиләре күренми.
Шатлыгыннан күзләре яна

- Син дустым бул, дип
 әйтәсе килгән кебек.!
Мондый салкын җир өстендә
Мәңге калдырмас идем.
Шуңа күрә, кулларыма алып,
Берүзең булмассың, дидем.
 Күбәләктәй яуган карга карап,
 Сабый чагымны искә төшерәм:
 Шул чактаагы көчегем
 Инде күптән зур үскән!

**КӨЗ**

Зур юллар беткән,
Сагынырлык, бәлки, калмаган
Әйдә, икәү бергә үтик
Тапталып, моңсуланып калган сукмаклардан.
 Без барыйк, әйдә дускай,
 Курыкмыйк төссез, моңсу кояштан.
 Беркем дә әйтмәс, мөгаен:
 Җәй буе аткан, - дип, таң.

**СИН КАРА!**

Анда нәрсә күрәсең?
Алтын төскә баткан урман?!
Нигә син аны:
- Елый торган, диясең?!
 Юк, син алай үксемә!
 Син шатлан, йөрәгеңне ач!
 Җәйләр бит килми бер генә
 Кабатланыр тагын да.
 Кояш та сөенеп куяр,
 Йөзеңдә елмаю күргәч!

## БАЙ НИЧЕК БӘХЕТЛЕ БУЛГАН?

(экият)

*Девятых Анжела, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Әхмәдуллина Р.Ф.*

Борын-борын заманда бер Сәлим атлы бай яшәгән, ди. Балалары үсеп кайсы кая таралган, хатыны үлеп киткән, туганнары читләшкән, ул берүзе сарай кадәр бик зур өйдә торып калган. Балалары кайтып йөрмәгән, алар диңгез артында ук, бик еракта яшәгәннәр, ди. Бик саран булганлыктан, кешеләр белән аралашмаган. Байлыгы да аның күңелен күтәрмәгән, ул гел кара янып йөргән.

Берзаман ул, күрше авылда яшәүче, шат күңелле, гел елмаеп кына йөрүче балачак дустын очратып:

- Кара әле, дус, без бит яшьтәшләр, ә син бер дә картаймыйсың, күңелең дә гел көр, йөзеңдә кайгының әсәре дә юк. Нидән бу?- дип сораган.

- Бәхеттән,- дигән бу, озак уйлап тормыйча.

- Нәрсә соң ул бәхет, синеңчә?-дип сораган Сәлим бай.

- Бәхет - ул, минемчә, кешеләргә ярдәм итә алу,-дигән дусты.-Үзең дә күрәсең, мин нинди генә эшкә тотынсам да, ерып чыгам. Кешеләргә ярдәм итәм, шул вакытта үземне

тагын да бәхетлерәк хис итәм. Син дә кешеләргә булышып кара, дип ашыгып китеп тә барган.

Дустының соңгы сүзләре байны уйланырга мәҗбүр иткән. Ул авылдашларына игътибарлырак була башлаган.

Ул елны, җәйге кызу көннәрнең берсендә, яшеннән янгын чыгып, бер күп балалы гаиләнең йорты янган. Җиде баласын кочаклап, бу гаилә урамда, бернәрсәсез торып калган. Шунда Сәлим бай бу гаиләгә иркен йорт салып бирергә уйлаган. Ул бабасыннан калган бер алмагач бакчасына зур йорт салып куйган. И шатланган бу гаилә! Сәлим байга рәхмәт укып бетмәгән. Аларга карап, байның күңеле күтәрелә башлаган.

Шуннан ул бу гаиләгә йорт янында гына кое да эшләп бирергә булган. Кое казый башласалар, ни күрсеннәр: көмеш һәм алтын тәңкә тулы тартма килеп чыккан. Көтелмәгән хәл: бабасы кайчандыр яшергән байлык табылган! Шулай итеп, йорт салырга киткән малы байга меңе белән кире әйләнеп кайткан! Ул тәңкәләрнең күпмесендер сәүдәгәрләргә сатып, балаларны баштан-аяк киендергән, яңа йортка кирәк-ярак бөтен әйберләрне алып биргән. Ул балалар, аның белән гел исәнләшеп, хәл сорашып йөри башлаганнар. Ә беркөнне, байны таларга дип килгән караклардан, шул ук күрше балалары коткарып калган. Ул балалар бик шук та, сизгер дә, тиз дә булганнар. Шуннан соң Сәлим бай тагын бик күп кешеләргә булышкан.

Картлык көнендә, янында яхшы дуслар һәм күршеләр булуы да бәхет икәнен аңлаган.

Шунысы кызык: кешеләргә күпме ярдәм итсә дә, аның байлыгы бер дә кимемәгән, ә киресенчә, тагын да артып торган, ди.

##ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ БАЙЛЫГЫ

(шигырь)

*Евдокимова Алёна, Мамадыш районы Шәдче урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Садыкова Л.П.*

Утырам да янә уйлап куям:
“Нәрсә соң ул байлык дигәне?”
“Акча”, – диеп дөнья куа халык.
Тик бармы соң акча җиткәне?
Кечесе дә чаба, олысы да,
Акча эшләп таба ул, имеш.
Байлык түгел акча дигәннәре,
Байлык түгел алтын һәм көмеш.
“Бары саулык – олы байлык” дигән
Бер мәкаль бар безнең халыкта.
Акча дигәннәре җитмәячәк,
Җитмәде ул, җитми халыкка.
Байлык сүзе мине уйга сала,
Нәрсә соң ул байлык дигәне?
Байлык бит ул – саулык, гаиләң булу,
Ник аңламый халык дигәне...
Шулар арасыннан бер хәерче
Кычкырадыр, өзелеп үзәге:
“Менә байлык”, – диеп алга кулын суза,
Ә кулында Ипи кисәге.
“Байлык бит ул –тату гаиләң булу”,-
Дип өзелә Ана йөрәге.
Ул да белә: байлык – ул балалар,

Ирең булу – дөнья терәге.
“Байлык бит ул – оныкларым”, – дия
Әби белән бабай, шатланып.
Алар белә байлык ни икәнен,
Яшиләр чын күңелдән куанып.
Кем өчендер байлык – яхшы уңыш алу,
Кем өчендер – һаман шул акча.
Бәхет табып булмый акча белән,
Булсын шунда, булсын бер букча.
Ялгышабыз бик еш, аңламыйбыз,
Шул бер акча безнең башларда.
Дөрес юлдан тайпылмыйча барыйк,
Дуслар булсын авыр чакларда.
Дусларыңның шаян елмаюы,
Җылы сүзе туганнарыңның,
Аңла, дустым, менә шулдыр байлык
Бу дөньяда озатып барырлык.
Гади әйберләрдән бәхет тоя белик,
Аңлыйк акча байлык түгелен.
Ялгышмыйча, дөрес юлдан атлап,
Бәхет белән үтсен гомерең.

## МИНЕ КӨЗЛӘР БҮЛӘК ИТКӘН
(шигырь)

Мине җиргә көзләр бүләк иткән,
Табигатькә алтын тамганда.
Кошлар, соңгы тапкыр аваз биреп,
Туган җирдән китеп барганда.
Мин дә алар сыман очар идем,
Канатларым булса очарлык.
Бирегезче мина пар канатлар
Галәм киңлекләрен кочарлык.
Канат җәеп очкан шул кошлардай,
Ирекле мин, күңлем биектә.
Кош баласы булсам тик бер көнгә,
Очар идем җиде кат күккә.
Көзнең сихрилеге мине әсир итә,
Әсир итә моңсу матурлык.
Вакытларны ничек туктатыйм сон
Шул көзләрдә бераз калырлык?
Көтче бераз, вакыт, кабаланма,
Син дә аргансыңдыр ашыгып.
Эх.. туктаса иде вакыт дигәннәре,
Дөнья кумас идек шашынып.
Мине җиргә көзләр бүләк иткән,
Уйнаклашып яфрак очканда.
Кызыл уттай янган миләш-баланнардан
Яңгыр тамчылары тамганда
Әкияти көздә туган бала бит мин,
Шул әкият минем күңелдә.

Онытылмас моңлы бер җыр булып,
Калсын көзләр минем күңелдә.

## ҖИҢҮ КӨНЕ

*Егорова Екатерина, Әлмәт шәһәре 15 нче урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Тюрикова Г.Г.*

Зур бәйрәмне көтә илем,
Көтә халкым,туган җирем.
Зур горурлык белән аны
Моңсуланып көтә күңелем.
  Алмагачлар чәчәк аткан
  Матур май иртәсендә.
  “Сугыш беткән” дигән хәбәр
  Ямьле яз алып килә.
Күпме кеше көткән бу хәбәрне,
Күпме күз яшьләре түгелгән.
Күпме сагыш-кайгылары,
Күпме гомер җиргә күмелгән.
  Курыкмаган халык ятимлектән,
  Курыкмаган салкын ачлыктан.
  Бар теләге илен азат итү
  Фашист дигән кыргый ерткычтан.
Күңелләрдә мәңге онытылмас,
Батыр халкым, көрәш юлларың,
Сине данлап хөрмәт итеп яши,
Горурланып, ул һәм кызларың.

## СИН КИРӘК БУЛДЫҢ МИҢА

*Ермакова Анастасия, Алабуга шәһәре 8 нче урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Тимофиева Л.Г.*

Кышның матур бер көнендә,
Сызылып таңнар атканда.
Дөньяга бит мин килгәнмен
Ап-ак карлар яуганда.
  Әнкәй мине кулына алып,
  Сөеп, иркәләгәндер.
  Кайгы-хәсрәт күрмәсен,
  Бәхете булсын дигәндер.
Әнкәй, синең теләкләрең
Кабул булсын барысы да.
Укып белем алырга да
Син кирәк булдың миңа.

## ӘБИЕМ

Олы җанлы, оста куллы
Минем яраткан әби.
Кичләрен утырып безгә

Җылы оекбаш бәйли.
Әбинең күзләре күрми
Миңа энә күзләтә.
Сиңа оекбаш бәйлим, – дип,
Йомгагын да эзләтә.
Иртән мине әбикәем
Сыйпап кына уята.
Хуш исле үләннәр белән
Тәмле чәйләр кайната.
Күңелем сизә әбекәем
Мине бик тә ярата.
Миңа елмаеп караса,
Йөзендә нур тарала.

## СОҢГА КАЛМАГЫЗ

*Җаббарова Илнара, Алексеевск эшчеләр бистәсе 2 нче урта мәктәбенең 10сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Хөснетдинова Г.С.*

Бәлки мине әнием эзлидер,
Бәлки мине әтием эзлидер.
Әнием! – Мин монда,
Әтием! – Мин монда
Каты тимер караватымда
Ишек бикле булса- ачыгыз,
Тәрәз бикле булса- ачыгыз,
Кертмәсәләр качып керегез.
Ләкин мине барыбер күрегез... -

дип язган Фәнис Яруллин үзенең “Калмагыз соңга” шигырендә. Ата-анасы ташлап киткән бер үксезнең җан авазы бу.

Галия бик күп игъланнар карап чыкканнан соң, балалар йортына социаль эш буенча белгеч кирәк дигән язмада тукталып калды. Барлык кирәкле документларны да җыеп, ул шунда юл тотты. Аның белән сөйләшү уткәргәннән соң, кайчан эшкә килергә кирәклеген әйттеләр.

Менә бүген беренче эш көне. Балалар йорты каршына килеп житкәч, Галия озак кына уйланып торды. Бу бина аңа беренче күрүдә үк шундый матур, якын булып тоелды,аннан ниндидер җылылык бөркелеп тора иде. Әнә урамнан саф һавада уйнап арыган балалар кайтып килә. Аның бу балаларга ярдәм итәсе, авыр вакытта аларга терәк буласы килде. Әйе, Галия чыннан да йомшак күңелле, кешеләргә һәрчак ярдәм итәргә ашкынып торучы кеше иде.

Беренче көннән үк, Галия башы-аягы белән эшкә чумды. Галиянең эш вазыйфаларына-балаларның бу йортка эләгү тарихын өйрәнү, эти-әнисен эзләп табып, кире гаиләгә кайтарырга тырышу, бу мөмкин булмаганда, баланы яңа гаиләгә урнаштыру юлларын эзләүиде.

Эшнең нечкәлекләренә төшенә-төшенә, Галиянең ике эш атнасы үтеп тә китте. Үзенә бер көн сайлап, ул балалар белән танышып, аларның хәлләрен белеп чыгарга уйлады. Төркемнәргә керүгә, аны тәрбиячеләр каршы алды. Болар- балаларны үз балаларыдай якын күреп,аларның киләчәк тормышларын кайгыртып, бөтен күңел җылылыкларын биреп эшләүче илаһи затлар.Галияне күргәч, алар үзләрен борчыган сорауларны бирергә ашыктылар. “Алмазның эти-әнисеннән берәр хәбәр юкмы? Булатның әтисе килгән иде, алып китәме әллә?” һ.б. “Марат белән яңа эти-әниләр танышырга килгән иде, бик тә ярattылар үзен,”- дигән куанычлы хәбәрләр белән дә уртаклаштылар.

Балалар белән таныша-таныша, бүгенге эш вакыты да үтеп китте. Ләкин Галия кайтырга ашыкмады. Соңгы төркемгә кереп, андагы балаларбелән дә танышып чыгарга иде исәбе. Әзрәк хәл алырга дип ул эш бүлмәсенә керде. Кәнәфигә утырды да бүгенге балалар белән танышуынкүз алдыннан уздырды. Аларның барысының да күзләре моңсу, карашлары уйчан. Галия аларның сабырлыгына таң калды, алар өчен нидер эшлисе, йөрәгендәбулган бар җылылыгын, барлык мәрхәмәтен шул ятимнәргә өләшәсе килде. Әйе, дөрестән дә бу балалар бик кечкенәдән тормышның ачысын татый башлаганнар түгелме?! Галия үз уйларына чумып, әкрен генә соңгы төркемгә атлады. Ишектән килеп керүе булды, бер сабый “әнием килде, әнием!” дип йөгереп килеп кочаклап алды. Галия бер мизгелгә каушап калды, ни әйтергә дә, үзен ничек тотарга да белмәде.

Шул көннән бирле, бу очрашу Галиянең күңеленә тынгылык бирмәде. Иң беренче эш - баланың шәхси эше белән танышып чыкты. Аннары опека органнарына шалтыратып, хатлар аша аның әти-әнисен, туганнарын эзләргә кереште, түземсезлек белән җавап көтте. Ләкин бу эшләрнең берсе дә теләгән нәтиҗәне бирмәде. Кыскасы, бала беркемгә дә кирәк түгел иде...

Галия баланы язмыш кочагына ташлап калдырган ата-ананың фотосурәтләренә күз салды һәм шаккатты. Рамилнең әнисе Галиягә ике тамчы су кебек охшаган иде. Әнисенең йөз чалымнарын хәтерли икән дигән уй чагылып үтте башында.

Галия бу турыда бала белән үзе сөйләшеп карамакчы булды. Өч яшь кенә булуга карамастан, бала чиста, матур итеп сөйләшә иде. “Сез бит миңа шарлар алып киләбез, дип киттегез дә юк булдыгыз. Ник килмәдегез, мин сезне һәр көнне көттем” – диде ул еламсырап.

Галия апасын күргән көннән бирле, Рамил дә үзгәрде. Моны тәрбиячеләр дә бик тиз күреп алды. Рамилнең көйсезләнүе дә кимеде, шатланып көлү тавышлары да ешайды. Галия дә баланы игътибарсыз калдырмаска тырышты, буш вакыты булган саен аның хәлен белеп, яратып чыга иде.

Менә беркөнне киңәшмә булды. Киңәшмәдә һәрбер хезмәткәргә интернатка җибәрелергә тиешле балаларның документларын җыярга куштылар, аларның фамилияләрен укып чыктылар. Бу исемлектәРамилнең дә фамилиясе бар иде. Көтелмәгән хәбәр булды бу Галия өчен. Аның Рамилне югалтасы килми иде. Аның башына бу баланы уллыкка алу турында фикер кереп урнашты.

Галиянең үз гаиләсе дә бар бит әле. Үзенең дә Рамил кебек кечкенә улы үсеп килә. Бу хәбәргә ире ничек карар ? Чөнки бу бик җаваплы эш, аны тиз генә хәл дә итеп булмый.

Ә мәсьәләне тиз арада хәл итәргә кирәк, аннары үкенергә калмасын. Ул бар көчен җыеп,уллыкка алу өчен кирәкле документларны җыярга кереште. Аның юлында төрле киртәләр очрады, гаепләүче кешеләр дә күп булды. Ләкин Галия бернәрсәдән дә курыкмады, Рамилнең өмете аңа рухи яктан көч өстәп торды. Ике ай дигәндә ул бу зур эшне башкарып чыкты.

Менә ниһаять, балаларны гаиләгә урнаштыру үзәгеннән Галия рөхсәт алды. Ул моңа үзе дә ышанып бетә алмады.

Баланы барып алырга тиешле көн килеп җитте. Галия һәм аның гаиләсе бу көнне түземсезлек белән көттеләр. Юлда машинаны туктатып, Галия кибеткә кереп төрледән- төрле шарлар, уенчык машина сатып алды.

Менә дулкынландыргычмизгелләр. Тәрбиячеләр дә Рамилне яңа тормышка озатырга дип җыелышып чыкканнар.Рамил башта бу тамашаны аңламады. Ләкин Галия апасын күрүгә, йөзе үзгәрде, ул “Әнием минем!” дип аның кочагына ташланды.Галия аны булачак әтисе, энесе Айдар белән таныштырды.

Машина кузгалып китте. Тәрбиячеләр күз яшьләрен тыя алмыйча, бу балага бәхетле тормыш теләп калдылар. Галия соңга калмавына тагын бер кат шатланып куйды.

## ЕРАК СУГЫШ ҖИЛЛӘРЕ

*Җәләлова Алия, Алабуга шәһәре 8 нче урта мәктәбенең 10 нчы А сыйныфы укучысы*
*Җитәкче: Мельникова Н.Н.*

Тормышта ирешеп максатка,
Бәхеткә елмаеп яшәрсең.
Ил өчен кан койган солдатны
Онытмый, онытмый яшә син!
(Фазыл Шәех, "Онытмый яшә син!")

Шәһәребезнең үзәк урамнарының берсендә яшь каеннар һәм кып-кызыл гөлләр арасында кургаштан ясалган егет һәйкәле тора. Кулына автомат тоткан, эре адымнар белән каядыр ашыга сыман. Горур башын туры тотып, кыю күзләрен ерак офыкларга төбәгән. Күктә – баш очында гына парлы ак күгәрченнәр очып йөри. Алар безнең тыныч тормышыбызга, аяз күгебезгә шатланып, ак болытлар арасында уйныйлар кебек. Туган ягыбызның зифа каеннары, нәфис яфракларын җилфердәтеп, талгын гына җилдә чайкалалар. Әйтерсең, Чулман буена сыенган борынгы шәһәребезнең үткән тарихын бүгенге яшь буынга җиткерәләр. Һәйкәл яныннан үтүчеләргә нәрсә әйтергә тели икән алар?

Кешеләр, бер минутка гына туктагыз! Һәйкәл янындагы мәрмәр ташка күз салыгыз! Анда Әфганстан һәм Чечня сугышларында һәлак булган солдатларның исемнәре язылган. Алар илебез сагында торганнар, илебез чакыруы буенча утка да, суга да кергәннәр, илебез кушуы буенча башларын җиргә салганнар. Туган йортларына исән-сау әйләнеп кайткан солдатлар, тату гаилә корып, берсеннән-берсе матур балалар үстерәләр, туган илебезнең төрле өлкәләрендә тыныч тормыш алып баралар. Илебез кушуы буенча сугышка кергән һәм һәлак булган иптәшләрен беркайчан да исләреннән чыгармыйлар. Ел саен һәйкәл янына Әфганстан һәм Чечня сугышында катнашкан солдатлар җыела. Чәчләренә чал кергән ир-егетләр сугыш яуларында башларын салган дусларын искә алалар, дәһшәтле еллар турында уйланалар. Батыр сугышчы һәйкәле алдына басып, бер минут тын калып, һәлак булган иптәшләре истәлегенә баш ияләр.

Сугыш бетеп ничә еллар үткән,
Әле һаман сызлый яралар.
Сөйгәннәрен көтә тугры кызлар,
Ә улларын көтә аналар.

Әфганстан... Күпләрне тетрәндергән сүз бу...Каян гына килеп керде соң безнең телебезгә бер үк вакытта ят та, дәһшәтле дә булган бу сүз? Килеп керде дә, барыбызны да сискәндереп, сагаерга мәҗбүр итте, аналарның төн йокысын качырды, илгә кургаш табутлар кайтарды.

Әфганстан белән СССР арасында дуслык турында солых төзелгән булу сәбәпле, аларга ярдәм йөзеннән, Л.И. Брежнев Әфганстанга совет гаскәрләре кертелү турындагы хәбәрне үзәк телевидение буенча шәхсән үзе 1979 нчы елның 27 нче декабрендә игълан итә. Халык котычкыч адымның асылын аңламый, чөнки икенче көнне үк Әфганстан темасы матбугат һәм халыктан корычтай ныклы пәрдә артына яшерелә. Фәкать 1988 нче елның 15 нче маенда гына чит илдәге гражданнар сугышыннан совет гаскәрләре чыгарыла башлый һәм, ниһаять, 1989 нчы елның 15 нче февралендә соңгы совет солдаты Әфганстан чиген атлап чыга. 9 ел 51 көн буе безнең гаскәрләребез чит илдә кан коя. Ни өчен яшь егетләрнең читтә каны коела? Моны аңлавы бик кыен...

Әфганстан сугышында 68 милләт вәкиле, алларына куелган бурычны үтәү өчен, үзләрен аямыйча көрәштеләр һәм Дәүләт бүләкләренә лаек булдылар. Бу авыр һәм каршылыклы көрәштә 40 нчы армиянең генераллары, офицерлары, сержант һәм солдатлары соңгы минутларына кадәр үзләренең хәрби бурычларына тугры булып калдылар. 200 мең Совет Армиясе сугышчысы Әфган сугышы елларындагы батырлыклары өчен төрле орден

һәм медальләр белән бүләкләнә. Шуларның 10955нәүзе үлгәннән соң гына бүләкләре тапшырыла.Һәлак булганнарның гәүдәләре кургаш табутларда ата-ана йортына кайтарыла.Еллар үтү белән күп вакыйгалар хәтердән җуела. Әмма без тарихтагы бу кайгылы көннәрне онытырга тиеш түгел.Гомерләренең иң матур вакытында һәлак булган егетләребезнең намус һәм хәрби бурыч төшенчәләрен үзләренең тормышыннан да өстенрәк куйганнары өчен горурлану тойгысы кичерәбез. Үлгәннәр хәтере исәннәрдә яши...

Тын калыйк бер минут, бары тик бер минут,
Бар дөньябер минут тын калсын!
Ах, Әфган җилләре һәм дала гөлләре...
Чык түгел, гөлләрдән яшь тамсын!

Кеше бу дөньяга яшәү өчен, иҗат итү, җирне матурлау өчен яратылган.Җир йөзендә сугышлар башка кабатланмасын, яшь егетләрнең гомере вакытсыз өзелмәсен, ата-аналарның кайгылы күз яше түгелмәсен. Дөньяда башка кан кою булмасын.

## ҺӘР НӘРСӘНЕҢ ҖАЕ БАР

(әкият)

*Закирова Зөһрә, Казан шәһәре 179 нчы урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Соснина В.Г.*

Берзаман барлык кошларга да исем табылып, алар, кайсы – песнәк, кайсы – чыпчык, кайсы – сандугач булып, яши башлаганнар. Тик менә бер кошка гына исем белән дәшмәгәннәр – ул исемсез калган. Моңа кош бик читенсенгән, кайгырган, хәтере калган.

Кошчык көннәр буе үзенең тамагын туйдыру өчен басулар, кырлар буйлап йөгерә дә йөгерә ди. Ул мескеннең томшыгы юан һәм кыска булган, шуңа күрә аңа бөҗәкләрне аулау бик кыен булган икән.

Беркөнне кошчык, арып-талып, бер агач кәүсәсенә утырган да тирән уйга калган. Үзенең башка кошлардан аерылып торуына бик нык уфтанып, йокымсырап утыра ди бу. Күпме вакыт утыргандыр мескенкәй, берзаман агач кайрысы астында ниндидер тавыш ишеткән. Кайры астында нәрсәдер кыштырдый, нәрсәдер йөргән кебек тоелган моңа. Кош тыңлап торган да, кайрының бераз ярылып киткән урынын табып, чукый башлаган. Көне буе, төне буе чукыган ул аны. Кайры кисәкләре җиргә коела да коела икән, ә кошчык һаман чукыган: тук-тук-тук, тук-тук-тук...

Таң атканда кош бик нык арыган, ләкин ул үзенең тамагының туйганын да, томшыгының озынаеп, очланып калганын да сизгән. Хәзер инде ул агач кайрысы астындагы бөҗәкләрне бик оста итеп тартып чыгара башлаган.

Шушы хәлдән соң бу кошчыкка да исем тапканнар. Агачта тукылдап утыруын күреп, син тукран исемле булырсың инде хәзер дип, аңа шушы матур кош исемен биргәннәр. Шулай итеп, бу кош тукран булып яши башлаган.

## ВАКЫТ КАДЕРЕ

*Закирова Эльвина, Яр Чаллы шәһәре 27 нче мәктәпнең 10 сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Миннегалиева Л.С.*

Кызык та соң инде без - кешеләр
Йөгерә-чаба дөнья куабыз.
Яшәү матурлыгын күрергә дә
Вакыт җитми дигән булабыз.

Һич ара юк, җай таба алмыйбыз
Туганнарның хәлен белергә.

Ярты сәгать җитми кала кайчак
Җан дусларыбызны күрергә.

Ничек тырышсак та беркемнең дә
Тотканы юк дөнья койрыгын.
Бер көн килеп мәңгелеккә китә
Калдырып ул бөтен байлыгын.

## СӨЮЛӘРЕҢ БУЛСЫН ИХЛАС СИНЕҢ

*Закирянова Рушания, Яр Чаллы шәһәре*
*«Яр Чаллы педагогия көллияте» нең 1 курс студенты*
*Җитәкче: Минһаҗева Р.Ә.*

Сөюләрең булсын ихлас синең,
Күзләремә карап алдама.
Башкаларны син күзләмә, җаным
Бүтән ярны, зинһар, сайлама.

Синҗа булган кайнар хисләремне
Күзләреңә карап әйтмимен.
Әллә куркам, әллә ояламын
Нигәдер ул - анысын белмимен.

Туры карап тора алмыйм сиңа
Син карасаң яна йөрәгем.
Синнән башка озак түзә алмыйм,
Сагынудан өзелә үзәгем.

Төшләремә керми калмыйсың син
Уйларымнан бер дә чыкмыйсың.
Йөрәгемне яулап алдың бит син,
Тик моны син үзең сизмисең.

## ТУГАН АВЫЛ

*Захарова Ольга, Мамадыш шәһәре политехник көллиятенең 11 Т төркем укучысы*
*Җитәкче: Әхмәтшина А.Д.*

Һәркеше өчен дә ул,
Туган авыл кирәкле җир.
Анда кеше, туа-үсә
Бу авылда тору, аңа бик тә килешә.
Туган авыл – сулары,
Чишмәләре, таулары.
Һәркешегә рәхәттер ул –
Бу авылда торулары.
Эх, дип тә уфтана күңел,
Нигә соң, алай ул?!
Минемчә, җавап мондый –
Туган җир, бер генә ул!
Яшел чирәм өстендә
Ауныйсыңда, тәгәрисең.

Бу авылда – рәхәтлеген,
Син соңыннан гына сизәсең.
Туган авылыңда синең
Әти-әниең тора.
Алар синең өчен –
Догалар кылып тора.

## УКЫТУЧЫ АПА

А хәрефеннән башлап,
Я хәрефенә кадәр –
Укытучы өйрәтә-өйрәтә,
Башларыбыздан сөя.
Укытучы апа болай ди:
-”Күп – күп итеп укы”, - ди.
Күп итеп укыган кеше
Бердә белемсез калмас, ди.
Укытучы апа!
Һәрбер бала өчен дә
Икенче әни бит ул.
Синең мәсьәләләреңне чишәр өчен –
Төнннәр буе утыра ул.

## БАБАМНЫҢ БАТЫРЛЫГЫ

*Заһидуллина Айгөл, Мөслим районы “Түбән Табын төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Әмирова М.Р.*

Җәйге матур көннәрдә ләззәтләнеп агачлар утыртканда таза, яшь егетләр ил өстенә ябырылган мәкерле дошманга каршы киттеләр. Шул егетләр арасында минем бабам – Вәҗетдинов Гайнетдин дә булган. Моңсу һәм хәсрәтле иде ул көннәр, - дип искә ала иде бабам.

Минем бабам Вәҗетдинов Гәйнетдин Вәҗетдин улы 1923 елның 16 августында Мөслим районы Тегермәнлек авылында туа. Бабам тугыз балалы гаиләнең бишенчесе булып дөньяга аваз сала. Бик авыр еллар була. Бабам ачлыкны да, ялангачлыкны да күрә. Гаиләдә бердәнбер малай булганга, аңа тормыш йөген бик иртә тартырга туры килә.

Сугыш – иң зур афәт. Бу явыз афәт безнең әбиләрнең дә өйләренә үтеп керә. Иң беренче булып бабамның әтисе, берничә айдан соң Гәйнетдин бабай китә. Бу вакытта бабайга 18 яшь була. Бабай икенче Украин фронтында рядовой булып, Белград һәм Курск шәһәрләрен азат итүдә катнаша. 1942 елның август аенда каты яраланып, госпитальгә эләгә. Госпитальдән чыкканнан соң 23 Һава десанты гаскәрләрендә Днепр һәм Калуга өчен барган сугышларда катнаша. Ә 1944 елның апрель аенда каты яраланып авылга кайта. Аның муенына пуля тиеп, сугышка ярамаслык була. Авыл кешеләре бабамның исән калуына ышанмыйлар. Ләкин ул көчле рухлы, батыр булган. Әбием үзе белгән үләннәре, догалары белән дәвалаган һәм кеше иткән. Шулай итеп 18 яше яңа гына тулган егет, өч елда 6 ай сугыш кырында үзен-үзе аямыйча көрәшә.

Бабамның сугышта күрсәткән батырлыкларын хөкүмәтебез онытмый. Ул ”Ленин” һәм “Почет билгесе” орденнары һәм бик күп медальләр белән бүләкләнгән.

Тыныч тормышта да бабам сынатмаган. Калган гомерен терлекчелектә эшләп үткәргән. Лаеклы ялга чыккач та биш ел үзенең яраткан эшен ташламаган. Аңа “Атказанган колхозчы” исемен бирәләр. Менә шундый бабам булганга мин чиксез горурланам!

Ләкин, кызганычка каршы бабай 2003 елның 1 нче мартында безнең арабыздан китеп барды. Без – аның оныклары , бабабызның батырлыкларын беркайчанда онытмаячакбыз һәм онытмабыз!

Буыннардан – буыннарга күчә
Батырларның гомере җыр булып:
Илне яратудан өстен хис юк,
Чын батырлык – илгә тугрылык.

## СПОРТ-СӘЛАМӘТЛЕК, СПОРТ-УҢЫШ!

Сәламәт тормыш рәвеше алып бару бүгенге көндә иң актуаль темаларның берсе. Бүгенге җәмгыятьтә тулы канлы тормыш алып бару өчен, иң беренче чиратта сәламәт булу мөһим. “Сәламәт буласың килсә - йөгер, матур буласың килсә – йөгер, акыллы буласың килсә – йөгер”, – дип бик белеп әйткәннәр борынгы акыл ияләре. Чынлап та, сәламәтлекнең нигезендә хәрәкәт булуын исбатлый бу әйтем. Димәк, сәламәт булу өчен спорт белән шөгыльләнергә, спортны яратырга кирәк. Әлбәттә, спортка мәхәббәтне кече яшьтән тәрбияләү кирәклеге һәркемгә мәгълүм. Бу эш һәр гаиләдә, балалар бакчасында да, мәктәптә дә системалы рәвештә алып барылырга тиеш дип уйлыйм мин.

Түбән Табын мәктәбендә бу юнәлештә ныклы эш алып барыла. Укучыларга башлангыч сыйныфлардан ук спортка мәхәббәт тәрбияләнә. Мәктәпкә аяк баскан көннән үк укучылар спортка тартыла. Мәктәптә ел буена төрле спорт уеннары, спорт ярышлары уздырыла. Кыш җитсә балалар чаңгыга баса. Районның спорт мәктәбе тренеры Фәрит абый Вәлеев укучыларны спорт белән кызыксындыру өчен нинди генә чаралар уйлап тапмый: бадминтон, биатлон дисеңме, ял көннәрендә укучылар белән кышкы табигатькә экскурсияләргә бару, төрле марафоннар уздыру балаларда спортка гына түгел, туган якка да, аның табигатенә карата да мәхәббәт тәрбияли безнең укытучыбыз.

Мин, Загидуллина Айгөл, башлангыч сыйныфларда укыганда ук спорт белән кызыксына башладым, ә хәзерге көндә шушындый таләпчән тренер кул астында шөгыльләнгәнгә күрә, минем дә спортта уңышларым күп: Әлмәт шәһәрендә үткәрелгән республикакүләм бадминтон ярышында III урын алып Дипломга лаек булдым, һәр елны кышкы спартакиада кысаларында үткәрелә торган чаңгы ярышларында беренчелекне алам һәм районара, республикакүләм ярышларда да катнашып призлы урыннарга лаек булам. Мин бигрәк тә, спорт төреннән – биатлонны үз итәм. Кыш аен түземсезлек белән көтеп алам.

Тренерыбыз Фәрит абый һәр көнне түгәрәккә йөрүче укучыларны спортзалга алып кереп бадминтон уенының серләренә өйрәтә, әгәр дә Фәрит абый тырыштырмаса, минем уңышларым күп булмас иде. Шуңа күрә укуда һәм спортта уңышларым күп булганга күрә, 2015-2016 нчы уку елында Яңа ел алдыннан үткәрелә торган күркәм традицияләрнең берсе – Президент чыршысы бәйрәмендә катнашуга лаек булдым.

Шуны әйтәсем килә: “Спортны яратыгыз, спорт белән шөгыльләнегез! Спортны яраткан бала авыру булмас, сәламәт булыр, укуда да, спортта да уңышлары күп булыр”.

## НИНДИ ГҮЗӘЛ СИН, ТУГАН ЯК

*Зәитов Айрат, Барда районы Каенавыл уртамәктәбенең 9 класс укучысы*
*Җитәкче: Зәитова Г.Р*

Җир йөзендә матур төбәкләр бик күп. Сәяхәттән соң гаҗәпләнеп, сокланып искә төшерәсең. Ул төбәкләр нинди генә булмасын, алар безгә ят булып калалар. Туган районыбыз – бөтенләй башка нәрсә.Ул табигатьнең бик матур почмагына урнашкан. Безнең урманнар, болыннар, елга-чишмәләр – кабатланмаслык! Мин монында кабат инандым.

Каенавыл мәктәбе каршында быел туристик-экологик лагерь-экспедиция эшләде. Аның максаты – Барда районының төп артериясе булган Тол елгасының торышын тикшерү иде. Тол елгасы буйлап агып төшү–лагерь тормышында иң кызыклысы һәм истәлеклесе булды. Бу экспедициягә чыкмасам, мин туган җиребезнең шулкадәрле искитмәле урыннарын күрмәгән булыр идем: төнбоеклы су буйлары, тау өстендә шаулап утырган чыршы, нарат урманы, текә ярлары, урмандагы кошлар сайравы.

Күп сулы Тол елгасы Уинск районыннан башлангыч ала. Безнең районга аның урта агымы туры килә. Яр буена күп авыллар: Сараш, Султанай, Төнгүк, Аклыш, Әрҗән, Барда, Бакчавыл, Түбәнавыл, Тауавыл, бу авылларның сабантуй урыннары урнашкан. Без агып төшкән вакытта елга буе гөрләп тора иде: кемдер су коена, палас юа, балык тота, сыерларны көтүли.Кеше күп булса да, яр буйлары чиста, чүп-чар юк диярлек. Бу - районыбыз халкының тәрбияле булуы турында сөйли. Ярый әле Тол елгасы буенда зур шәһәрләр, завод-предприятиеләр юк. Суы мондый чиста булмас иде.Яхшы тәэсирләр белән бергә күңелсез як та хәтеребездә калды: Барда янында Тол елгасына торбадан пычрак су ага.

Якында шундый мул сулы елга булу – ул зур байлык.Дөньяда иң мөһим, кирәкле нәрсәләр арасында, әлбәттә, чиста су, саф һава булу төп шарт. Моны онытырга ярамый.

## ОЧУ ТЕЛӘГЕ

*Зиатдинов Булат, Яр Чаллы шәһәре 7 нче урта мәктәбенең 10 сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Камаева Р.Б*

Айрат бүген көннәр буе, урамнан күзен алмыйча, тәрәзә янында утыра. Көн кояшлы, матур. Өй каршындагы бакча шау чәчәктә. Бакча яныдагы рәшәткәгә кошлар кунган. Айрат шул кошларны күзәтә. Аның да шушы кошлар кебек һаваларга күтәрелеп очасы килә. Теләге зурдан. Айратның әбисе дә: “Балам, барлык эшне дә булдырып була, бик теләсәң”, – ди бит. Айрат бүген өйдә көне буе кулларын җилпеп бик озак йөрде. Өйдә беркем дә юк. Әбисе дә кәҗәсен эзләп инеш буена төшеп киткән. Аның яраткан мәчесе Аккүз дә күренми. Айрат бүген өйдә көне буе кулларын җилпеп бик озак йөрде. Көзгедән үзен күзәтте. Куллары яхшы гына хәрәкәтләнә иде.

Беркөнне Айрат үзенең хыялын тормышка ашыру теләге белән ишегалдында бик озак йөгергәләп йөрде. Аның теләге шулкадәр көчле иде, малай ишегалды белән генә чикләнеп кала алмады урамга ук йөгереп чыкты. Йөгереп тә чыкты Дусты Булат узып бара икән, аңа килеп бәрелде:

– Син нишләп йөгереп йөрисең, эшең беттеме әллә? – дип сорады Булат.

– Киресенчә, эшем бик күп Булат дус, очарга өйрәнәм бит мин, – диде Айрат.

Булат бермәл дустына карап алды да, бик аңлагандай:

– Дустым очар өчен киңлек кирәк шул, әнә кошларга кара, нинди иркендә очалар, – дип, дустын уйга салып китеп тә барды. Дусты Булат елга буена балык тотарга ашыга иде.

Айрат озак уйлап тормады, бакчадагы беседка өстенә менеп тә басты. Бик биек күренә. Янда гына шомырт агачлары, алмагачлар... Чыпчыклар куышып уйный. Менә бит кайда икән иркенлек! Бер адым алга атлыйсың да... Менә шулай уйлап, Айрат кулларын җәеп очып та китте. Шундый рәхәт, битне җылы җил иркәли... Ләкин бу рәхәтлек озакка бармады, малай бакча башына кычытканнар арасына килеп тә төште. Нәрсә булганын аңлар хәлгә килгәч, үтереп тезенең, терсәкләренең әрнүен тойды. Авыртудан күзләреннән яшьләр атылып чыкты.

# ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК

(хикәя)

*Зиннатуллина Эльнара, Башкортстанның Илеш районы Югары Яркәй*
*1нче гимназиясенең 10нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Фәррәхова З.Х.*

Җәйнең ямьле көннәре үтеп китте.

Җәмилә 11нче сыйныфка укырга килде. Аның күңеле бик шат һәм шул ук вакытта бик моңсу да иде. Мәктәп еллары – балачакның иң гүзәл мизгелләре белән хушлашу җиңел булмаячак. Ул, башлангыч сыйныфтан ук, тик яхшы билгеләренә генә укыды.Холкы буенча да бик тыныч, сабыр, тыңлаучан, ярдәмчел булды. Арыса да, авырып торса да, үзе турында уйламады. Һәрвакыт укуда артта калган сыйныфташларына, төрле бәйрәм чараларын үткәргәндә укытучыларына ярдәмгә ашыкты. Өйгә кайткач, әтисе кайтуына ашарга әзерләде, өй эшләрен эшләде. Җәмиләнең әтисе мулла. Атнага бер кызын да мәчеткә алып бара. Бәлки шуңадыр да, ялгыз үстерүенә карамастан, кызына бик яхшы тәрбия биргән. Ә энисе, Җәмиләгә 7 яшь тулганда,каты авырып,бу якты дөньядан китеп барган. Кыз әнисен бик сагына. Әтисе аңа еш кына: “Әниең күктә. Ул һәрчак безнең белән. Безне күзәтеп, уңышларыбызга сөенеп, уңышсызлыкларыбызга көенеп тора”,- дип сөйли торган була. Шуңа күрә, Җәмилә һәркөн кич белән йоклар алдыннан, тәрәзә янына басып, айга карап, үзенең серләре, уңышлары, уңышсызлыклары турында сөйли торган булып китә. Ул шулай итеп күңелен бушата, үзен тынычландыра, юата.

Сентябрьнең өченче көне җитте. Җәмилә иртә торып, чәй әзерләде. Һәрвакыттагыча әтисе белән чәй эчеп,амин тоткач, мәктәпкә җыена башлады. Аның нигәдер иртәдән бирле йөрәге тыныч түгел иде. Мәктәпкә барып җиткәч, кермичә, бераз аптырап басып торды. Кинәт кыңгырау шалтыравын ишетеп сискәнеп китте һәм ашыга-ашыга алга атлады. Йөгерә-атлый сыйныф бүлмәсенә ашыкканда, кемгәдер килеп бәрелеп катып калды. Шунда ул бик таныш тавыш ишетте:

- Кая ашыгасың бу кадәр, кеше өстенә менә-менә?

Бу сыйныфташы Заһир иде. Егет күптән түгел бу мәктәпкә күчеп килде.Ул тәртипсез, хулиган малай булып үсте, чөнки начар компаниядәгемалайлар белән дуслашты. Ләкин аның күңеле бик яхшы иде. Дуслары нинди дә булса начарлык эшләргә җыенсалар: “ Нәрсәгә кирәк бу безгә, бу бит бик начар дусларым”,- дип туктатырга тырыша иде. Ә дуслары аның сүзенә колак та салмый. Шулай итеп ул үзе артыннан ияртә алмыйча, алар артыннан ияргергә мәҗбүр була иде. Авылда нинди генә начарлык эшләнмәсен, һичшиксез, аның дуслары катнашлыгында була иде. Шуңа күрә, яманаты чыккан бу егетнең тавышын ишетүгә Җәмилә куркып калды. Шулай да күзләренә карап:

- Гафу ит, кыңгырау шалтырады. Мин дәрескә ашыгам,- диде дә йөгереп китеп барды.

ӘЗаһир: “Бик чибәр икән бу кызый: ямь-яшел күзләр, иңнәренә сарылып төшкән сары чәчләр. Нишләп элегрәк игътибар итмәдем икән минаңа?!”- дип уйлап куйды.

Бу хәлдән соң ике атна вакыт үтте. Җәмилә Заһирдан качып йөри башлады, чөнки ул аның карашын, үзе артыннан күзәтүен сизеп тора. Моңа кадәр башка малайлар аны шаярталар, ирештерәләр, үчеклиләр иде. Шушы ике атна эчендә аның ягына борылып карарга да курка башладылар. Ә егет кызны ничек булса да үзенеке итәргә булды, чөнки ул аңа гашыйк иде.

Дәресләр беткәч, Җәмилә драмтүгәрәккә китте. Заһир моны белеп алды да: “Түгәрәккә йөрсәм, мин аңа якын булам һәм теләгемә ирешәм”,- дип уйлады.

Түгәрәккә йөрергә теләгән укучылар актлар залына җыелды. Соңга калып Заһир да килеп керде. Барысы да аңа аптыраулы караш ташлады.Түгәрәктә, спектакль куяр өчен, рольләр бүлә иделәр. Сөйләшеп куелгандай, баш рольләрне Җәмилә белән Заһирга бирделәр.

Түгәрәктән соң Җәмилә өенә ашыкты. Кинәт аның каршында Заһир пәйда булды. Кыз сискәнеп:

- Ни кирәк сиңа?-диде.

Егет:

- Әллә нәрсә уйлама, Җәмилә. Миңа синең ярдәмең кирәк. Минем бер дә спектакльләрдә катнашканым юк. Бергәләп кабатласак яхшы булыр иде, - диде. Кыз ризалашты һәм алар дус булырга сүз куештылар. Бу вакытта, алар икесенең дә йөрәкләрендә нинди хисләр кабынуын аңламыйлар иде әле.

Шул вакыйгадан соң, Заһир бик үзгәрде. Дәрес, түгәрәктән соң өенә ашыгыр булды. Иптәшләре начар эшләр эшләргә җыенганын сизеп, җаен табып читтә калырга өйрәнде.

Менә бер көнне, тәнәфес вакытында, Җәмилә Заһирны эзләп китте. Аларның кабатлыйсы вакытны билгелиселәре бар иде. Ул һәрвакыттагычадуслары белән тәрәзә янында басып тора иде. Җәмилә:

- Заһир, бүген ничәдә күрешәбез? Кабатларга ике атна вакыт калды,-диде.

Егет беразга тынып калды. Иптәшләре алдында, ничектер, оялды һәм күңеленнән бер төрле җавап бирергә уйласа да, теле икенче төрле тәтелдәде:

- Нинди очрашу,нинди кабатлау? Әллә укый торгач, башың киттеме кызый?

Җәмилә беразга катып калды, аннан соң йөгереп мәктәптән чыгып китте. Ишегалдындагы алмагачка сөялеп тын ала алмыйча тордыда туктый алмыйча үксеп елап җибәрде.Аның йөрәге сыкрап сызлады.

Ә Заһир дөрес эшләмәвен, үзен дуслары янында “текә малай” итеп күрсәтер өчен, яраткан кешесен гаепсезгә рәнҗетүен бик тиз аңлап алды. Үз-үзен белештермичә аның артыннан йөгереп чыкты да:

- Җәмилә, гафу ит. Мин ул сүзләрне әйтергә теләмәгән идем. Син миңа бик кадерле,- дия алды. Кыз күз яшьләрен сөртте дә:

- Заһир, син әйтәсесүзләреңне дусларың янында әйттең инде. Оныт барысын да, шулай яхшырак булыр, - дип китеп барды.

Егет, кыз күздән югалганчы, аның артыннан каккан баганадай карап торды һәм ничек булса да гафуүтенү юлларын эзли башлады.

Икенче көннең киче җитте. Җәмилә белән әтисе ашарга җыеналар иде. Кемдер ишек шакыды. Әтисе чыгып ачты. Ишек катында Заһирның тавышы ишетелде:

- Җәмиләне чакырыгыз әле, мулла абзый. Бик нык кирәк иде. Минем аңардан гафу үтенәсем бар. Мин аны бик нык рәнҗеттем,-диде. Заһирның кем икәнен белгәнгә, кызының аның белән очрашуын теләмәгәнгә, каты гына итеп:

- Ул өйдә юк,- диде. Ишек артында барысын да ишетеп торган кыз, егетнең тавышында чын-чынлап үкенү, ялваруны сизеп, әтисенең каршы булуына да карамастан үзе килеп чыкты. Алар бик озак сөйләшеп аңлаштылар һәм шул көннән кабат очрашып, спектакльгә әзерләнә башладылар.

Менә көтеп алган көн килеп тә җитте. Җәмилә иртәдән бирле үзенә урын табалмыйча йөрде. Ә Заһир киресенчә бик тыныч иде, чөнки аның янында сөйгәне. Ул янында булганда, аңа бернәрсә дә кирәкми һәм ул бернәрсәдән дә курыкмый.

Спектакль бик уңышлы үтте.Җәмилә белән Заһир да рольләрен бик килештереп башкардылр. Шуңа да тамашачылар аларны көчле алкышларга күмде. Спектакльдән соң егет кызны озата бармакчы иде дә, булмады. Әтисе ишек төбендә көтеп тора иде,аның ачуы йөзенә чыккан:

- Кайткач сөйләшәсе булыр,-диде.

- Ярар, әти. Сиңа спектакль ошадымы?

- Әйе, кызым,-диде ата кеше йомшара төшеп.

- Әтием, нигә син бик моңсу?

- Җәмилә, кайткач.

- Ярый.

Өйгә кайткач, Җәмилә ашарга әзерләде. Әтисе бик уйланып йөрде, ләкин кызга берсүз дә әйтмәде. Ашап дога кылгач, әкрен генә сөйли башлады:

- Кызым, ул егет белән башка аралашма. Син аның нинди икәнен беләсең, тиң түгел ул сиңа. Аңла, мин сиңа начарлык теләмим.Очрашуны хәзер үк туктатмасаң, соңыннан авыр булачак. Заһирга үзең турында барысын да сөйләмәгәнсеңдер бит?

- Юк, сөйләмәдем. Ул аны белергә тиеш түгел.Очрашуны туктатырмын. Мин аны яратам, шуңа күрә туктатам да.

- Ярар, кызым, сөйләштек.

Бу төнне Җәмилә йокламады. Ул төне буе елап чыкты. Башында һаман шул бер сорау бөтерелде: “Мин нинди начарлык эшләдем? Ни өчен мин?Минем бәхетле булырга хакым юкмыни?”

Иртән аның тамагына ризык бармады. Шул килеш мәктәпкә китте. Анда аны Заһир каршы алды. Ул бүген кызга үзенең бөтен уй-хисләрен сөйләргә булды.

- Җәмилә, саумы. Безгә очрашып сөйләшеп алырга иде.
- Саумы, Заһир. Сөйләшик соң.
- Әйдәбүген кинога барыйк. Шунда барганда сөйләшербез дә.
- Юк.
- Нигә, мин билетлар да алдым бит инде?- дип аптырап калды егет. Кызның кәефсез икәнен башта ук сизгәнгә күрә ашыга-ашыга тезеп китте:

-Җәмилә мин сиңа беренче күрүдә үк гашыйк булдым. Яратам мин сине!

- Заһир, исеңдә булса, мин сиңа теге вакытта ук, без дуслар гына була алабыз дигән идем. Мине яратырга ярамый. Мин...- Кыз сүзен сөйләп бетерә алмыйча һушын югалтты. Егет аны күтәреп кочагына алды:

- Җәмилә, Җәмилә уян! Нәрсә булды сиңа? Җәмилә, Җәмилә...

Ләкин кыз уянмады.“Ашыгыч ярдәм” машинасы аны хастаханәгә алып китте. Заһир да шәфкать туташыныңярамый дигән сүзләренә карамыйча, терәшә-терәшә машинага утырып барды. Ул төнне шунда үткәрде. Таң атты. Заһир янынатабибкилде. Ул ялварулы карашын аңа төбәп:

- Абый, Сез булса да әйтегезче, нәрсә булган аңа?
- Улым, сиңа кайтып ял итәргә кирәк, бик арыгансың.
- Юк, нәрсә булганын белмичә кайтмыйм,- дип кырт кисте егет. Табиб дөресен сөйләп бирмичә котылып булмаячагын аңлады һәм Җәмиләнең йөрәгендә чире барын, бәләкәй чактан ук шуның аркасында күп газаплар чигүен, бу чирнең бернинди дәвага да бирешмәвен, көннән-көн хәленең начарлана баруын сөйләп бирде.

Заһир ничек хастаханәдән чыгып киткәнен дә, ничек өенә кайтып җиткәнен дә хәтерләми. Аның уйлары гел сөйгәне турында булды: “Ни өчен аның Җәмиләсе, ни өчен?”Бу төнне ул тагын йоклый алмыйча уздырды. Сөеклесенә берничек тә ярдәм итеп булмаганга, аның үзәкләре өзелде, җаны әрнеде, үзенә урын таба алмады.

Бу вакыйгадан соң, бер атна вакыт үтте. Бу көннәрне Заһир аның янында үткәрде. Җәмиләне хастаханәдән чыгарганда да янәшәсендә булды. Ничек булса да кәефен күтәрергә тырышты. Кыз, күңел төшенкелеген сиздермәскә тырышса да, күзләрендә тирән моңсулык ятканы күренеп тора иде. Шушы кичне егет аны су буена чакырды. Әтисе дә аларның бер-берсенә чын-чынлап гашыйк икәнен аңлады һәм каршы килмәде.

Су буе. Күктә тулган ай, җемелдәп торган йолдызлар, челтрәп аккан чишмә тавышы, төрле кошларның моңлы итеп сайравы күңелләргә ямь өсти. Нинди серле төн!Шушы төндә Заһир Җәмиләгә тәкъдим ясады. Кыз егетнең назлы карашларына төбәлеп, шатлыктан яшьләнгән күзләрен сирпеп ризалыгын белдерде. Бар табигать аларга шаһит булды. Бу вакытта, бөтен дөньяда алардан да бәхетле кеше юк иде. Таң алдыннан бер-берсенә вәгъдәләр бирешеп аерылыштылар.

Авыр имтиханнар да, мәктәп еллары да артта калды. Күпмедер вакыттан соң яшьләр өйләнештеләр. Бик матур итеп туй ясадылар. Пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп, бәхеткә күмелеп яшисе генә иде дә бит... Юк шул... Рәхимсез язмыш үзенекен итте. Туйдан соң ике ай вакыт үткәч, Җәмилә кабат хастаханәгә керде һәм бу юлы табиблар аны алып кала алмадылар.

Авыр, бик авыр кичерде Заһир бу кайгыны. Шулай да сөйгәненә биргән сүзендә тора алды:медицина институтына укырга кереп белем алып, зур табиб булды. Күп кешеләрнең гомерен саклап алып калды.Вакыт-вакыт ул вәгъдәләшкән су буена төшеп, тулган айга карап, эчен бушата торган булып китте.

Әйе, вакыт дәва,-диләр. Еллар үтү белән Заһирның да йөрәк яралары бераз төзәлә төште. Үзе кебек үк һөнәрне сайлаган кызга өйләнде һәм беренче кызы туу белән Җәмилә дип исем куштырды.Язмышлардан узмыш юк дигәндәй, тормыш шулай әкрен генә үз җаена ага бирде.

## СИН БИТ МИНЕ ҮЗЕҢ ЭЗЛӘП ТАПТЫҢ...

*Ибраһимова Алсу, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Хәйруллина Ә.С.*

Син бит мине үзең эзләп таптың,
Җылы җәйләр узып барганда,
Күңелемдә инде көзге салкын
Әкрен генә урын алганда.

Шакымыйча кердең ишекләрне,
Сизми калдым йозак ачканым,
Тоясыңмы минем хисләремне?
Канатларсыз җирдә очканым...

Җылы хисләр, гүзәл сөю белән
Күрешкәнем әле булмады.
Аңламыйм шул, мәхәббәтме икән
Тынычлыгым минем урлады?

Сәбәпсездән елмаямын хәзер,
Кирәкмәстән елыйм һәм көләм!
Йөрәгемә бирер идем әмер
Туктап булмаслыгын мин беләм.

## САГЫНУ ХИСЕ....

*Идрисова Гүзәл, КФУның Алабуга институты студенты*

Туган җирне сагындыра, диләр,
Читкә киткән абый-апалар.
Яшь чагында аңламыйбыз, диләр,
Кызыктыра, диләр, калалар.

Сагынабыз, диләр, урамын да,
Коесын да туган авылның.
Үтә вакыт, ләкин берничек тә
Басып булмый күңел давылын.

Ашкына ул иркен болынына,
Уйнап үскән дуслар янына.
Төшерә дә искә яшьлек минутларын
Сагышлардан бераз арына.

Кайтыр идек, кайтып булмый, диләр
Эш җибәрми, бурыч, акчалар...
Шуңа күрә йөрәк кушканнарын
Соң кат күрә алмыйча калалар.
Ә туган җир көтә балаларын,
Ялгыз ана кебек, сагынып.
Түзем генә көтә, сабыр итә
Сорый белми елап, ялынып.

## ТУГАН ТЕЛ

*Имамиева Айсылу, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Саттарова Г.Г.*

Һәркемгә дә газиз ана теле,
Җырдай моңлы татар теле,
Үз телемдә сөйли алам,
Татарча мин шигырь язам.
Туган телдән илһам алам,
Мин дә синең газиз балаң,
Туган телнең матурлыгы-
Татарымның горурлыгы.
Бик кыйммәтле хәзинә ул,
Тукай теле – татар теле.
Беркайчан да онытылмас,
Анам теле – татар теле.

## САГЫНСАҢ УЧЛАРЫҢНЫ БИТЕҢӘ КУЙ

*Исхакова Рәзилә, Әлмәт политехника техникумы студенты*
*Җитәкче: Хайруллина З.В., Камалова З.Ә.*

Караңгы, салкын, айлы көн. Алар, тар сукмактан икәү атлап баралар. Икесе дә уйга батканнар. Алар бик күп ялганны, авырлыкларны, хыянәтне бергә кичерделәр. Язмыш аларны аерса да, бирешмәделәр, бәхетләре өчен көрәштеләр. Тагын кавыштылар. Инде боларны үткәч, кыз эчтән генә сөенде, Ходайга рәхмәтләр укыды. Егет тә кызның кадерен белә, элекегедән дә катырак ярата кебек тоелды. Ләкин бу озакка бармады. Бер атнадан егет тәмам үзгәрде. Шалтыратмый, шалтыратса да матур итеп сөйләшми. Күңелсез үткәннәр турында сөйли. Кыздан көлә башлады. Кыз түзде, үтәр диде. Тик үтмәде. Егет бөтенләй читләште.

Менә бүген дә алар бер-берсенә берни дәшми янәшә атлыйлар. Кыз егеткә әйтәсе сүзләрен уйлый. Ничек башларга кыймыйча әкрен генә атлый. Менә ул бар көчен җыеп, сүз башлады:

- Беләм, синең миңа булган хисләрең инде күптән сүнгән. Синең миңа килеп гафу үтенүең бары тик сагыну гына булган. Ә мин моңа ышандым. Янәсе ул мине ярата. Ул миңа килде. Күңелем мине алдамаган дип сөендем һәм сине элеккегедән дә катырак яраттым. Мин синең тормышыңнан югалам. Үз-үземә каршы килсәм дә, китәм. Мин сиңа яхшы булсын дип китәм. Бу юлы башка кайтмаска дип. Тик син мине сагыначаксың. Яратмасаң да, киләчәк бер көн, миңа кабаттан кайтасың киләчәк. Чөнки, мин яраткан кебек сине башка беркем дә яратмаячак. Тик ул вакытта соң булачак. Мин инде синең белән булмаячакмын.

Кыз, егетнең кулын алып, аның учларыннан үпте.

- Сагынсаң учларыңны битеңә куй. Мин анда үземнең үбүләремне калдырдым.

Бу кызның егеткә әйткән соңгы сүзләре иде. Ул сүзендә торды. Егетнең тормышыннан юкка чыкты.

Егет аны эзләмәде. Баштарак ул күңел ачты. Дуслары белән эчте. Көн саен кызларны алыштырып торды. Берни турында уйламады. Бер мәгънәсез яшәде, бер ел гомере шулай узды.

Ә беркөнне ул үткәннәрне исенә төшерде. Аны ниндидер аңлатып булмаслык хис биләп алды. Аның белән болай булганы юк иде. Ул “кечкенә кызчык”ны сагынды. Үзе дә сизмәстән учларын битенә куйды. Җылы булып китте. Күңелне рәхәтлек биләп алды. Ашыгып телефонын алды һәм кайдандыр номерын табып аңарга шалтыратты. Ләкин анда “элеге номер кулланылмый” дигән сүзләр яңгырады. Кабат-кабат шалтыратса да, ул шул ук сүзләрне ишетте. Егет кыз турында таныш-белешләрдән, уртак дуслардан сораштырды.

Кыз булган вакыйгалардан соң үз эченә бикләнде. Дуслары белән аралашмый башлады, туганнардан читләште. Аңа егетләр матур сүзләр әйтсәләр дә, артыннан яратып йөрсәләр дә, алардан качты, тормышына беркемне дә кертмәде.

Әйе, болай озак дәвам итә алмый иде. Барысын да оныттырырлык, элекеге “баткаклыктан” чыгарырлык егетне очратты ул. Егет, кызның үткәннәрен оныттырыр өчен бик тырышты. Аны чың күңеленнән яратты. Кыз тынычланды, янәдән элеккечә кешеләр белән ачылып сөйләшә башлады, дусларын кире “кайтарды”, ә аның көлүе бик күпләрне сөендерде. Ул үткәннәрне исенә төшермәскә тырышты.

Егет барысы өчен дә гафу сорады. Яратуын белдерде. Ә кыз җавап итеп бары шуларны гына әйтте:

- Мин синнән киткәндә үзем теләп китмәдем, син мине мәҗбүр иттең. Үз тормышыңны үзең сайладың, ә мин теләмәгән тормышны сайларга мәҗбүр булдым. Мин бик кыенлык белән генә элеккеге хәлемә кире кайттым. Син җимергәнне мин янәдән торгызу бәхетенә ирештем. Ә хәзер яратсам да мин синеке булмаячакмын. Минем бәхетле итәрдәй кешем бар. Мине бәхетле итәрдәй кешем бар. Мин аның белән генә булачакмын. Ул син ясаган ялгышларны кабатламаячак. Мин аңа ышанам. Мине сагынсаң, учларыңны битеңә куй.

Кыз китте... Ә егет “кечкенә кызчык”ны югалтканын шул вакытта гына аңлады. Ул учларын битенә куеп, кыз киткән юлга карап калды.

## КИТМӘС ИДЕМ

Авылымнан киткән чакта
Каеннар калды тезелеп,
Кошлар да бит шул чагында
Сайрап калды өздереп.
Сау булыгыз, ак каеннар,
Сау булыгыз, кырларым.
Балачаклы авылыма
Илтә минем юлларым.
Без уйнаган тау битләрен
Яшел юрган каплаган.
Сабый чак гамьсезлегенең
Эзләре дә калмаган.
Бик сагындым бала чакны,
Кайтыр идем яңадан.
Яшел юрган кабул итсә,
Китмәс идем авылдан.

## НӘРСӘ СОҢ УЛ БӘХЕТ?

Мин үземчә аңлыйм бәхетне
Бәхет минем өчен гади тормыш

Өмет итмим алтын тәхетне
Бәхет миңа җаным эштән кайтса
Бәхет мина күршем ишек какса.
Бәхет түгелмени һәркөн кояш чыкса
Зәңгәр күкләр һәрчак аяз булса
Бәхет бит ул пыскып яшәмәүдә
Яшен уты булып яшьнәүдә
Бәхет бит ул хәрбер туар көннең
Кадерләрен белеп яшәүдә!

## ӘТИЕМ

Инде биш ел синсез яшим әти,
Белсәң иде ничек сагындым.
Синең юклыгыңны аңламыйча,
Аллахыма күпме ялындым.
Эх, күрәсем килә, әти, сине,
Төшләремдә генә булсада.
Син исемдә минем һәркайчан да,
Рәсемнәрдә генә калсаң да.
Мин яратам сине әти җаным,
Син һәрвакыт минем исемдә.
Тик кайтарып булмый инде сине,
Аңлыймын мин моны үзем дә.

## ЯШЬЛЕК ЕЛЛАРЫ

Нинди матур еллар,
Тупланалар синдә барысы.
Егетләрнең кайгы –шатлыклары,
Ә кызларның йөрәк сагышы.
Беләсеңме, дустым, сөю нәрсә?
Сөю чәчәк, сөю бер генә.
Яшь вакытта чын күңелдән сөю,
Кабат булмый, була бер генә.
Ул мавыгу түгел, табыну.
Тик берәүгә тугры калу ул..
Төпсез ләззәт, тиңсез сагыну,
Акылыңны җуеп яну ул..

## ЭХ, БУ ДӨНЬЯ КАЯ ТАБА БАРА?

*Кавиева Глюсә, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең*
*10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гатауллина М.Г.*

Эх, бу дөнья кая таба бара,
Кайсы юлга мине озата?
Күңел әллә нишләп тырный-тырный
Йөрәгемдә яра яңарта.
    Эх, бу дөнья күпме газап тулы,
    Күпме нәфрәт анда җыелган.
    Яшь гомерне җәлләмичә язмыш,

Мине сынау белән тотырган.
Эх, бу дөнья, тагын ниләр булыр,
Борчуларга мине төшерде.
Еракларга мине озаткандай,
Күзгә кайнар яшьләр китерде.

## ӘНИЕМ

*Кадирова.Гөлчәчәк, Әлмәт политехника техникумының III курс студенты*
*Җитәкчеләр: Хәйруллина З.В.,Камалова З.Ә.*

Минем дә әни әйбәт
Сөйли белми бер гайбәт
Әниләрне хөрмәтләү –
Монысы яхшы гадәт!

Якты йөзле, шат күңелле,
Уңган һәм бик тә тырыш.
Бакчабыздан җыеп ала
Ел саен бик күп уңыш.

Өлгер дә шул, булдыклы да
Әнием минем, Тәнзилә.
Рәхмәт әйтәм сиңа бүген
Кочаклап үбә-үбә.

## ЧЫН КЕШЕ

Укытучым Кадрия Ринатовнага багышлана

Яши бер шәһәрдә, сөекле укытучы –
Һәркемгә кояштай, нур сибеп торучы,
Ялыгу белмәүче, тынгысыз кеше ул.
Тик белә башкара, иң изге эшне ул.

Шифалы нурлардай, җылыта сүзләре
Тулган ай шикелле ягымлы йөзләре,
Ул мине укыта, иң авыр елларда
Чыгара җитәкләп, киң озын юлларга.

Өйрәтә һәрвакыт, бик гадел булырга
Тормыштан ямь табып, яхшылык кылырга.
Шуңа да, күрәсең, бернигә бирешми,
Атлыймын тормышта гел алга, турыга...
Тырышам, тырмашам чын кеше булырга.

## ШУК ӘМИР

(экият)

*Калимуллина Роза, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Бәхтегәрәева Р.Н.*

Әмир җәй җиткәч, авылга кайтырга ярата. Әби-бабайның хуҗалыгы зур һәм анда аңа бик кызык. Көне-төне болында күбәләкләр артыннан йөгерә, сарыкларны куркыта, тавык һәм чебиләрне интектерә. Бераздан песинең койрыгыннан алып суга ыргытты, казның бөтен

канатларын йолкып чыгарды, кәҗәгә аягы белән суга-суга йөрде. Бер дә әйбәт эшләмәде, хайваннарны куркытып бетерде, шуннан көлеп аның кәефе күтәрелде.

Бу хәл бөтен ишегалды хайваннарын, кошларын бик туйдырды. Берзаман, бөтен кеше йокыга яткач, кәҗә, песи, каз һәм тавыклар җыелыш үткәрделәр.

"Бу малай белән нишләргә?"- бу сорау аларны аптыратты. Алар Әмирне акылга утыртырга җыендылар. Зур план әзерләделәр.

Иртүк Әмир тора, битен дә юмый, хәзер үк өй алдына чыга. Үзе артыннан ишекне ябарга өлгермәде, аны кәҗә сөзде дә, песи аның аягына ябышты. Әмир тигезлекне югалтты һәм суга егылды. Шунда әтәч аның башына сикерде, ә тавыклар әкрен генә Әмир ягына килделәр. Әмир куркуыннан сикереп торды һәм елап өйгә йөгереп керде. Өч көн урамга чыкмады, өйдә генә утырды.

Хайваннарны тик торганнан интектерергә ярамаганны ул аңлады һәм бөтен хайваннардан, кошлардан гафу сорады.

## КЕЧКЕНӘ МАҖАРА
**(әкият)**

*Камашев Марат, Минзәлә кадет интернат мәктәбенең 10нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Мөхәмәдеева А.Б.*

Күптәнме, күптән түгелме, бер бәләкәй авылда, фәкыйрь гаиләдә туган ди бер ир-бала. Ата-анасы аңа Искәндәр дип исем кушкан. Искәндәр бер баладан да аерылмаган, иптәшләре белән дус булып үскән. Аңа унике яшь тулгач, ул төрле могҗизалы хәлләргә очрый башлаган.

Көннәрдән бер көнне ул һәрвакыттагы кебек дуслары белән су буенда туплы уйнады. Туп, көтмәгәндә, елгага килеп төште һәм агып китте. Балалар тупны судан ничек чыгарырга дип, киңәшләшә башладылар. Искәндәрнең алар арасында иң батыр булуы ачыкланды:

-Мин тупны елгадан чыгарам- дип белдеру ясады һәм шул ук минутта суга сикерде дә, күз алдыннан юкка чыкты. Балалар дустын озак көттеләр, ә ул һаман юк, караңгы төшә башлагач, алар барысы дә өйләренә таралдылар. Искәндәрнең ата-аналары, балаларының кайтмавына борчылып, эзләп елга буена киләләр. Төне буе эзләп йөрделәр, ләкин бар да бушка...

Ә Искәндәр белән менә нәрсәләр булган.
Ул суга чумгач, тупны табам дип, озак һавасыз торса, яр буена менмәде. Аны эзләп су төбенә үк төште һәм аңын югалтты. Аңына килгәч, күргәненә шаккаты. Ул ниндидер бер бүлмәдә ята иде, бүлмәнең стеналары алтыннан, түшәме һәм идәне көмештән. Искәндәр яткан ятак алтыннан, мендәре һәм юрганы ефәктән иде. Андагы картиналар да, фотосүрәтләр дә, төрле төсле, матур ташлардан, ә люстра гел мәрҗәннән иде. Бүлмәдә аннан башка бер кешедә юк иде. Искәндәр бүлмәдән чыгарга булды, ишек ачкач, ул озын коридор алдында калды, коридор буенча бик күп ишекләр тезелгән. Коридор азагында ул бер кыз-бала шәүләсен күрде. Якынрак килгәч, ул аны баштан аякка кадәр карап чыкты. Ул кыз диңгез төсле зәңгәр күзләре белән Искәндергә карап тора иде. Кыз искиткеч матур, аның чәч толымын зәңгәр лента урап алган иде. Искәндәр тагын да якынрак килгәч, кыз аңа әкрен генә елмайды да:

- Мин Айсылу, ә син, батыр егет, кем буласың? - дип эндәште.

- Ә мин Искәндәр - дип җавап кайтарды егет.

Айсылу аңа кулын сузды, якынрак танышкач, ул Искәндәргә өен күрстәтергә тәкъдим итте. Өй Искәндәр яткан бүлмә шикелле үк, алтыннан иде. Карап чыккач:

- Син монда юкка гына түгел. Без бик зур бәлага ялыктык, минем әтине явыз аждаһа урлады. Аны син генә коткара аласың – диде яшьләнгән күзләре белән кыз.

Искәндәр аңламый калды, “ни өчен мин?” дигән сорау кат-кат башында әйләнде, бер мизгел эчендә аны курку хисе чорнап алды, ләкин барыбер Айсылуга “юк” дия алмады.

Икенче көнгә Айсылу Искәндәрне төрле тәм-томнар белән сыйлады, ат җикте, аждаһа яши торган урынны аңлатып, юлга озатты. Берничә көн ул эзләп йөрде Айсылу әйткән тауны. Тапкач, ул керде тауга, анда бик караңгы иде. Аждаһа аның каршысына чыкты. Искәндәр кылычын чыгарып, дошманынаташланды. Алар озак сугышкач, Искәндәр җиңүче булып калды. Аждаһа куркып очып китте. Искәндәр Айсылуның атасын коткарып, бергә кайтып киттеләр.

Озакмы, озак түгелме бәйрәм иткәннәрме, вакыт үткәч, Искәндәрнең өйгә кайтасы килде. Айсылу әтисе белән аны алтын, көмеш, күп төрле мәрҗәннәр белән бүләкләделәр дә, өенә җибәрделәр.

Искәндәр өенә ике сандык байлык белән кайтып керде. Әти-әнисе, сөйләгәнгә, әлбәттә, ышанмадылар. Шулай да ул бу маҗараны бүгенге көнгә кадәр елмаеп искә төшерә.

## САРАШ АВЫЛЫ ТАРИХЫНДА ЭЗ КАЛДЫРГАН СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙ

*Кариев Альгиз, Пермь крае Барда районы Сараш авылының Советлар Союзы Герое Шәрифҗан Казанбаев исеменең урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы.*
*Җитәкче: Туйгельдина В.В.*

Туган авылымның мәгариф тарихы гаять бай. Мин аларны язып үтмичә булдыра алмыйм.

19 нчы йознең 2 нче яртысында Сараштa мәдрәсә булуы билгеле. 1886 нчы елдан рус-татар башлангыч мәктәбе эшли башлый. 1918 елда 1 нче совет башлангыч мәктәбе ачыла. 1924 нче елда районда беренче буларак җидееллык мәктәп эшли башлый. Ә 1953 нче елда ул сигезьеллык булып үзгәртелә. 1955 нче елдан урта мәктәп буларак эшли башлый. 1966 нчы елда Сараш урта мәктәбе Советлар Союзы Герое Ш.Казанбаев исеменә лаек була. Шул ук елда мәктәптә авылдашыбыз Ш.Казанбаев хөрмәтенә мемориаль музей ачыла.

Мәгариф тарихында тирән эз калдырган әдәби шәхесләребез безнең горурлыгыбыз булып торалар. Алар: Сәгыйть Сүнчәләй – шагыйрь, драматург, укытучы, тәрҗемәче. Шәриф Сүнчәләй – укытучы, Сараштa укыта. Риза Ишморат - язучы, драматург, 1911-1915 нче елларда Сараштa белем ала.
(Укытучылары – С.Сүнчәләй, Ш.Сүнчәләй). Дания Сарманаева – педагогика фәннәре кандидаты, Сараш мәктәбендә укыган. Рәшит Ягафаров – филология фәннәре кандидаты, фольклорчы, галим, шагыйрь, Рәшит Ягафаров 1964 нче елда Сараш урта мәктәбен тәмамлый. Идият Әширов – шагыйрь, язучылар берлеге әгъзасы, Сараш мәктәбе укучысы.

1908 нче елда күренекле шәхес Сәгыйть Сүнчәләй Пермь губернасындагы Сараш һәм Султанай авылларында укытучы итеп билгеләнә. Ул укытучылык эшчәнлеген башлаганнан соң Сараш мәктәбенең даны еракларга тарала.

С.Сүнчәләйнең укучысы Риза Ишморат “Гомер сукмаклары” дигән китабында бер бүлекне тулысынча Сараш авылына багышлый, ә үзәктә, әлбәттә хөрмәтле укытучылары Сәгыйть һәм Шәриф Сүнчәләйләр.

“Бераз кызурак канлы, кырысрак табигатьле булса да укучылар бик яраталар. Чөнки дәрестән соң, ә атна кич махсус билгеләнгән дәрес вакытында, укучы балаларны җыеп җырларга өйрәтә һәм шул ук вакытта бик матур итеп, моңлы итеп скрипка, мандолинада уйный, яңадан-яңа көйләр өйрәтә Сәгыйть абый”

“Кайвакытларда ул үз шигырьләренә язган көйләрне дә өйрәтә иде.

Укучыларны үзенә тарта торган аның әле тагын бер сыйфаты бар: дәрес алып барганда ул кычкырып-кычкырыпартистларча әйбәт итеп, Тукай шигырьләрен укый иде. Казанга барган саен Тукай белән очрашып, сөйләшеп йөрүен, үзе язган шигырьләрне Тукайга укып

баруын сөйләгәч, укучыларның аңа карата хөрмәтләре тагын да арта. Әнә кем бит безнең Сәгыйть абыебыз!"

Сәгыйть абый Сараштa хатыны Фәридә, уллары Фәрид һәм Таһир белән яши.

Сәгыйть һәм Шәриф Сүнчәләйләр һәр җомга көнне күңел ачу мәҗлесләре үткәрә торган булганнар. Йорт хуҗасы Һәҗәр әби пешергән камыр ашлары белән чәй эчкәннән соң, мәҗлес дәвам итә. Төрле темаларга алып барган бәхәсләр, дөнья хәлләре, әдәбият, театр, музыка турындагы сүзләр, үзенең яңа шигырьләрен кунакларга кычкырып уку ...

С.Сүнчәләйнең иҗатының Сараш белән бәйле булган чорына тукталып китәм. Шигырьләренең купчелеген Сараш һәм Султанай авылларында яшәгән дәвердә иҗат итә. Бу замандагы бөтен кичерешләре, сөенү-көенүләре, өметенең бер сүнү, бер уянуы шагыйрь җанына гына хас булган барлык каршылыклары аның иҗатында чыгылыш таба. С.Сүнчәләй авылны сөя, аның табигате белән хозурлана һәр ел фасылының ямьле якларын күрә белә.

*Аһ, туган, моңлы авыл! Китмәс күңелдән күренешең,*
*Кайгы-михнәт җырлый-җырлый шаулаган моңлы кышың*
*Язгы эссе көндә яуган җылы яңгырларың,*
*Ямь-яшел хәтфә кебек киң-киң уҗымлы кырларың*
*("Авылда актык кич")*

Тормышының иң авыр вакытларында, күңеле төшенклекләргә бирелгән мизгелләрендә, шагыйрь шигырь белән генә юана, кайнап торган хисләрен шигъри юлларга сала:

*"Сез мине коткардыгыз! Сезгә була тордым күнеп!*
*Булмаса, сүнгән идем инде, вакытсыз кимсенеп.*
*Мин әзерләнгәч аварга – сез миңа көч бирдегез!*
*Бирдегез дә изге – үз тәетемә мендердегез!..."*
*"...Әй минем үткән"*

Авылыбызның гаҗәеп табигате, күркәм холыклы халкы Сүнчәләй иҗатына илһам бирә. Мәслән, " Тау биекеме" дигән шигырен Сараш тавына багышлый:

*Тау биекме, син менәмсең,*
*Мен, менә алсаң, тауга мен,*
*Күр яланнар, күр япаннар,*
*Күр бу доньяның ямен.*

Сәгыйть Сүнчәләй безнең авылыбызны Тукай кебек бөек шәхес белән тоташтыручы да дип исәплим мин. Ул хатларында авылыбыз турында еш яза, ә Тукайның хатлары Сарашка юллана.

Тукайга багышлап ул дистәдән артык шигырь яза. Шагыйрь образы Сүнчәләй иҗатында зур урын алып тора. Ул Тукайның үлеме турында фаҗигале хәбәрне Сараш авылында ишетә. Риза Ишморат бу кайгылы хәбәрне болай искә ала: «…әйтерсең ботен доньяны яктыртучы нурлы кояш сүнде... Безнең йөзләребезне генә түгел, бөтен табигатьне, караңгылык басты. Сәгыйть абый күзләре тулы мөлдерәгән яшь аша:

- Балалар! Олы кайгы килде. Сез бик яратып шгырьләрен укый торган, җырлый торган, балаларны да халкыбызны да, чын күңелдән сөюче бөек шагыйребез Габдулла Тукаев вафат булды. Бу олы талант иясен халкыбыз беркайчан да онытмас. Үзе үлсә аның шигырьләре беркайчан да үлмәс, халкыбыз күңелендә мәңге яшәр, - диде.

- Дәрт, моң, хис кешесе С.Сүнчәләй бу хәбәрне бик авыр кичерә. Ул зират коймасы буенда әле күптән түгел генә яшелләнеп чыккан чирәмне тырный-тырный елый.

-Тукай җаным, бәхиллә мине! – дип кычкырып та куя.

Казанга соңгы баруында ул Тукай белән үпкәләшеп кайткан. Соңгы күрешүләре булган икән. Тукай белән татулашып та, бәхилләшеп тә кала алмаганына шулай үкенә, өзгәләнә ул.

Әнә шулай бөек шагыйрь Г.Тукай үлемен Сараш авылы кайгы итеп кичерә. С.Сүнчәләйнең Тукай өчен күз яшьләре Сараш җирендә тама.

*Әй шагыйрь!, белсәң иде, нинди синең кадрең биек;*
*Син Ходайның илчесе – һәр җырларың дога кебек...*

С.Сүнчәләй... Кызганыч... Бик кыска гөмерле була ул, ләкин шушы кыска гына гөмернең 7 елы безнең Сараш авылында үтүе белән без хаклы горурланабыз.

Беренче чиратта, без аңа зур бәяне педагог буларак бирәбез. Ул укучыларына доньяви фәннәрдән төпле белем бирә, аларны дөнья мәдәнияты белән таныштыра, рус теленә өйрәтә.

Укытучының хезмәт нәтиҗәсе укучыда күренә. С.Сүнчәләйнең шәкерте Р.Ишморатның язучы, драматург булып китүе дә моңа дәлил булып тора.

С.Сүнчәләйнең авыл яшьләрен җыеп атна саен җомга кичләрен үткәрүе дә авылыбызны агартуда, аның культурасын үстерүдә зүр аһәмияткә ия. (Сүз остасы Нурла Сандугач та бу кичәләрдә еш булган).

Мин С.Сүнчәләй кебек бөек шәхеслнең эзләре сакланган Султанай авылында тууым, Сараш авылында укуым белән бик горурланам! Ул безнең генә түгел, районыбыз горурлыгы да!

## ГЕРОЙ АБЗЫЕМ

*Кашапова Зилә, Башкортостан Республикасы Салават районы*
*Нәсибаш мәктәбе укучысы*
*Җитәкче: Михайлова М.Ф.*

Бүгенге көннәрдән дәһшәтле Бөек Ватан сугышы еллары ераклашканнан-ераклаша бара. Ләкин вакыт совет солдатлары күрсәткән батырлыкны халыкның хәтереннән, күңеленнән алып ташлый алмаячак! Яу кырында туганнарын, туган илен саклап, үлемнән һич курыкмаганнары безне, яшь буынны, алар белән горурланырга мәҗбүр итә.

Сугышның һәр көне миллионнарның батырлыгы булып тора. Бөек Ватан сугышы башлангач, якташларыбыз читтә калмаган. Салават районыннан 8526 кеше фронтка китә, 5818е генә кире кайта. Якташ геройларыбыз арасында исән кайтканнардан минем абзыем да бар. Ул – Тавил Нигамәтьян улы Шакиров, Бөек Ватан сугышы ветераны, хәрби лётчик, отставкадагы полковник. Минем аның турында сөйләп үтәсем килә.

Тавил Шакиров 1926 елның 12 нче мартында Салават районының Нәсибаш авылында туа. Сугыш елларында Башкортстан Республикасыннан Берлинга кадәр ярты Европаны сыбай үткән ветеран, быел үзенең 90 еллык юбилеен Малаязда үткәрде. Мин аның күптапкыр дәһшәтле еллар турында сөйләгәнен ишеткәнем бар. Ул бер минутка да иңгә-иң терәшеп сугышкан иптәшләрен, мәңгелеккә сугыш кырында ятып калган дусларын онытмый. Күпме сагыш, күпме истәлекләр аның күңелендә!

Сугышка алынганда аңа нибары 17 яшь кенә була. Ул 1944-1945 елларда 1нче Белоруссия фронтының кавалерия полкында сугыша. Гвардия кавалерия полкының җитәкчесе генерал-лейтенант Крюков була.

1944 елның 20 июлендә Польшаны фашистлардан азат итәләр. “Көненә 600 километр үтәргә туры килә, атка атланган килеш 18 сәгатьтән артык юл тотарга кирәк иде,” - дип искә ала Тавил абзый. Иң авыры – Берлин юллары...

Берлин өчен 12 милләттән артык халык фашистларга каршы көрәшә. Эльба елгасына чыгалар. Әтисе белән бер җирдә немецларга каршы сугышканнарын алар белмиләр. 1945 елның 30 апрелендә, авыр яраланып, Нигамәтьян Шакиров батырларча һәлак була. Өчпочмаклы үлем турындагы хаты туганнарына бик озак килми. Пуля документтагы Нәсибаш дигән сүзне үтәли тишкән була.

Хәрби бурычын яхшы башкарганы өчен Тавил Шакиров Бөек Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә. Сугыш беткәч, ул Ригада хәрби хезмәткә кала. Шунда ук авиация училищесен тәмамлый. Прибалтика хәрби округында 30 ел авиация

офицеры булып, 7 ел Германиядә, 3 ел Кубада хәрби хезмәт бурычын үти ул. Отставкадагы полковник 17 ел Латвиянын энергетика министрлыгында элемтә инженеры булып эшли.

Тавил абзыйга гомерлек юлдашы – Нәсибашнын чибәре Рәйсә Рәүф кызы да бик ярдәм итә. Алар 50 ел бәхетле тормыш көтәләр. Кызганычка каршы, 2006 елны хатыны үлә. Тавил абзый, аны кадерләп, Нәсибаш авылы зыяратына алып кайтып җирли.

Бүгенге көнне Тавил Нигамәтьян улы Шакиров Малаязда яши. Улы Олег янына кунакка Ригага да барганы бар. Оныгы Элина журналистика факультетында укый. Еш кына ветераннар рәтендә Тавил Нигамәтьян улы яшь буынга патриотик тәрбия бирергә ярдәм итеп, төрле чараларда катнашты. Февраль, март айларында районыбызның авылларында Әфган һәм Чечняда һәлак булган якташларыбызга багышланган тактаташлар ачкан вакытта чыгышлар ясап йөрде ул.

Тормыш матур, илебездә тыныч гомер кичерәбез. Ә шулай да безнең авылдан күпме сугыш батырларының гомерләре тыныч заманда өзелде. Һәр өйдә әби-бабайлар сугышлар булмасын, балалар интекмәсен, күкләр аяз булсы өчен дога кылалар, аллаһыбызга ялыналар. Сугышлар булмасын, сугышлар булмасын…

## ҮТӘ ЕЛЛАР, КАЛА ХӘТЕР...

*Киямова Элиза, БДУның Стәрлетамак филиалы 2 нче курс студенты*
*Җитәкче: Габбасова Г.З.*

Сугыш! Әлеге дәһшәт турында ишетү белән һәр кеше ниндидер бер эчке тетрәнү кичерә. Күз алдына җимерелгән шәһәр-авыллар, үле гәүдәләр, ятим калган балалар килә... Кешелек өчен моннан да куркынычрак афәт бармы икән дөньяда?
Әйе, илебездә тынычлык урнашканга 70 елдан артык вакыт узып киткән.

Әмма халкым Бөек Ватан сугышының илебезгә нинди зур югалтулар алып килүен беркайчан да онытмый. Сугыш ничә миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган...

Бөек Ватан сугышына минем туган авылым – Бишбүләк районының Дүсән авылыннан гына 150 кешекиткән. Исән-сау әйләнеп кайтыгыз, – дип газиз аналар – улларын, сөйгән ярлар – парларын, балалар – әтиләрен озатып калган. Ләкин аларның яртысы сугыш яланнарында мәңгелеккә ятып кала. Шулар арасында минем карт әтием – Киямов Хаҗи Киям улыда була. Сугышка кадәр колхозда бригадир булып эшли. Яшькенә егет 1941елның июль аенда фронтка китә. 112 нче кавалерия дивизия составында ул Днепрны кичүдә катнаша.Соңгы хатлары да шуннан була. Кызганычка каршы, карт әтиемнең дә язмышы меңләгән совет солдатларының язмышы кебек, яу яланнарында өзелә. 1944 елда гаиләбезгә кайгылы хәбәр килә, карт әтием хәбәрсез югала. Күрсәткән батырлыклары өчен аны“Кызыл йолдыз” медале белән бүләклиләр.

Сугыштан исән кайтып, Бөек Җиңүне каршылаганнар арасында Каюмов Мәгъсүм Газиз улы бар. Каюмов Мәгъсүм Газиз улы 1944 елда сугышка китә. 284 нче батальон составында ул Белорус, Украина фронтларын, Брест, Варшава, Люблин шәһәрләрен азат итүдә һәм Берлинны алуда катнаша. Тыныч тормышка кайткач, Стәрлетамак педагогия институтынтәмамлый һәм 40 елдан артык авылда балаларга белем бирә. Күрсәткән батырлыклары өчен күпсанлы медальләр белән бүләкләнгән: икенче дәрәҗәле Бөек Ватан сугышы ордены, “Берлинны алу өчен”, “Бөек Ватан сугышында Германияне җиңү өчен” һ.б.. Хаклы ялга туктагач та, иҗат эшен дәвам итә. Ул үзенең “Җиденче кое” дигән романын язып бастыра. Шулай ук Дүсән авылыныңтарихын да өйрәнеп, китап чыгара.

Вакыт дигән нәрсә үзенекен итә, су кебек ага. Бер буыннарны икенчеләреалыштыра, тарих китабына яңа битләр өстәлә, вакыйгалар төпләнә, ачыклана яңа мәгълүматләр өстәлә. Тормыш әнә шулай дәвам итә, илебез яши һәм алга бара, бу дәһшәтле сугыштан соң ул

күтәрелә ала. Кеше гомере бик кыска булсада, хәтер һәм истәлекләр гел янәшәдә шулай мәңге яши кебек һәм мәңге онытылмый.

Әйе, сугыш авазлары еракта калса да, бу дәһшәтне күргәннәрнең йөрәкләрендә яралар һаман әрни. Бер буыннарны икенчеләре алыштыра, тарих китабына яңа битләр өстәлә, вакыйгалар төпләнә... Тормыш әнә шулай дәвам итә.Илебез тыныч тормышта яши, алга бара. Кеше гомере бик кыска булсада, хәтер һәм истәлекләр гел янәшәдә шулай мәңге яши һәм мәңге онытылмый. Халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр! Һәм безнең изге бурычыбыз – безгә бүләк ителгән тыныч тормышны саклауһәм киләсе буыннарга тапшыру!

## ТОРМЫШ СЫНАУЛАРЫ

*Кузнецова Валерия, Мамадыш районы Җөри урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Кузнецов В.Н.*

1942 елның көзе коры һәм салкын килә. Ноябрь башына кадәр жиргә кар төшми. Ел азагында сугыш, Надя әбиләрнең дә ишеген кага, алай гына түгел, өйләренә килеп керә. Иренең милициядә эшләгән вакыты була,эштән кайткач,хатынына көтелмәгән хәбәрне җиткерә.

-“Надя, хәрбикомиссариатка чакырдылар, сугышка китәргә повестка бирделәр, миңа жыеныргa кирәк”. Надя әби өй уртасында тораташ басып катып кала.

- “Иртәгә иртүк Тәкәнешкә барып житәргә кирәк”. Надя әби кайгыдан коелып төшә, эшне нидән башларга белми, ирне юлга әзерләргә кирәк.

Иртән иртүк юлга кузгалалар,әтисен сугышка озатырга олы бала буларак улы Степанны да алалар. Әтисе белән әнисе ара-тирә генә сөйләшеп ала.Вакыт-вакыт әнисенең тавышсыз гына елаганын күреп, аны кызганудан Степанның йөрәге сызылып авыртып куя. Аларның һәрберсе тирән уйга чумган...

Тәкәнешкә Хәрби комиссариат янына килеп житкәндә,анда бик күп җигүле атлар,кешеләр жыелган була инде. Гаилә башлыгының поездга утыргач, балаларны уттан, судан сакла, дигән сүзләрен генә аермачык ишетә Надя әби. Улыбелән поезднык үздән күмелгәнче бик озак карап озатып калалар.

Ирен сугышка озатып озакта узмый, Надя әбинеңбашына бик авыр кайгы килә. Берсенә 7 яшь, икенчесе яңа гына 4 яшен тутырган, ике баласы берсе артыннан берсе якты дөньядан китәләр. Калган дүрт баласы да бик кечкенә була. Олысы Степан гына 10 яшен тутырган. Гаилә башлыгы сугышка киткәндә ныклы гына булып калган хужалык, бер ел эчендә, бик авырлык белән генә көн күрә башлый. Хуҗалыкны алып бару бик авырлаша, ашарларына булмый, ягарга утыннары бетә... Урманнары авылга терәлеп торсада,урманга кертмиләр, утын әзерләргә рөхсәт юк. Шул ук елны сугыштан “похоронка” килә. Дүрт сабый белән тол калган әбием бу кайгыны бик авыр кичерә. Замана улы Степанны да, вакытыннан алда олыгайта. Әнисенә олы булышчы, ныклы таяныч була ул.

Шулай җинү көнедә килеп житә. Бәйрәмдәкешеләрнең йөзе кояш нуры кебек якты да,давыллы яңгыр кебек болытлы да була. Бу көнне күпләр әрнеп кайнар күз яшьләрен түгә, чөнки,һәр гаиләнең кеме дә булса бу бәхетле көнне күрә алмый, һәлак булган. Ире сугышта үлеп калган Надя әбинең дә йөрәгеннән кан яшь тама, кайгысын берни белән дә басарлык булмый, ана калган дүрт баласын кочаклап, башкалар өчен сөенеп кайнар күз яшьләре түгәргә генә кала.

Тормыш дәвам итә, әкренләп балалары да үсә. Улы Степан үсеп буйга житә, ул сеңелләре өчен әти дә, абый да була. Кайгы Надя әбинең ишеген тагын кага. 18 яшьлек улы ноябрь бәйрәме алдыннан кичкырын чана җигеп утынга менә. Утынын төягәч, кайтыр юлга

чыга. Шулвакыт аны лесник күреп ала һәм куа башлый. Текә тау итәгеннән төшкәндә чанасы капланып Степан бүрәнәләр арасына кысыла. Күпме яткандыр шул чакта…

Улыкайтмаганга борчылган ана кеше аны эзләп бара һәм улын ярым исән хәлдә таба. Улы бүрәнәләр арасында, кысылган, әледән-әле ыңгырашып куя, тыны бетеп еш-еш сулый. Ана кеше күпме тырышса да, бүрәнәләр арасыннан улын чыгара алмый, ярдәм эзләп авылга йөгерә. Ярдәмсоңара, алар килеп җиткәндәегетнең хәле авырайган була. Улының әнисенә төбәлгән күзләрендә коточкыч курку һәм ялвару: күрәсең, үз хәлен яхшы аңлый.

-“Әни, үләм бит”,- бу сүзләрне тыны кысылып әйтеп, соңгы сулышын тирән һәм иркен ала да мәңгегә күзләрен йома,йөзендә елмаюга охшаган мәңгелек яшьлек битлеге кала. Улының соңгы сулышы белән Надя әбинең дә җаны чыккан кебек була, берни күрми, ни кылырга белми, күкрәк куышлыгындагы йөрәге зурайганнан зурая, авырайганнан авырая,күкрәгенә сыймыйча бугазына килеп кысыла.

Улым.....

Надя әби елап,улының үле гәүдәсенә каплана, кысып кочаклаптынсыз кала.

Унсигез яшьлек улын әбием мәңгелеккә югалта. Әбием нишләсен,бу авырлыкны да йөрәгенә сыйдыра. Вакытлар узу белән улына багышлап күп кенә бәетләр языла. Йөрәк сызлануына түзә алмаган ана, зират юлын күп тапкырлыр таптый. Әбинең өч кызын аякка бастырасы бар бит, шулар хакына дип яшәргә көч таба.

Хәзерге көндә кызлары исән-саулар. Берсенә берсе булышып,балаларына,оныкларына сөенешеп яшәп яталар. Әбием мәрхүм инде... Озак яшәде, әбием. Ходай аңа гомерне, балалары өчен дә, сугышта үлгән ире өчен дә, биргәндер.

Бүгенге көндә Надя әбинең улы үлгән урынны “Степан үлгән елга” исеме белән атап йөртә авылдашлары.

## КЫШКЫ МАНЗАРА

*Куляева Марианна, Түбән Кама районы Югары Чаллы урта мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Хәйретдинова Р.Җ.*

Әкияти, бизәкле ак шәл ябынып,
Килде суык кышның матур көннәре.
Төрендереп карга, бөтен табигатьне,
Салкынайтты кышкы, аяз төннәрне.

Юл буенда карлар тирән эз салдылар,
Арттырырга теләп, яңа елның мизгелен.
Буран белән тәңкә карлар күтәрелде,
Кышның усаллыгын бик нык сиздереп.

Юл буенда озак кунак булды буран,
Яшел чыршы ботакларын күмдерде.
Аннан авыл башындагы агач өйнең,
Кыегына менеп, төне буе шунда үкерде.

Әкрен генә җемелдәшә юлда карлар,
Оча, бөтерелә, адашкандай төнге буранда.
Түгәрәк айның яктысында юлның өсте,
Елтыр-елтыр килә, искә алып һаман да.

Кышның серле, сихри, кыска мизгелләре,
Күз алдыннан китми минем хәзер дә.
Салкын көндә әкрен генә төшә,
Ап-ак кар бөртеге жирнең өстенә...

## ШИГЪРИЯТ КҮГЕНДӘГЕ ЙОЛДЫЗ

*Мазгутова Ләлә, Чистай районы Татар Талкышы*
*урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Шәйхетдинова Г.Р.*

Тукай дөньясы, Тукай рухы... Инде менә гасырдан артык укыйбыз, сокланабыз. Укыган, өйрәнгән саен шигъри чишмәсенең чылтырау моңын, аһәңен, серен гакылыбызның колачлап бетерә алмавын сизәбез. Нидән бу? Тукай турында, аның иҗаты турында күпме фәнни хезмәт, күпме әдәби әсәр язылды. Ә без, сусауны баса алмый интеккән чүл фәкыйредәй, һаман саен Аңа киләбез. Тукай дәрьясының саф суыннан авыз итәбез. Үткен-туры да, моңлы-сагышлы да иҗатына мөкиббән китәбез. Сере нидә?

Даһилар йөз елга бер туа, диләр. Никтер яңа Тукайлар күренми. Шигърият күгендә йолдыз булып балкыган Тукай һәр шагыйрь, һәр каләм тибрәткән иҗат кешесе өчен биеклеккә омтылу ноктасы булды. Хикмәт нидә? Минемчә, Габдулла Тукай шигърияте, аның иҗат теле - әле һаман да ачылып бетмәгән сер. Мавыктыргыч, үзенә тартып-чакырып тора торган сер. Адәм баласы шулай корылган бит: сер бар икән, аның хикмәтенә төшенәсе килә. Тукай теленең тылсымлы көчен ныграк өйрәнгән саен, бу серле шигъри дөньяның асылына якынаябыз.

Яз көненең йомшак җылы җиле
Гасыр аша миңа эндәшә:
“Тукай-шагыйрь, Тукай –Апуш
Пәйгамбәргә бүген тиңләшә.”

Мөхәммәт саләллаһу вә сәлам күк
Кече яшьтән эти-әнисез.
Үксезлекне кичкән-ятимлекне,
Авыр тормыш үткән ул тиңсез!

Алдан күрүчәнлек, сабыр акыл,
Тиңсез иҗат көче, галимлек.
Барысы да бар синдә,Тукай абый!
Үткен-туры хак сүз, гадилек.

Керсез-пакъ җаныңа синең Тукай
Дога булып барсын шигырем.
“Милләт күгендәге йолдыз ул,”-дип
Татар халкы зурлый шагыйрен!

## КЫШКЫ ХОЗУРЛЫК

*Мандрейкина Олеся, Нурлат районы Егоркино*
*урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Газизова Г.У.*

Күбәләктәй кар бөртекләре
Бөтерелеп очып йөриләр.
Гүя безнең белән алар
Серле биюләрен бииләр.

Ак каеннар мамык шәлен ябып,
Тыйнак кына басып торалар.
Яннарында горур солдат кебек

Төз чыршылар сакта торалар.

Мин яратам шушы авылымның
Сабыр, эшчән, тырыш халыгын.
Шушы матурлыктан хозурланып
Илем өчен хезмәт кылуын.

## ӘНИЕМНЕҢ КЫЗЫ ЮК БИТ

*Маркова Ольга, Алабуга шәһәре 8 нче урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Шакирова Л.М.*

Әниемнең кызы юк бит,
Без бит әнигә өчәү.
Әтине дә бергә кушкач,
Без булабыз бит дүртәү.
Әниемнең эше күп бит,
Һәр эшендә булышам.
Елаганда уенчык биреп,
Кече энемне юатам.
Әни минем укытучы,
Ул эшен бик ярата.
Күңелен биреп һәр балага,
Белем орлыклары тарата.
Әниебез бик сөйкемле,
Йөзләрендә нур балкый.
Тәмле ашлар пешергәндә,
Кулларында ут уйный.
Бүген дә без дүртәү эшләп,
Пәрәмәч пешерәбез.
Әниләр көне белән котлап,
Бер көнлек ял бирәбез.

## РӘНҖЕТМИК ҖИР-АНАНЫ!

*Марьина Дарина, Алексеевский районы  Биләр урта мәктәбенең 10нчы сыйныф укучысы.*
*Җитәкче: Фетхуллова Р.Х.*

Бу җиһанда була төрле хәлләр:
Була җилләр, хәтәр давыллар.
Кайда урман яна, кайда йортлар,
Су астында кала авыллар.
Кар көртләре юлга төшә кайчак,
Кай җирләрдә вулкан атыла.
Әй замана, кая бара шулай,
Табигатьме әллә ашыга?
Юк, табигать түгел, без – кешеләр
Үзебез үк ясый хаталар.
Җир ананы рәнҗетәбез кайчак:
Анда – монда чүпләр яталар.
Күр инде, күр, әнә Агыйделкәй
Ярларына бәрелеп чайкала.
Гүя безгә төпле киңәш бирә:
Тирә - якны сакла син, бала!

Әйе, дусларым, саклыйк табигатьне,
Анда гына шундый гүзәллек!
Җир анабыз гына рәнҗемәсен,
Көч тапсын ул безгә түзәрлек!!!
Башка җирдә юк ул гүзәллек!

## МИН – ТЫНЫЧЛЫК ИЛЧЕСЕ!

Җир шарында күпме авыллар бар,
Җир шарында күпме калалар.
Мул тормышта рәхәт яшисе дә,
Ятим калган күпме балалар.
  Әйе, әйе, бу каһәрле сугыш...
  Әфганстан, Чечня, Гудермес.
  Сугышларда башларын салганнар
  Безнең районнан да булды ич.
Тол иттеләр алар сөйгәннәрен,
Ятим калды бала-чагасы.
Таңнар атса, күзләрен дә алмый
Көтте аны ата-анасы.
  Ил өстенә төшкән шул михнәткә
  Китеп бара солдат егетләр.
  Хәрбиләр дә китә шул сугышка
  Барысы да бөркет кебекләр.
Тик бөркетнең канатлары сына:
Мина шартлый, туплар атыла.
Сәламәтлек бетеп, хәле киткәч,
Алар кайта туган ягына.
  Ник туктамый сугыш, әйтегезче?
  Кайсыгыз соң белә дөресен?
  Тик тынычлык кирәк безнең җанга,
  Тик тынычлык алдан йөресен.
Гел кояшлы булсын көнебез.
Кайгы күрми үсик без – сабыйлар,
Аяз булсын тормыш күгебез.
Тик тынычлык кына телибез!

## XIX НЧЫ ГАСЫРГА СӘЯХӘТ...

*Марданшина Ләйсән, КФУ ның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Даутов Г.Ф.*

Бүген 2016 нчы елның 23 ноябре. Мин, көндәгечә мәктәптән кайттым да, өй эше хәзерләргә тотындым, өйдә якты, рәхәт, беркем юк. Тәрәзәдән карыйм, кешеләр каядыр ашыгалар. Кая микән? Кызык.

Берзаман өйдә ут сүнде дә, ишек ачылып китте. Тыштагы кышкы салкын өйгә керде. Нindидер тавыш ишетелә: “Муса, чык әле, чык тизрәк! Сиңа күрсәтәсе әйбер бар. “Минем күңелдә шик уянды. Кем булыр бу?Әтинең чапанын өскә элдем дә, чыктым. Баксам, дустым Каюм икән. Бервакыт шундый хәл булды: Каюмны авыл бер ай эзләде... Инде Каюм бүтән юк, ул үлде дигән хәбәрне таратырга дигән карардан соң, ул кирeдән пәйда булды. Бар авыл шаккаткан иде шул вакытта. Шуннан соң Каюмны урамга да чыгармадылар. Бүген күрәсең әтисе эштә, ул качып кына чыгып киткәндер.

Мин чыктым да, тирә – якка күз салдым, чип – чиста. Каюм гына басып тора. “Муса, син минем иң яхшы дустым, ләкин син минем турында бар нәрсәне дә белеп бетермисең...” Каюмның бу сүзләре минем күңелгә тагын да шик – шөбһә салды. “Ерак түгел безнең авылдан, бер ташландык йорт бар, шул йортта бер карт кына бабай тора, аның исеме Яков, ул бик укымышлы кеше” – диде Каюм. Бар куркуымны калдырып, Каюм белән шул йортка юнәлдек. Шактый бардык без, килеп җитәрәк минем йөрәгемне курку баса башлады. Еракта өйнең ишек төбендә ак сакаллы карт күренде. Ичмасам, ай яктысы да төшми, кап – караңгы. Берзаман, әкияттәге кебек, безнең сукмакка ай яктысы төште, чын әкият иде бу.

Тышкы яктан бер ташландык кына өй, тәрәзәләре,җил – давыл аркасында ватылып беткән. Керергә дә куркыта. Килеп җитүгә безне бер бабай каршы алып, өй эченә чакырды. Ни күрәм бит! Тыштан ташландык йорт булса да, эче патшалар сараена охшаган. Каюм бу могҗизаны күреп аптырамады. Шуннан соң минем “башыма типте”. Бер ай буе ул шушында булган димәк. Ләкин нинди максат белән? Түргә үткәч, ни күзем белән күрим – машина! Каюмның машиналар белән кызыксынганын белә идем, ләкин кем уйлаган бит, мондый машинаны минем үземнең дә гомеремә беренче күрүем иде. Мин сораулы күзләрем белән бабайга карап торам. Бераз шулай карашып торгач, Яков сүз катты: “Бу,балаларым, вакыт машинасы. Минем өчен иң кыйммәтле әйберләрнең берсе. Мин бу машинаны күп гасырлар элек уйлап таптым. Кем дә кем бу машинага утыра, ул үткәненә һәм киләчәгенә сәяхәт итә ала. Ләкин бу машина турында беркем белергә тиеш түгел”.Минем XIX гасырга сәяхәтем нәкъ шулай башланып китте дә инде.

Вакыт машинасы арыш басуына төшкәндә, төн үзенең кара юрганын ябынган иде инде. Кирәк бит ә, берүзем басу уртасында, җитмәсә машинаның ягулыгы бетеп килә. Аның өчен, машина ял итәргә тиеш, чөнки минем монда мәңгегә калуым бар. Тирә – якка күз салдым, алда бер авыл уты күренә. “Шунда барып, бер төн кунсам, иртәгә кайтып китермен” – дип уйлап куйдым.

Авыл бик кечкенә күренә, кайбер өйләрдә ут яктысы күренә, ләкин бик ачык түгел, әйтерсең сукыр лампа якканнар. Авылны бик зур дип әйтеп тә булмый. Юлларда арба эзләре, әйтерсең монда машина йөрмәгән, юллар сазгак. Өйләр бик фәкыйрь күренәләр: койма урынына читән белән уратылган ишегаллары, яңгыр кермәсен дип ямалган түбәләр, болар барысы да моңа дәлил булып тора иде.

Каршыма ниндидер бер кеше килә, минем күңелдә әлеге дә баягы шик. Якынайганнан якыная бара бит теге кеше. Миңа җитәрәк бер метр алдан туктап калды, тора таш басып тора. Ул да мине күрде бугай. Үзе бер 70 яшьләр тирәсендә. Мин барып исәнләшергә булдым:

“Исәнмесез, мин каядыр килеп эләктем, хәтта бу авылның исемен дә белмим”.

“Бу авылның исеме Каргалы була, улым. Син нишләп караңгы төн уртасында болай ялгызың йөрисең?”

Әгәр дә үземнең вакыт машинасында килгәнемне һәм бу гасыр кешесе түгел икәнемне әйтсәм, мине дөрес аңламаска мөмкиннәр. Шуннан соң мин алдашырга мәҗбүр булдым: “Мин күрше авыл малае, сезнең авылга чишмәгә дип килгән идем, адаштым”.

“Сине болай йөрүеңне күрергә мөмкиннәр, син бүген миндә кунарсың, иртәгә үз авылыңа юл тотарсың”.

Бу зур йөрәкле Әбелмәних исемле кеше Каргалыда күп еллар яши икән инде. Өенең эче бик зур түгел. Килеп керү белән зур өстәл, өстәлдә сукыр лампа, кәгазь битләре ята. Чын язучы өстәле диярсең. Чәй эчәргә утыргач, мин бу авыл турында, һәм монда яшәгән халык турында сораштырырга булдым.

Каргалы авылы бик борынгы авылларның берсе икән. Әбелмәних 1782 елда шушы Каргалыда туган. Ул үзен шул авылда яшәүче замандашлары аның әсәрләрен кулдан – кулга күчергәннәр. “Тәрҗемәви Хаҗи Әбелмәних Әльбистәви Әссәгыйди” китабы өстендә эшләвен күрсәтте.

Шуны әйтәсем килә, улым, татар әдәбиятында динилекнең үзенчәлекле бер күренеше булган суфичылык идеяләре дә шактый көчәеп китте. Мин сиңа суфи шагыйрь буларак әйтәм, әгәр әдәбиятыбызны төрле яклап, тирән итеп яктыртырга теләсәк, суфичылык әдәбиятына карата битараф мөнәсәбәт күрсәтергә тиеш түгелбез.

Белсәң, татар укымышлылыары Е. Пугачев восстаниясенә дә актив катнашалар, кызганычка каршы җиңелүләрдән соң, Кавказга китеп, тау халыкларының азатлык хәрәкәтенә кушылалар. Абызагайлар хәрәкәтенең тарихи чикләнгәнлеге, аның эзлекле социаль – политик программасы булмавы ачык күренә. Оешкан хәрәкәт буларак, көрәш мәйданыннан китәләр. Менә син дә мәдрәсә тәмамлап, мулла булырга теләсәң, Диния нәзарәтенә барып, эшкә рөхсәт кәгазе – указ алырга тиеш буласың" – диде.

Шулай тәмләп сөйләшеп утырганда, кемдер ишек какты. Әбелмәних ишек ачырга дип, чыгып китте. Мин чәемне эчеп бетереп, бүлмәнең түр башындагы сәкегә барып утырдым. Ишектән Әбелмәних белән бер кеше керде. "Кем дип торам, Һибатулла дус икән" – дип елмайды Әбелмәних. Бу дус дигән кеше Һибатулла Салихов булып чыкты. "Менә Иске Кандал авылыннан Чебенлегә кайтышлы кереп чыгарга булдым әле" – диде. Шулай ике дус өстәл артына чәй эчәргә утырды. Мин аларның сөйләшүен тыңлап, йокыга киткәнемне сизми дә калганмын.

Иртән мине кесәмдә онытылып калган кәрәзле телефон уятты. Йокыдан торып, Әбелмәнихкә рәхмәтләр әйтеп, кочаклашып саубуллаштым да, арыш басуына юл тоттым. Барсам ни күрәм! Вакыт машинасыннан җилләр искән. Нишләргә инде хәзер? Кире авылга борылсам, Әбелмәних абзыйга нәрсә дип аңлатырмын соң? Юк, болай булмый, нәрсәдер эшләргә кирәк. Ике чакрым ераклыкта ниндидер урман күренә. Бәлки берәрсе машинаны шул урманга таба алып кереп киткәндер. Төнлә ни булмас, барып карарга кирәк.

Урман зур һәм караңгы. Шул вакыт кичә генә әдәбият дәресендә укыган Тукайның "Шүрәле"се искә төшмәсенме! Куркуымнан кулларым калтырый, йөрәгем кага башлады. Ләкин минем уемда хәзер тиз генә вакыт машинасын табып, XXI гасырга кайту.

Шулай урман эченә юл тоттым. Йөри торгач, каршымда бер шәүлә күренеп алды. Куркудан куллар калтыраса да, аякларны атларга мәҗбүр итәм. Ни күрәм бит! Миннән өч чакрым алда – машина. Ничек килеп эләккән соң ул анда? Машина кырыена барып җитүемне сизми дә калдым. Барысы да урынында, ягулык кимегән кимүен, ләкин өйгә очарлык кына җитәр. Ярый, юлга чыгарга кирәк...

Бар булган хәлне искә төшерә –төшерә мин өйгә юл тоттым. XIX гасыр шагыйре Әбелмәних Каргалыйның хикәятләрен тыңлау ди торды бит! Әгәр миннән синең XIX гасыр турында ишеткәнең бармы дип сорасалар, мин аннан да бигрәк, ишеткән генә түгел, күргәнем һәм шул чор кешесенең сөйләвен дә тыңлап утырганым бар дип җавап бирәчәкмен.

Сезнең урман эчендәге шәүләнең кем булганын беләсегез киләдер, мөгаен. Шәүлә дигәнем Габделҗаббар исемле карт булып чыкты. Аның XXI гасырга килеп, укытучы Алсу апага китап калдыруы безнең барыбызны да сихри уйга салды...

## ДИСБЕ
## (хикәя)

*Мингалимова Эльвина, КФУның Алабуга Институты студенты*
*Җитәкче: Габидуллина Ф.И.*

Күптән көтеп алган ял көннәре килеп җитте. Сөмбел әнисе – Шәмсия әби янына кайтырга булды. Туган як һавасын, әнинең җылы кочагын бик сагынган иде ул. Күчтәнәчләр төяп, ниһаять, авылга, туган җиргә кайтып төште. Һаваны тирән итеп сулый-сулый, аның табигатенә соклана-соклана, авыл читендәрәк урнашкан туган нигезгә кыю адымнар белән атлый башлады ул. Капканы ачып керүгә, ишегалдында нидер эшләп йөргән Шәмсия әбине күреп, күчтәнәчләрен җиргә ташлап, янына йөгерде. Килеп, каты итеп кочаклап: "Исәнме,

әнкәй, мин түзә алмадым, тагын кайттым”, – диде. Шәмсия әби дә: “Бик әйбәт, кызым, мунча да яккан идем, бәлешем дә әзер, әйдә өйгә керик. Ана күңеле шулай сизә инде ул”, – дип өйгә юнәлде. Сөмбел күчтәнәчләрен җыйган вакытта ишегалдын күзәтте, һәрвакыттагы кебек чисталык, тәртип.

Кичен, мунча кергәч, бергәләп чәй артында озак сөйләштеләр алар. Һәм шунда, сүз күршедә яшәүче, Сөмбелнең укытучысы Хөллия әби турында китте. Ул апа турында авыл халкы арасында гел уңай фикерләр генә ишетергә мөмкин. Һәрвакыт ачык йөзле, мәрхәмәтле күнелле, нинди генә чак булмасын, ярдәмгә әзер ут әби иде ул. Бик дини кеше: көненә биш вакыт намазын калдырмый, һәр ел саен ураза тота, кулында һәрчак дисбе.

– Әнкәй, Хөллия апа ни хәлләрдә икән?

– И кызым, япа-ялгыз ул. Балаларының кайтып күренгәннәре юк. Иртәгә кереп чыгарсың, аз булса да сөенер, бу арада авырып та тора әле ул, бичаракай...

Иртән әтәч тавышына, туган йортның түбәсендәге ботак эзләрен күреп, балачагын искә төшереп уянып китте Сөмбел. Шәмсия апа табада чыж-чыж коймак кыздыра иде. Бу мизгелдә шундый рәхәт иде аңа.

Ашагач-эчкәч, Сөмбел якындагы кибеткә кереп чыгып, Хөллия әбиләргә юл тотты. Күренеп тора, бу өй әбидән башка беркемгә дә кирәкми. Ишекне беркем дә ачмады. Сөмбел, аны акрын гына ачып, үзе керде. Өйдә тәртип, барысы да үз урынында. Өй түрендәге караватта бер хәрәкәтсез Хөллия әбине күреп куркып калды.

– Исәнмесез!

– Кызыкаем, Диләрәм синмени?, – диде ул кузгалырга теләп.

– Юк, Хөллия апа, мин бу, Сөмбел, күрше кызы, укучыгыз.

– Ә, синмени балакай, әйдә-әйдә уз...

Алар дөнья хәлләрен сөйләштеләр. Сөйләшү барышында Сөмбел әбинең балаларына үпкәсе зур икәнен сизде. Ә ахырдан: – Сөмбел, булдыра алсаң, зинһар, әйт кызларыма һәм улыма, кайтсыннар. Мин аларны көтәм, бәлки, миңа күп тә калмагандыр инде, – дип авыр сулады карчык.

– Сез нәрсә инде, Хөллия апа? Менә күрерсез, сез әле яшәячәксез.

Сөмбел шул ук көнне кичке автобус белән Яр Чаллыга юл тотты. Иртәгә эшкә булмаса да әнкәсе яныннан аерылырга туры килде. Ялгыз ананың сүзләре бик тәэсир иткән иде аңа.

Икенче көнне таныш-белешләре аша Хөллия әбинең олы кызын Диләрәне эзләп табып, шунда китте. Ишекне бик яшь булмаган, ялгыз анага охшаган бер ханым ачты:

– Хәерле көн, мин Сөмбел булам. Хөллия апаның укучысы, күрше кызы.

– Әйе бик шатмын, нәрсә кирәк? – диде ханым саран гына.

– Хөллия апа авырый, хәле бик начар. Сез кайтмаганга бик рәнҗи, үзен гаепле саный, – диюгә, ханымның кулындагы бокалы аздан гына төшеп китмәде.

– Аңлагыз, әни бит ул бер генә. Җир йөзендә аның кебек сезне яратучы, һәрвакыт көтүче юк. Үтенеп сорыйм, бергәләшеп кайтыгыз, әниегез “миңа инде күп калмагандыр”, – дип әйтә...

Диләрә ханым Сөмбел белән сөйләшкәч, шунда ук сеңлесе һәм энесенә килергә кушты. Айгөл белән Камил кичкә таба Диләрәнең ишеген шакыдылар.

Чәй артында Диләрә апа сүз башлады:

– Камил белән параллель сыйныфта укыган Сөмбел атлы бер хатын килде. Ул кичә авылда булган, әнкәй чирли, хәле бик авыр икән. Безгә кайтырга киңәш бирде.

– Нәрсә булган соң, барысы да яхшы иде бит? – диде Айгөл.

– “Миңа инде күп калмагандыр” – дип әйткән, – диде апалары.

Эшләреннән ял алып, бергәләп авылга кузгалды туганнар. Юл буе беркем бернәрсә дәшмәде. Авылга җиткәндә, өчесе дә туган җирне күзәтте. Күренеп тора, авыл үлә бара, йортлар да азайган. Нигә соң бу заманда туган җирнең кадере юк? Нигә соң кешеләр читкә

ашыга? Югыйсә, туган нигезнең барлыгына куанып кына яшәргә кирәк. Авыллар кимегән саен, безнең милләт, тел юкка чыга. Кеше гомере ул дисбе кебек, аның бер төймәсе, безнең язмышта нидер аңлата. Туган нигезгә кайтмау гомернең бер генә төймәсен түгел, берничә төймәсен югалта. Кеше шул дисбесе төймәләрен, үзе дә сизмәстән, төрле якка сибә.

Капка төбенә килеп туктагач, туган нигезнең ни хәлдә икәнен күреп таң калдылар. Ниһаять, өйгә уздылар. Урында яткан әниләрен күреп, Камилгә чаклы күз яшьләрен тыя алмады.

Хөллия әби ап-ак яулык, күлмәктән иде. Ә кулына...ә кулына ул өч дисбе тоткан. Өй эче ялтырап тора. “Әни, әнкәй!”, – диде ул. Тик ана кеше дәшмәде. Якынрак килеп әнисенә акрын гына төртте. Һаман хәрәкәт күренмәгәч, Камил аны үзләренә таба каратты. Хөллия апада яшәү чаткысы юк иде инде...

Икенче көнне Хөллия әбине соңгы юлга озаттылар. Бүген бөтен авыл халкы елый, мәрхәмәтле әби бүтән юк.

Бу вакытта, авыл халкына Караганда, өч туганга авырырак иде. Чөнки алар әниләренең соңгы сүзләрен ишетмичә, аның белән аралашмыйча яшәделәр. Үзләренең ялгышканнарын аңлап, очып, кадерле әниләре янына кайттылар кайтуын. Тик соң иде инде, соң иде...

## САТАШКАН ҖАННАР

*Мингалимова Эльвина, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Габидуллина Ф. И.*

Бәхет эзләүчеләрне
Аңлап булмый беркайчан.
Дөнья бетереп,таптап җирне
Йөри алар һәркайдан.
Алар шундый романтиклар-
Саташкан җаннар,
Бәхет эзләп йөриләр...
Геолог сыман.
Алар үтә тауларны
Сизмичә генә,
Максатына ирешә,
Тырышлар гына.

## КӨНЛӘШҮ

Бүген миңа читен әле.
Бүген сине уйладым.
Сагынудан айга карап,
Очраштыру сорадым.
Мин беләм:
ул сизә,
тоя,
аңлый.
Тик нигәдер миңа җавап бирергә теләми.
Аңлыйм: бу мәхәббәт газабы дип,
Көнләшеп миңа карый.

## ЮГАЛТУ

Болытлы коры кышның салкын көнендә
Син юкка чыктың кояш нурыдай.
Кереп чумдың,эреден бик тиз боздай.

Һәм шул минутта юк булдың хәтердә.
Барысы да үзгәрде шул чак:
Күп ясаган адымнар,
Кыек караган карашлар
Очты хәтердән шул чак.
Тик бер мизгел мәңгелеккә
Калыр йөрәктә яра булып.
Ул да булса синең алдап,
Китүең... хыянәтең.
Сине гаепләмим,була андый хәл,
Тик юк-бар дип,онытып булмый һич тә.
Меңләп чакрым узармын олы юл.
Сагынырсың - тик синеке булмам бер дә.

## ХИСЛӘНҮ

Әйе,мәхәббәт ул – сафлык һәм ярату хисе.
Тик кайбер вакытларда ул юкка чыгаручы кешене.
Күзләрдән яшьләр чыгарып,
күңелнең җепләрен тартып,
әрнетә-әрнетә икегә бүлүче.
Шул чакларда җирдә урыныңны тапмыйча,
үз-үзеңне югалтып,
сахраларга тайпылып
әкрен очучы кош булмыйча,
кем булып каласың соң,тилереп?
Канатларың сына,башың иелә бара.
Күзләреңдә зәңгәр томан,
алдыңда билгесезлек.
Чумасың син шул билгесезлеккә...
Хыял дәрьясына.

## СИН ҖИТМИСЕҢ

Байтак вакыт үтеп китсә дә,
Дустым,
Онытмам әле.
Кар-бураннар арасыннан
Табармын сине.
Карлыгачлар очып китсәләр дә,
Туган якларыннан бер көнне -
Син калырсың.
Җәй җылысын сагынган йөрәкләргә
Син җитмисең.

***

Һәр ел саен
көзләр килә,
Бар дөньяны
алтын төскә күмә.
Сары төсне
Сары сагыш диеп,
әйтүчегә бер дә ышанма.

Сары төстә
күктә янган кояш,
сарылыгы төшми битләргә.
Сары төсе көзнең
сагыш булып
түгелмәсен әле
күңелгә.

## КАРАБАШЫМ – ТУГАН ҖИРЕМ

Туган җирем,газиз җирем,
Ямьле Зәй буйларында.
Язлар җиткәч,Зәй сулары
Ташу булып җәелә.
Авылымны саклап тора
Мәхәббәт "Каравыл" тау,
"Бур" таулары,"Чүмәл" тавы
Ураткан авылымны.
Авылым бик борынгы
Гасырларга сузылган,
"Әби" патша юлы узган
Авылым уртасыннан.
Шул юлларда җәяү йөргән
Бабамның бабалары.
Карабашым бик данлы як,
Кара алтын чыккан як.
Төрле милләттән булса да,
Дус яши бездә халык.
Яше, карты бар да тыңлый
Изге Азан тавышын.

## ЯЛГЫЗ КАРТЛЫК НИНДИ БУЛА?

(шигырь)

*Минехәерова Айгөл, Әлмәт шәһәре 5 нче гимназиянең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Шәйхетдинова Л.С.*

Көн кояшлы, тәрәзә ачык...
Ак яулыклы ялгыз карчык,
Еракларга төбәп күз карашын,
Күзәтәдер болытлар агышын.
    Кулларында дисбе уйный,
    Ялгыз карчык нидер уйлый.
    Өмет итә ахры ул җилләрдән
    Бары хәбәр туган җирләрдән.
Тик...
Тик бу йортка андый хәбәрләр
Бигрәкләр дә сирәк киләләр.
Монда һәркем ялгыз,чыккан истән,
Монда һәркем онытылган күптән.
    Ә шулай да...
    Ә шулай да уйлап карасаң,

Ул ялгыз да түгел шикелле.
Язмышлар бер, тик барыбер,
Үз туганы түгел шул инде.
Картлар йорты...
Нинди авыр сүзләр!
Онытылмый һаман моңсу күзләр,
Ачык тәрәзә, өмет тулы йөзләр...
Сезгә дәшәм, әй, кешеләр!
Олыгайгач, безне нәрсә көтәр?!

## ЯЛГЫЗ ТОРМЫШ АЧЫСЫ

*Мирзаһитова Гөлдания, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Әхмәдгалиева Г.Г.*

Авыл буйкайларын үткән чакта,
Күзем төште ялгыз каенга.
Тормыш юлкайларын үткән чакта,
Тик язмасын ялгыз калырга.
Җилләр исә – каенкай сыгыла,
Ботаклары кабат кайрыла.
Ерак киткән, мәңге киткән җаные,
Кайрыларын урап кыскан кайгы.
Яшәгәндә никтер кадерләмибез шул,
Онытабыз әҗәл киләсен.
Уян кеше, бераз аңлырак бул,
Син дөньяга тик бер киләсең.
Гомер үтә, кеше мәңге түгел,
Килә аңа әҗәл көне дә.
Күрәм барын, үксеп елый күңел,
Кадер белеп яшәүләргә ни җитә.
“Соңгы туйда” ни мәгънә кадерләп,
Исән чакта кадрең булмаса.
Һәр көн саен бәгырең телгәләп,
Эчтән кара мәче тырмаса.
Мохтаҗ кеше ярату-назлауга,
Ач күңелең, ярат син аны.
Мәҗбүр түгел иңдерү тауларга,
Тетрәндерү бөтен дөньяны.

## ӘТИЕМНЕҢ БАХБАЙЛАРЫ
**(мәкалә)**

*Мирсалихов Нәргиз, Мөслим районы Мари Буләр төп гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гыйлфанова Л.М.*

“Атсыз ир – канатсыз кош”, “Ат яхшы булганда, юл кыска булыр”, “Атлы батыр, атсыз ятыр” кебек әйтемнәр бар. Ә өлкән буын өчен ат – иң кадерле хайван: ашатучы һәм җылытучы, авыр хезмәтне бермә-бер җиңеләйтүче дә булган.

Чабыш атлары, юртаклар катнашмаган кайсы Сабан туеның яме бар? Шуңа күрә дә элек-электән татар халкының милли бәйрәме – Сабантуй ат чабышларыннан башланып киткән һәм бу традиция әлеге көнгәчә дәвам итә.

Ләкин атчылыкка игътибар азайды. Ярый әле авылларда бармак белән санарлык булса да, бу хайваннарга изге җан итеп караучы, минем әтием кебек “ат җене кагылган” кешеләр яши. Андый кешеләр булмаса, атлар кирәксез бер җан ияләренә әйләнерләр иде.

Безнең үзебезнең ике баш нәселле юртак атыбыз бар. Алар безнең гаилә әгъзалары кебек. Әтием бахбайларны бик ярата. Режим белән ашата, ел әйләнәсе тренировкага йөртә. Без дә абыем белән әтигә булышабыз: ашарларына салабыз, асларын чистартабыз, йөртергә алып чыгабыз. Әтием атларны байлык туплар өчен түгел, ә аларны чын күңеленнән ératканы өчен асрый. “Шул атларыма утырып бер юыртып керү - миңа теләсә нинди диңгез ярын алыштыра”, - ди ул. Ләкин бер атны Сабан туена әзерләү өчен дә әтиебезгә ни кадәр тир түгәргә туры килгәнен, аннан никадәр тырышлык, сабырлык таләп ителгәнен без яхшы аңлыйбыз!

Ямьле Сабан туйларын тагын да бизәп торучы чаптарлар, авыр йөкләрне саз-пычраклардан ыргылып тартып чыгаручы көчле бахбайлар күбрәк булсын иде. Ат гомер-гомергә кешенең дусты һәм ярдәмчесе булган һәм бу шулай булып калырга да тиеш!

## ТУКАЙГА...

*Мирсияпов Илгиз, Татар Талкышы урта мәктәбенең 11нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Мирсияпова Г.Р.*

Һәр ел саен язлар кайта,
Илһам кайта туган якларга.
Язлар белән бергә Тукай кайта,
Күкрәү булып яңгырый еракка.
Күңелләрем ,Тукай, сиңа дәшә,
Дәресләрем Сиңа тоташа.
Күп нәрсәгә мине Син өйрәттең,
Газиз булган туган тел аша.
Һәр шигырең Синең гыйбрәтле
Бирә безгә үгет, иәсыйхәт.
Күкрәк түрләреңнән сызылып чыга,
Дөреслек һәм ачы хакыйкать.
Тормыш сине күпме сынаган,
Үксез иткән, күпме кыйнаган.
Йөрәгеңнән ургып чыккан
Шигырьләрең җанга сыймаган.
Мин тормышта синнән үрнәк алып,
Гел дөреслек, хаклык эзлимен.
Авыр булган чакларда да
Шигырь язам менә, түзмим мин.
Йөрәгеңнән чыккан һәрбер сүзең,
Әйди безнең татар милләтен.
Саклап калсын безнең буынны
Әсәрләрең,олуг шагыйрем!

## ӨЗГӘЛӘНЕП ӘРНИ ҮЗӘГЕМ....

Йоклый авыл, их, тып-тын урамнар
Әллә инде уйга талганмы?
Ишетелми гармун тавышы да,
Әллә шуңа моңсу калганмы?

Карга чумган авыл урамында
Йөрми кеше, өрми эте дә.
Кая киткән сабый тавышлары,
Күренми бит аяк эзе дә.
Уйлап куям: заман шаукымымы
Ятим иткән авыл дөньясын.
“Телик “ карый, санагындауйный,
Анданиндидәртләр уянсын.
Күрми бала дөнья гүзәллеген,
Табигатьнең сихри бизәген.
Шул хисләргә бирелеп үземнең
Өзгәләнеп әрни үзәгем....

## КУАНЫП ЯШИК

*Мифтахова Альбина, Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер санатор мәктәп-интернатының 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җиәкче: Нигъмәтуллина Ф.Ә.*

Тиздән яз килеп җитәр,
Бөреләр дә уяныр.
Кошларның сайраулары
Тирә-якны шаулатыр.
Юл буйларын чуарлап,
Җил чәчәкләре чыгар.
Әйдәгез, тырышып укыйк!
Уку елы тиз үтәр.
Ә җәй житкәч, әлбәттә,
Ял итәргә туктарбыз.
Инеш, күл буйларында
Су чәчрәтеп уйнарбыз.
Көз җиткәчтен яңадан
Укырга вакыт җитә.
Чү, бик алга китмик әле,
Чөнки балачак үтә.
Һәрбер чорның кадерен,
Куанып, белеп яшик.
Иртүк торгач һәрвакыт,
Матур теләкләр телик.

## КҮҢЕЛЕМДӘ ШАТЛЫК КӨЛӘ

*Мөбәрәкшина Фирдинә, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Нуриева А. Р.*

Бик нык сөям сине, якын кешем!
Син дә мине шулай сөясеңме?
Күзләреңнән бәхетемнең якты нурын күрәм.
Син дә минем күзләремнән шуны күрәсеңме?

Сине генә сөеп тибә минем йөрәк!
Синең йөрәгең дә шулай сөеп тибәме?

Күңелемнән шатлык хисе ташый...
Синең дә күңелеңдә шатлык “көләме”?

Сагынганда, җаным урын тапмый.
Синең җаның нишли шундый чакта?
Кысып кочасылар килә ...
Синеңдәме шулай, иркәм, сагынганда?

Күрешер минутлар җиткәнен
Түземсезлек белән алам көтеп.
Син дә шулай көтәсеңме,
Түземлекнең чикләренә кадәр җитеп?

Дөньядагы үз тиңем дип сөям сине!
Синең дә уйларың шундыймы?
Башка бирәү өчен түгел минем сөю-
Бары сиңа! Синең дә сөюең бары миңамы?

Күңелем белән, йөрәк белән сизәм, тоям-
Синең миңа хисләр чисталыгын.
Минем сиңа булган ак-саф хисләремнең
Син дә сизәсеңме кайнарлыгын?

Барлык хисләрне дә сүздә әйтеп бетереп булмый
Синдә бит беләсең шуны,
Янәшәдә утырып торган чакта
Бар хисемне күзләремнән карап укы.

Күзләремнән укы хисләр юлын.
Иксез-чиксез, бетмәс әсәрсыман ул...
Һәрбер сүзе – безнең үткән сәгать,
Ә җөмләләр – бергә булган якты киләчәк.

## АЧЫ ҮКЕНҮ
**(хикәя)**

*Мөбәрәкшина Чулпан, Мамадыш районы Көмеш Күл төп гомуми белем мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Саматова З.Р.*

Бүген дә Галия апа йокыга китә алмый азапланды. Тынычландыргыч дарулар да, бал салып кайнатылган сөт тә ярдәм итә алмый шул хәзер. Бетеренде, тәмам бетәште Галия. Барысына да шул каһәр суккан аракы гаепле. Андый идемени соң аның улы? “Әнкәем!”-дип өзелеп торган улын “шабашкага” йөри башлагач, алыштырып куйдылармыни?! Башта салгалап кайтуларын арыганга сылтап калдырса, тора-бара тәмам үз кочагына алды шул “яшел елан”. Атасының эчкәненә гарьләнеп елый торган иде, балакаем, үскәч, мин аны авызыма да алмаячакмын дип антлар эчте. Юк шул, ул шайтан бер авызыңа керсә, тиз генә котылырмын димә икән. Әтисе дә шул аракы аркасында 38 яшендә гүр иясе булды югыйсә. Гыйбрәт алырлыгы бар да бит... Исенә төшәр төшүен, тик мине генә вакытсыз кабергә кертер. Кызы үзләренә чакыра, тик яшәгән йортыңны, гомер иткән нигезеңне ташлап китүе

бик авыр шул. Илгизе исерек баштан ут-күз чыгарса.... Алла сакласын... Бөтен гомер буе интегеп җыйган мал юкка чыга бит.

Газаплы уйларыннан арына алмаган ана күз яшьләрен мендәргә түкте. Чү, дөбердәгән тавыш килә, кайтты, ахрысы. Әйе, шул, аның газиз улы. Кадерләп, зур өметләр баглап үстергән йөрәк парәсе. Илгиз исә, анасын уйларыннан арындырып, кулындагы буш сыра шешәсен түргә ыргытты да:“Нәрсә катып торасың, ашарга бир!” -дип кычкырды. Галия апа инде суынып барган ашны бүлеп бирде дә күрше бүлмәгә кереп китте. Тәлинкә ватылган тавышны ишеткәч, аның болай да беткән йөрәге урыныннан чыгарлык булып тибә башлады. “Мә, үзең аша бу каткан ашыңны, ризык та пешерә белмисең, бар күземә күренмә, ычкын моннан!”-дигән боеру аяктан егарлык көч булып яңгырады.

Инде кая барырга? Күршеләргә дә гел-гел керүе оят. Бу вакытта бөтен кеше тирән йокыда. Әрнүле күз яшьләрен коя-коя, су буена юнәлде бәхетсез ана. “Әллә суларга ташланыйммы икән?”-дигән гөнаһлы уйлар да керде күңеленә. Юк, ярамый, андый кешеләрнең җаннары үзләренә урын таба алмый, диләр, болай да озак яшисем калмагандыр инде, тизрәк Ходай җанымны алса иде дип тели-тели таң аттырды ул.

Курка-курка йорт бусагасын атлап кергәндә, Илгиз өйдә юк иде инде.Тиз генә чәен кайнатып эчте дә түрдәге урынына барып ятты. “Ичмаса, көндез бераз хәл алыйм әле,”- дип уйлады ул.

Шау-гөр килгән тавышка уянып киткән Галия апа беравык аптырап торды. Каршысында чәчәк букеты тоткан кызы Алсу белән киявен күргәч, шатлыгы эченә сыймады “Туган көнең белән, кадерле әбиебез!”-дип, оныклары битеннән үбеп алдылар. Пакет-пакет күчтәнәч төяп, әниләрен туган көне белән котларга кайтканнар икән. Әй, Алла, туган көнен дә оныткан икән бит инде ул. Ярый әле кызы бар. Бөтен борчу-мәшәкатьләрен, кайгы-хәрәтләрен оныттырды балалакайлары.

Илгиз, гадәттәгечә, әнисенең туган көнен хәтерләми иде. Төн уртасында кайтып кергән ир, апасы белән җизнәсен күргәч, аптырап китте, әмма исереккә диңгез тубыктан шул, бусага төбендә үк ятып гырлый башлады.

Иртәгәсен Алсу, энесен каршысына утыртып, озак сөйләште. Башта киреләнеп маташкан Илгиз Казанга дәваланырга барырга күнде тагы.

Айдан артык Илгиз Казанда дәвалану курслары үтте. Өйгә ул, балкып, күчтәнәчләр төяп кайтып керде. “Әни, бүтән эчмим, әнием, ант итәм, булды, ташладым. Элек эчкәнем өчен, зинһар, кичер!”-диде. И шатланды Галия апа!

Инде барысы да үзгәрде. Илгиз наркодиспансерда бер кыз белән танышкан икән. Авылга кайткач та аралашып тордылар. Галия апа, хатын-кызның эчкечелектән котыла алуына бераз шикләнсә дә, улының канатларын сындырмады. Тиздән Илгиз өйләнешәчәкләрен хәбәр итте. “Ахыры гына хәерле була күрсен,”-дип теләде ана.

Яшьләр әйбәт кенә яшәп киттеләр. Килен бик чибәр иде, әмма йорт эшләрен бик өнәп бетермәде. Туганнары, сөйләшеп, кафега җыештыручы итеп урнаштырдылар. Берничә ай эшләгәннән соң, Дилбәр өйгә соңга калып кайта башлады. “Ярар, бала тугач үзгәрер әле,”-дип өметләнде Илгиз. Әйе, тиздән Илгизгә ике тамчы су кебек охшаган кыз бала алып кайтты Дилбәр. Сабыйга Гөлназ дип исем куштылар. Галия апаның да шатлыгы эченә сыймады, тик менә Дилбәрнең генә нарасыена бик исе китмәде. Башта: “Сөтем юк,”-дип имезмәде, тора-бара Гөлназны карамый да башлады. Бала үстерү мәшәкате тулаемГалия апа өстенә калды. Дөрес, Илгиз дә нык ярдәм итте. Бик ярата иде шул ул кызын.

Көннәрдән беркөнне Дилбәр бала пособиесе алырга дип өйдән чыгып китте дә кире кайтмады. “Бер дальнобойщикка утырып киткән,”-дигән хәбәре генә килде. Әлеге хәбәрне ишеткәч, Илгиз, ачуын басар өчен, тагын хәмергә үрелде.

Айнымыйча эчкән атада бала гаме калмаган иде, әлбәттә. Гөлназныбалалар йортына алып киттеләр. Галия апаның да йөрәгенә инфаркт булды, аны хастаханәгә салдылар. Алсу

әнисенең караваты яныннан бер генә минутка да китмәде, кияве нинди генә дарулар ташымады, әмма күпне күргән ана йөрәге таң алдыннан тибүдән туктады.

Илгиз анасын озатканда да исерек иде. Барлык җирләү мәшәкатьләрен кияве үз өстенә алды. Өчесен, җидесен уздырганнан соң, Алсулар да китеп барды. Болын кадәр өйдә берьялгызы калган Илгиз кинәт айнып киткәндәй булды. “Бу куркыныч төш кенә булса икән!”-дип, могҗизага өметләнде ул. Ләкин кырыс чынбарлык бөтен дәһшәте белән алга килеп басты. Илгиз төннәрен саташып уздырды, ачы үкенү тойгысы йөрәген телгәли иде. Көн туган саен, зиратка барды, каберенә ята-ята елады. Телендә бер генә сүз: “Кичер, әнкәем, зинһар өчен кичер! Мин генә, бары тик мин генә гаепле! Эһ-һ-һ!!!!”

## КҮРДЕГЕЗМЕ ӘЛЕ БҮГЕН, ДУСЛАР?

*Мөслихова Айгөл, Алабуга шәһәре 9нчы урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Җиһаншина М.И.*

Күрдегезме әле бүген , дуслар?
Тирә - юньдә нинди матурлык...
Онытылып карап тордым бүген
Нинди аклык, нинди хозурлык!!!
Тып-тын калып нурлар чәчте дөнья –
Сокланырга хәтта курыктым.
Сүзләр җитмәс, сөйләп аңлатырга...
Сафлык , аклык ала күз явын...
Туй күлмәге кигән кәләш кебек
Бар дөньяны иңли ап-ак кар,
Табигатьтә шатлык ,бәйрәм бүген,
Никтер җанда тирән тойгы бар.
Күрдегезме әле бүген, дуслар?
Юк күрмәгән көнем, югыйсә.
Ак бүрекле уйчан каеннарны
Түзеп буламы соң күрмичә?

## ҺӘРЧАК САБЫЙ БУЛЫП КАЛАСЫ

*Мөхәммәтҗанова Илзирә, Мамадыш районы Урта Кирмән авылы*
*гомуми урта белем бирү мәктәбенең 11нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Мөхәммәтҗанов И.Ф.*

Алтын көзләр җиткәч, гади яфрак
Өзелеп төшә,коела агачтан.
Яше тулгач, газиз бала да бит
Аерылып китә ата-анадан.
Үтә гомер,олыгаер бала,
Үзе булыр сабый анасы.
Яшел чирәм таптап үскән елга
Килер аның шулчак кайтасы.
Алларында сөелеп әткәсенең
Талгын гына йокыга таласы.
Әнкәсенең өйрәнчеге булып,
Арттан калмый һәрчак чабасы.
Эх, минем нәни балачагым,
Нигә үттең,җитез йөгереп?

Хатирәләр кала,бары хатирәләр.
Булмый синең арттан өлгереп.
Эх,бер куып җитеп сине
Куенымда кысып тотасы...
Һәр адәмнең ашмас хыялы бар:
“Һәрчак сабый булып каласы!”

## КЕМ?

Чәчкәлрнең таҗларын
Түгәрәкләп кем тезгән?
Энҗедәй йолдызларны
Күкләргә соң кем элгән?
Аяк асты бәрхет улән.
Җирне кем катлап тезгән?
Болындагы җир җиләген
Кем су сибеп үстергән?
Язлар җиткәч, кошлар кайта.
Кем чакыра аларны?
Чыбыклардан оя ясый.
Каян укыган ул аны?
Болытлардан су тамчысын
Кем кар итеп яудыра
Кабатланмас бизәкләрне
Кем шулай уеп куя?
Кук йөзенә җиде төсне
Тәртипләп, акмас итеп,
Дугалап,буй җитмәслек
Кем шулай элеп куя
Ай урынына кояш чыкмый,
Көз урынына яз килми.
Ник жир шары әйләнгәндә
Асты өстенә менми?
Шундый тәртип һәм гүзәллек
Кемнең соң кодрәтендә?
Тик бер патша – Аллаһ кына.
Шунын хакимлегендә.

## САГЫНДЫМ, АВЫЛЫМ

*Мөхлисова Таңсылу, Мамадыш районы Урта Кирмән урта гомуми белем мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Шайдуллина Л.А.*

Авылым, сиңа кайтыр өчен,
Гүя коштай талпындым.
Кайттым туган авылым сиңа,
Сине бик сагындым.
Сагындым авылым синең
Киң басу юлларыңны.
Җанга дәва бирә торган,
Саф чишмә суларыңны.

Туган авылым, нык сагындым,
Синең киң урамыңны.
Сандугачлы урманыңны
Тау, болын, кырларыңны.
Синдә тудым, синдә үстем
Тәгәрәдем мин яшел чирәмдә.
Ак мамыктай бәбкә- үрдәкләрне
Саклаганым истә әле дә.
Авылымда сайрый кошлар,
Иң матур көйләр генә.
Алыштырмам сине, авылым,
Гүзәл чит илләргә дә.
Бәхет эзләп йөри кеше
Күз күрмәгән чит- ят җирләрдә
Бәхетле ул, бары туган якта-
Кендек каны тамган нигездә.

**АЛМАГАЧЛЫ ЯЗ**

Язын шау чәчәккә төренеп.
Гөрләп чәчәк ата алмагач.
Тирә-якны нурга, моңга төреп,
Сузып-сузып сайрый сандугач.
Бакчаларга керсәң, чәчәк исе
Иләсләндерә башларны!
Һәр яз саен алмагач,
Кавыштыра гашыйк ярларны.
Бигрәк күңелле яз айлары,
Хисләр чәчәк ата ел саен.
Шуңадыр зарыгып көтеп алам,
Ямьле, алмагачлы яз аен!

**ӘГӘР КОШ БУЛСАМ МИН**

Беләсезме, әгәр кош булсам мин,
Гизәр идем барча дөньяны.
Агачларга кунып сайрар идем,
Күңелемдә булган моң – зарны.
Очар идем, айкап зәңгәр күкне,
Җилпеп-җилпеп ике канатым.
Тал очына басып җырлар идем,
Ак офыкка ташлап карашым.
Тик, кызганыч, мин кош түгел,
Ә гап –гади Ходай баласы.
Ирекле кош булып очар өчен,
Кирәк икән кабат туасы..
Онытмагыз, бу дөньяда-
Без бары кунак кына.
Кадерләрен белик яшәүнең
Яшик куанып кына.
Кадерен белик туганнарның,
кын иткән дусларның.
Газиз әти-әнинең,

Яшьли сөйгән ярларның.
Рәхмәтле булыйк һәрнәрсәгә
Булганына сөеник.
Яшәүләрнең кадерен белеп,
Юк барга без көенмик.

## КЫШ

Алтын кебек ялтырап,
Җир өстенә кар ята.
Җил малайлары аларны
Һәр тарафка тарата.
Бигрәк калын булды инде
Быелгы кар юрганы,
Асылташтай җем- җем карлар
Бизәде бар дөньяны.
Һәр капка, өй түбәләре
Ак мамык башлык киде,
Агач, куак иңнәренә
Мендәр- мендәр кар элде
Һәр тарафта аклык, сафлык,
Җан рәхәте тоясың,
Ходай биргән гүзәллеккә
Сөенеп һич туймыйсың.

## КАР БӨРТЕКЛӘРЕ

Зәңгәр күктә бөтерелеп,
Бии кар бөртекләре.
Ак мамыктай җиңел, йомшак.
Җилдәй җитез үзләре.
Җил канатына утырып,
Әле түбән төшәләр,
Җир битеннән үбеп, янә
Күккә күтәреләләр.
Бер- берсенә һич кенә дә
Охшамаганнар алар ,
Һәрберсе үзгә бизәкле
Булсалар да туганнар.
Җем- җем килеп ялтырыйлар
Җылы кояш нурында
Күңел хисләрен кузгатып ,
Яшиләр кыш җырында

## УКЫТУЧЫМ

*Мурзина Айгөл, Зәй муниципаль районы Чыбыклы гомуми төп белем мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Мурзина Г.М.*

Кайвакытта орыштыгыз,
Алып калдыгыз безне.
Безне инде аңлап булмый,
Гаепләмибез Сезне.
Гаеп Сездә түгел лә ул,

Сез бит усал түгелсез.
Гаеп бездә иде шул ул,
Без инде ул тәртипсез.
Без үзебез укымадык,
Гел Сезне гаепләдек.
Гаепләүләрегез белән
Без хәтта килешмәдек.
Сез яхшы укытучы,
Тәрбияче идегез.
Тормыш көтә белергә
Һәрвакыт өйрәттегез.
Ә без инде шаян, шук,
Бала-чага идек шул.
Сөйләгәнне тыңламыйча,
Уйнап йөри идек шул.
Менә хәзер инде Сез юк,
Сүзләрегез йөрәктә.
“Аңгыра шалкан”, “буш чиләкләр”
Китмәс безнең йөрәктән.

## ӘБИ

*Нәҗипова Әлфия , КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Нуриева А. Р.*

Сәлам әби, – диеп яза башлыйм,
Сиңа дигән шушы хатымны.
Сагынсам да кайта алмыйм,
Укы син, әби, шушы хатымны.

Биш ай узды, алтынчысы китәр,
Син көтәрсең өйдә сагынып.
Әби өчен газиз оныклары,
Алтын мәрҗәннәрдән кадерле.

## ӘНИЕМНЕҢ ТУГАН КӨНЕ

Әниләрнең кадерен без
Бик соң аңлый башлыйбыз.
Алар түзә, көтә,
Без балалар нишлибез?

Бик моңсу да, бик көлке дә,
Килеп чыкты бу шигырь.
Туган көнең белән сине, әни,
Исән-сау, бәхетле бул син бүген.

Бүген генә түгел, һәр чак,
Исән-сау була күр, кадерлем .
Әниләрсез авыр тормыш,
Яшә берүк мәңге, әнием.

Бәхетле бул, кайгы күрмә,
Шатлан син һәрбер көнгә.
Тормыш бит ул үзе шатлык,
Яшә елмаеп син көн дә.

## КАЯ БАРА ДӨНЬЯ

Көндә үлем, көндә сугыш
Кая бара бу дөнья.
Берсе үлә, берсе туа
Бу дәһшәтле дөньяда.

Аңламый шул кабәхатләр
Ана-бала кайгысын.
Кыра бара көндә алар,
Кешеләрнең тормышын.

Күпме бала ятим үсә,
Күрмичә ата-ана назын.
Купме ана күз яшләре
Түгелә көннәр саен.

Барсынада гаепле бер
Сугыш дигән бу дәһшәт.
Аңламый шул фашист дигән,
Алга бара кабәхат.

## ӘНКӘЙ НАЗЫ

*Нәҗипова Диләрә, Алабуга шәһәре 1 нче гимназиянең 11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Нигъмәтуллова Р.Н.*

“Әни” булсын иң беренче сүзең,
“Әни” булсын иң яраткан кешең.
“Әни” диеп дулкынланып торсаң,
Иң бәхетле кеше булырсың.

Әниләрдән якын кеше булмас
Һәрвакытта аңлап торучы,
Терәк булып, һәрчак яннарыңда
“Балам”, – диеп сөеп торучы.

Уңышларың белән куандырып
Яшәсәң син аны гел яратып.
Күңелеңдә синең кояш булыр,
Үз кояшың, һәрчак торыр балкып.

Бу нурлардан әйе, дөнья ямьле
Аллы-гөлле булыр тирә-ягың...
Яшә әле, әнкәй, гел бәхеттә.
Гел кояшлы булсын аткан таңың.

**КЫШ**

Күзем ачсам бүген – хәйран калдым
Бөтен дөнья ап- ак юрган япкан.
Ис- акылым китеп карап тордым.
Мондый энҗе юрган кем соң тапкан?!

Йөгереп  чыктым урам уртасына
Һәм таң калдым, шушы матурлыкка.
Кулларыма алдым мамык карны,
Өрдем... очып китте алар төрле якка.

Кыш – нинди серле, гүзәл ел фасылы.
Кары йомшак, үзе ачулы.
Салкын җиле килеп битне чеметә...
Әй кышкы җил – саф һәм ярсулы.

Кызык хәтта этләр, песиләргә
“Кардан качам”, – дип чабып йөриләр.
Оя эченнән борын чыгарып
Табигатьнең ямен күзлиләр.

**ТУКАЙГА**

*Нигъмәтҗанова Алинә, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Әхмәдгалиева Г.Г.*

Тукай, син татарның җаны идең.
Син – татарның газиз йөрәге,
Шатлыкларын, хәсрәтен дә тойган,
Аңлый белгән иң зур терәге.
Синең өчен үз саулыгың түгел,
Татар саулыгы булды кадерле.
Авыруың якаңнан тотканда да,
Сабыр иттең, булдың түземле.
Мирас булган иҗатың да синең,
Гүя энҗе-мәрҗәннәрдән төзелгән.
Әйтерсең лә, күңел сафлыгың да
Шигъри юлларыңа түшәлгән.
Син илнең, татар тормышының
Ачып биргәнсең бар якларын:
Михнәт чиккән вакытларын да
Матур һәм килешле чакларын.
Инде бер гасыр вакыт үтсә дә,
Синдәй җан атканнар күренми.
Күпме генә “халкым” дисәләр дә,
Син түккән күк тир инде түгелми.
Ләкин сөйгән халкың сине онытмый:
Иҗатыңны һәрчак барлыйлар.
Язганыңны укып, гыйбрәт алып,
“И туган тел” – диеп җырлыйлар!

## ӘНИЕМ

*Низаметдинова Линара, Нурлат шәһәре 3 нче урта гомуми белем мәктәбенең*
*11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Әбүбәкерова Р.М.*

Синең җылы карашың,
Ышанычлы күзләрең.
Күңел түрләремә үтә
”Кызым”, – дигән сүзләрең.

Бу сүзләрдә күпме мәгънә?
Әни йөрәге назлы.
Иркәләп баштан сыйпавы
Җылытып тора җанны.

Киләчәктә мин үзенә
Ярдәм итә алсам иде.
Әни, бер дә картаймыйча,
Яшь килеш калса иде.

Әни рәнҗеше алырга
Язмасын дөньяларда,
Ананың “эх!” – дигәне дә
Төшә ди ул балаларга.

## МӘКТӘБЕМ

Һәр көн саен иртән торып,
Мин сиңа очып киләм.
Син миңа канат куясың,
Кадерле мәктәбем.

Беренче сентябрьдә
Кулларымда матур гөл.
Киләчәкнең якты юлы
Синнән башланадыр ул.

Гомер узар, яшьлек үтәр,
Син калырсың хәтердә –
Белем иле булып минем
Күңелемнең түрендә.

## ТУКАЙ АБЫЙГА
**(шигырь)**

*Нуриәхмәтова Алинә, Актаныш авылы аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүле*
*2 нчеурта мәктәбенең 10 нчысыйныфукучысы*
*Җитәкче:Камаева Э.Р.*

Язмыш аны каккан, суккан
Ятим итеп үстергән.
Кушлавыч, Сасна, Өчиле,

Кырлай аны үз күргән.
Җаек олы шагыйрь иткән,
Казан канат иңдергән.
Тукай язган һәр әсәрне
Халык якын, үз күргән.
Ятим бала моңлы була:
Апуш барсына түзгән,
Балачакның һәр мизгелен
Шигъри юлларга тезгән.
Тукай шигырьләрен укып
Ничәмә буын үскән.
Әхлак, тәрбия, мәхәббәт
Һәрбер балага күчкән.
Бала белән күбәләк
Бүген дә йөри уйнап.
Су анасы һаман туймый
Алтын чәчләрен тарап.
Шүрәленең бармаклары
Бик авырта, беләсез.
Хәзер йөрми кулын болгап,
Акыл кергән, күрәмсез.
Тукай әле һаман сөйли
“Исендә калганнар”ын.
Шүрәле һәм Су анасы
Тыңлый аның зарларын.
Ел да Кырлайга җыела
Әкияти геройлар.
Тукай белән бергәләшеп
Бәйрәм итәләр алар.

## ҺӘЙКӘЛ

(шигырь)

Авыл уртасында һәйкәл,
Анда батыр солдат тора.
Ничә еллар кешеләрнең
Тынычлыгын саклап тора.
Ул да бит газиз ананың
Бер кадерлесе булган.
Киләчәккә төрле матур,
Якты планнарын корган.
Дошман илгә басып кергәч,
Кулына корал алган.
Илен саклап, халкын яклап,
Дошманга каршы барган.
Курыкмаган баш өстендә
Ядрәләр яуганда да,
Дошманга каршы йөзгә йөз
Көрәшкә барганда да.
Явыз дошман пулясыннан
Гомере аның өзелгән.

Кабере аның чит җирләрдә
Гөлчәчәккә күмелгән.
Үзе үлсә дә, исеме-
Халкыбыз күңелендә.
Батыр һәйкәл булып басты
Авылыбыз түрендә.

## ТАБИГАТЬ КИЛӘЧӘГЕ - КЕШЕЛЕК КИЛӘЧӘГЕ

*Нуриева Элиза, Бөгелмә шәһәре 2 нче лицееның 11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Ногманова Д.Р.*

Бөек Россия дип аталган илдә, куе урманнарга,зәп-зәңгәр күзле елга-күлләргә, челтерәп аккан чишмәләргә, яшел хәтфә болыннарга, җиләкле аланнарга, иксез-чиксез иген кырларына бай булган гүзәл Татарстан туфрагында борын-борын заманда түгел, ә ун-унбиш еллар элек зур кара урман уртасында бер Каен кызы яшәгән. Тирә-ягы куе агачлар белән уратып алынган булганга, аңа бер генә җил-давыл да тимәгән. Янында гына чут-чут итеп сандугачлар сайраган, ерак та түгел челтер-челтер итеп чишмә җырлаган, ә инде янәшәсендә үскән Имән егетенең көннән-көн калынаеп, биегәеп китүен, үзенә ягымлы караш ташлавын сизгәч, Каен кызының дөньясы бигрәк тә ямьләнгән. Ул үзенең бик-бик бәхетле булуы, тамырларын туендырган туган җир туфрагының мәрхәмәтлелеге турында шыбыр-шыбыр килеп үзенең дус кызларына сөйләгән. Аларның серләшүен башка агачлар да ишеткән, шомырт, балан, миләшләр дә бу әңгәмәгә кушылган.

“Чынлап та, нинди ямьле безнең туган җиребез! Һәр мизгелдә туган табигатебез матур, нәфис. Кышын, язын, җәен, көзен үзенә генә хас бер илаһи гүзәллеккә күмелә бит ул!Кышын Җир-анабыз, әйтерсең лә, ап-ак мамык белән каплана. Кояш нурлары астында күзләрне камаштырып җемелди. Без дә – бөдрә каеннар, көчле имәннәр, биек наратлар, сылу миләшләр ап-ак шәлгә төренәбез,” – диешкәннәр алар. “Ә яз килү белән гүя барча табигать уяна! Карлар эреп гөрләвекләр ага, елгаларда бозлар кузгала һәм йомшак кар астыннан язның беренче чәчәге – умырзаялар чыга. Җылы яклардан туган җирләрен сагынып, ашкынып кошлар кайта һәм оялар корып, яңа нәсел үрчетә. Җәнлекләр дә уянып, кышкы туннарын алмаштыралар, яңа көчләр белән яңа тормыш башлыйлар. Яз кояшының җылы нурлары астында безнең бөреләребез ачылып, яфрак яра. Җир өсте ямь-яшел хәтфә белән каплана. Язын тирә-як җанлана, чөнки яз безгә яшәргә көч бирә,” - дигән Каен кызы. “Ә җәенбөтен дөнья чәчәккә күмелә. Аларның нindие генә юк: кызыл, ал,сары, зәңгәр, ак һәм башкалар. Чәчәктән чәчәккә кунып күбәләкләр, бал кортлары очып йөри. Агачларда,болыннарда җиләк-җимешләр пешә. Алар да бит безнең туган ягыбызның байлыгы түгелмени?” – дип елмайган миләш агачы. “Алтын көз безнең урманнарга яңа төсләр кертә. Алар шундый булып үзгәрә, хәтта карап сокланып туя алмаслык! Яфракларыбыз сары, куе сары, кызгылт-сары, кызыл һәм башка бик күп төсләргә керә. Гүя алтынга төренәбез.Күп тә үтми “яфрак яңгыры” башлана. Бу шундый матур күренеш, тирә-якта аның белән чагыштырырлык берни дә юк. Без шундыйматур урманда туганга бик бәхетлебез, Ходайга рәхмәтлебез!” – дия-дия сокланды Каен кызы.

Тик бу шатлыклы тормыш озакка сузылмый. Беркөнне кояшлы иртәдә Каен кызына ерактан нindидер ят, куркыныч тавышлар ишетелгән. Ул гына түгел, барлык урман моны ишеткән. Һәммәсе гаҗәпләнгән һәм куркуга калган. Тиздән урман буйлап шундый хәбәр таралган: “Урманга кешеләр килгән!” Һәм тиккә генә түгел, ә газ кудыру корылмасын төзергә! Каен кызы яшьлеге белән бу хәбәргә әллә ни игътибар итмәгән. Аларга әлегәкуркыныч янамаган, чөнки урманның уртасындарак үсеп утырганнар.Ләкин көннән-көн агач кискән тавышлар якынрак ишетелә барган.Тора-бара тирә-якта сандугач сайравы да тынган. Алар инде күптән икенче урманнарга очып киткәннәр. Каен кызының дус кызлары –

балан, шомырт, миләшләр елый-елый корыганнар. Алар кешеләргә бик рәнҗегәннәр, аларның мәрхәмәтсезлекләренә гаҗәпләнгәннәр. "Без ел саен авыл халкын җимешләребез белән туендырып тордык. Алар килеп,ботакларыбызны сындырып җимешләребезне җыйсалар да- түздек, икенче елга яңадан хуш исле чәчәкләргә күмелеп, татлы җимешләр бирдек. Кешеләргә зур файда китерүебезгә чын йөрәктән шатландык. Аларның килүен түземсезлек белән көттек. Әбүген кешеләр безне кисәләр, ботарлыйлар, тамырларыбызны актаралар. Я Ходай, зинһар ярдәм ит! Безне шушы мәрхәмәтсезлектән сакла. Акылга утырт бу кешеләрне!" - дип ялварганнар. Ләкин аларның аһ-зарын беркем дә ишетмәгән, беркем дә ярдәмгә килмәгән. Кешеләр агачларны кисүләрен дәвам иткән. Алар үзләрен бик көчле итеп тойганнар, хаклы итеп санаганнар. Ләкин кешеләр дә бу эшне изге уй белән эшләгәннәр, чөнки газ кудыру корылмасы халыкның тормышын күпкә җиңеләйтәчәк.

Каен кызы гына тирә-яктагы дусларын һаман да югалта барган. Шул сәбәпле ул бик күп елаган, аның күңеле сыкраган. Бердәнбер көнне явыз кешеләр аның иң якын дустын, сөйгәнен – Имән егетен кисеп аударганнар. Бу кайгыдан Каен кызы бөтенләй яшәү көчен югалткан, аңа сулавы да авырлашкан. Кайчандыр шау-гөр килеп утырган урманда ул берүзе генә калган.

Менә газ кудыру корылмалары да эшли башлаган. Саф һаваны пычратып торбалардан әллә нинди зарарлы матдәләр бүленеп чыккан. Кайчандыр урманда иң матуры, иң гүзәле булып утырган Каен кызын шул агулы һава уратып алган. Ул көннән-көн сулган, кипкән. Ә беркөнне бөтенләй яшәү көчен югалткан. Соңгы сулышында Каен кызы: "Кешеләр, нишлисез сез?! Кайдан сездә шулкадәр гаделсезлек, вәхшилек?! Тәңребез биргән гүзәллекне нигә сакламыйсыз? Кылган явызлыкларыгыз үзегезгә кайтачак бит!" – дип ялварган. Ләкин Каен кызының соңгы сүзләрен беркем дә ишетмәгән. Тик искән җил генә аларны еракларга алып киткән...

## TÜRKMEN TALYBY/ ТӨРКМӘН СТУДЕНТЫ

*Оразов Ораз, КФУның Алабуга институты студенты*
*Житәкче: Миңнуллина Р.Ф.*

Bu "Kazan ilinde gezip her yana,
Durmusda men sahyr bolup baryana.
Yatlayan hemise öz dogduk mekanmy,
Sol toprakda oynap gülen çagymy.

Bizleri gorayar ähli yerde-de,
Eziz eneleriñ gyzgyn söygüsi.
Olaryñ herisiniñ yüreklerinde,
Alow bolup yanyar Watan duygusy.

Watanymyñ Türkmenistan adyny,
Bütin dünyä abray bilen yayradyar.
Türkmeniñ buysanjyny Tuguny,
Al-asmanda alyslarda parladyar.

Ählisiniñ kalplarynda bir arzuw,
Ählisiniñ dillerinde bir söz bar.

Diplom bilen ülkesine dolanmak,
Çünki bu pursada hemme intizar.

Watandan dasarda okayan yaslar,
Ata-Enelerñiz guwansyn size.
Dolanmagy yene mährem diyara,
Alladan dileyän her bir biriñe...

## ӨЧ КЫЗ

(әкият)

*Осипов Вадим, Алабуга шәһәре, 4 нче гимназиянең 9 нчы А сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Салихова Р.В.*

Бер авылда, бер гаиләдә бер-бер артлы өч матур кыз бала дөньяга туган, ди.

Ата-ана аларга: Гөлбикә, Нурбикә, Асылбикә дип, азан кычкыртып, исем куштырганнар икән. Гөлбикәсе бик уңган, Нурбикәсе бик белемле булып үскәннәр икән. Ә менә Асылбикә, төпчек кыз булганга, иркәрәк үскән. Апалары өй җыештырган, кул эшләре эшләгән вакытларда, Асылбикә, күбәләк кебек очып, җырлап-биеп, уйнап кына йөри торган булган, ди. Базардан эштән кайтканда төпчек кызга һәрвакыт кәнфит, прәннек алып кайтып, апаларыңа да өләш, дип, капчык-капчык күчтәнәчләр бирә торган булганнар. Әмма, тәмле тамак, саран булганлыктан, апаларына яртышар кәнфит кенә бүлеп бирә торган булган, икән.

Менә кызлар үсеп буйга җиткәннәр. Шул вакытта, әниләре каты авырып киткән. Кызларын чакырып, ул аларга болай дигән.

- Сез – минем кадерле кызларым. Минем сезгә көмештән сырлап эшләгән тимер сандыкларым бар, шуларны алып килегез, – дигән әниләре.

Сабыр, акыллы ана олы кызга дигән сандыкны үзеннән ачтырса, аннан өч пар бәйләнгән оекбаш килеп чыга.

- Кызым, минем сиңа ачуым килгән вакытта, мин синең белән талашмаска, ачуымны сиңа чыгарып тиргәшмәс өчен, дәшмичә калып, йон оеклар бәйләдем. Димәк, әнием мин сине алты тапкыр рәнҗеткәнмен, гафу ит, зинһар, дип ялварган олы кыз.

- Ә хәзер, уртанчы кызым, син ач сандыгыңны, – дигән әни кеше.

Сандыкны ачса, уртанчы кыз ике тегелгән күлмәк күргән.

- Сиңа да кызым, ачуым килгән вакытта, дәшмичә калып, күлмәк тегәргә утырдым, дигән әни кеше.

- Әнием, мин сине тормышта ике тапкыр ачуландырганмын икән, зинһар гафу ит, – дигән кыз.

Менә чират, өченче төпчек кызның сандыгын ачарга вакыт җиткән, ди.Төпчек кыз сандыгын ачса, анда бер бәйләгән мамык шәл һәм илле мең сум тәңкә акчалар ята икән. Төпчек кыз бик сөенгән.

- Әнием мин сине бер генә тапкыр хәтереңне калдырдым, ачуландырдыммы? – дип, сөенеп сорган. – Ә болары нинди акча? – дип сораган кыз.

- Ә болары, кызым, шәл бәйләп саткан акчалар – дип җавап биргән әни кеше.

- Син кызым, комсыз булып үстең, апаларың белән тигез итеп уртаклаша белмәдең. Минем җаным синең өчен әрнегәндә, мин кәҗә мамыгы эрләп шәл бәйләп, сиңа юмартык, акыллылык, уңганлык теләп, сорап дога укыдым Аллаһы Раббымнан, – дигән ана. – Ә хәзер сандыгыңдагы көмеш акчаларыңны апаларыңа тигез итеп, санап, бүлеп бир. Ә сиңа киләчәк тормышыңда, уйланып, дөрес итеп, үз балаларыңны минем үрнәгемдә тәрбияләрсең дип, соңгы киңәшемне бирәм, – дигән Ана һәм күзен йомып ахирәткә күчкән.

# ТАТАР ТЕЛЕН ХӨРМӘТ ИТ, САКЛА ҺӘМ ҮСТЕР!

*Платонова Диана, Биектау районы Бөреле гомуми урта белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Тазмиева Р.М.*

Татар милләте элек-электән белемгә омтылышы белән аерылып торган. Укырга-язарга өйрәнү өчен мөмкинлеге булмаганнарның да өйләрендә кульязма китаплар сакланган, хәтта озын-озын әдәби әсәрләрне дә яттан өйрәнгәннәр, гади крестьяннар да үзләренең соңгы акчаларын җыеп, балаларына азмы-күпме белем бирергә тырышканнар. Акчалырак, дәрәҗәлерәкләр исә, шәһәргә, Бохара кебек ерак җирләргә кадәр барып гыйлем өстәгәннәр. Шуңа күрәдер, мөгаен, татар халкының талантлы уллары, тарихка кереп калырлык талантлы шәхесләре байтак. Бөтен гомере буе халыкка фидәкарьләрчә хезмәт кылган, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре арасында Утыз Имәни, Габдулла Тукай, Шиһабеддин Мәрҗани, Риза Фәхреддин, Гаяз Исхакый, Каюм Насыйри һ.б. бар. Шунысына да игътибар итәргә кирәк: алар барысы да татар телендә иҗат иткәннәр һәм үзләре дә телебезне үстерүгә зур өлеш керткәннәр, татар теленең камил, бөек, аһәңле тел булуын, фән теле булырга тулы хакы һәм мөмкинлекләре барлыгын исбатлаганнар. Мәсәлән, Каюм Насыйри укыту, тәрбия бирүнең, милли үзаңны үстерүнең төп предметы булган телебез турында “Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел”, – дип яза.

Уйлап кына карагыз: татар телендә күпме фәнни хезмәтләр, гүзәл әдәби әсәрләр иҗат ителгән. Әсәрләрдә телебезнең иң матур сүзләре генә кулланылып, энҗе-сәйләннәр тезгән кебек затлы, нәфис, нәзакатьле итеп язылган. Алар дистәләрчә телләргә тәрҗемә ителеп, телебезнең, әдәби байлыгыбызның данын еракларга танытканнар һәм таныталар. Бу – безнең газиз телебезнең, татар теленең бөеклеген тагын бер кат раслаучы дәлил түгелмени?

Милләттәшләребез арасында зур ачышлар ясаган, фән үсешенә тормы-шыбызны камилләштерүгә байтак өлеш керткән галимнәр дә игътибарга лаек.

Иң мөһиме – аларның байтагы фән өлкәсенә үз телебез аша юл салган һәм шуңа хыянәт итмичә, хезмәтләрен дә татар телендә бастырып чыгарганнар. Шулар арасыннан берничәсе турында гына күзаллау булдыру да татар теленең мөмкинлекләре турында югары фикер йөртергә этәрә.

Мисал өчен, татарлардан беренче химия фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән һәм техника эшлеклесе Гыйлем Хәйри улы Камай бөтен дөнья тарихына органик кушылмаларны өйрәнеп ачкан “Камай реакциясе” белән кереп калган. Ике мәртәбә Ленин, өч мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән бу галим – русча-татарча химия терминнары сүзлеген төзеп бастыручы, татар телендә “Химия буенча лекция курслары” дигән дәреслек, “Тормышка ашкан хыял” дигән автобиографик хезмәт һәм башка күп кенә фәнни-популяр мәкаләләр авторы да. Сокланыйк, уйланыйк, горурланыйк! Татар теле менә нинди көчле тел ул! Әйе, һичшиксез, ул – фән теле, ул бөтен кешелек тарихында эз калдырган бөек тел!

Алда әйтелгән сүзләрне татар тарихчылары, татар тел галимнәре, татар фәлсәфәчеләре, татар этнографлары, татар әдәбият галмнәренең күплеге дә дәлилли. Иршад Гафаров, Хәйри Гыймади, Энгель Таһиров, Альфред Халиков, Индус Таһиров, Һади Атласи һәм башкаларның тарих хәзинәләрен ачуда; Шәмсетдин Күлтәси, Казбек Гыйззәт кебекләрнең фәлсәфи мәсьәләләрне чишүдә; Раил Кузеев, Хәмит Зөбәер Кошай, Габделгазиз Монасыйповларның этнографик табышмакларга җавап табуда өлешләре бәяләп бетергесез. Моннан тыш, татар әдәбияты һәм татар тел белеме буенча эшләүчеләр дә дистәләгән. Бу галимнәрнең күбесе татар телен камил белеп, шул телдә фәнни мирас калдырган шәхесләр. Аларның мөһим фикерләре, бөек ачышлары, төрле мәсьәләләрне чишүдәге карашлары безнең үз телебез аша җиткерелгән. Кемнәрдер тарафыннан “урам теле, ломовойлар теле”

дип кимсетелгән татар теле әнә шулай, киресен дәлилләп, дәверләр аша биеклектән кул изи, тыйнак кына үз дәрәҗәсенең тагын да югарырак булырга тиешлеген ассызыклый.

Безнең әби-бабаларыбыз гасырлар дәвамында туган телебезнең исәнлеге, матурлыгы, чисталыгы өчен көрәшкәннәр. Тора-бара аны яклау, саклау, киләчәк буыннарга исән-имин тапшыру өчен көрәш юлына басканнар. Йә, әйтегез: кайда соң хәзер милли үзаңнары шундый югары дәрәҗәдәге яшьләр? Алар бармак белән генә санарлык түгелме? Ни өчен без борынгыларның “Тел бетсә, милләт бетә”, “Теле барлар халык була, теле юклар балык була” дигән акыллы сүзләрен истән чыгарабыз? Ә бит югарыда әйтелгәннәрне тагын бер кат уйдан кичерсәк, телебезнең нинди бөек тел булуын да, аның мөмкинлекләрен дә бик ачык күрәбез. Кызганыч, моны аңлап бетермәүчеләр үзебезнең әйләнә-тирәдә генә дә шактый. Яшьтәшләребез арасында туган телебезне кимсетеп, ике телне бергә кушып сөйләүчеләр, татар телендә җәмәгать урыннарында аралашырга читенсенүчеләр дә юк түгел. Билгеле, күп очракта “Балык баштан чери” – ата-аналар гаиләдә рус телендә аралашып, чын татар гаиләләрендә дә сабыйларыныңа тәрбияне рус телендә бирә. Гап-гади мисал: татар телендә белем алып, татар теле аша тәрбияләнеп үскән икетуган абыем моннан берничә ел элек гаилә корды. Бәхеткә каршы, аның тормыш иптәше дә үз милләтебездән, телебезне, гореф-гадәтләребезне яхшы белгән акыллы кыз. Ләкин ни сәбәпледер, гаиләне тулыландырып, милләтебез дәвамчысы булып туган энекәшем хәзер татарча сөйләшкәндә авыз эченнән ботка пешерә, ничек кирәк алай ике сүзне русча, бер сүзне вата-җимерә татарча әйтеп җавап кайтара. Кемдер тизрәк җәмгыятьне, балалар бакчасын гаепләргә ашыгыр, ләкин иң җитди сәбәп күз алдыбызда: бу – абыем һәм туган апам. Минем аларның балага “улым” дип эндәшүдән тыш, татарча сөйләшкәннәрен ишеткәнем дә юк, ахры. Минем белән калырга туры килгәндә энем белән татарча сөйләшергә омтылам, ә ул күзләрен мөлдерәтеп карый да, үзенекен сөйләвен дәвам итә. Шулай да, татар телендә мультфильмнар караганда аңлатуымны үтенә, хәйран сүзләрне татарча кабатлап йөри. Хәтта аралашканда да үз телебездәге сүзләрне кушып җибәрә, кызыксына. Ләкин даими аралашу булмаганлыктан, үз телебез һаман онытыла бара. Балаың беләсе килә, исендә калдыра. Димәк, рус телендә тәрбия бирүче балалар бакчасын түгел, ә чит телдә аралашкан һәм шундый бакчага биргән әти-әнине гаепләү дөресрәк булыр, минемчә.

Тормышыбыздан тагын бер мисал карап китик. Безнең икенче бер туганыбыз рус телендә белем бирүче Казан мәктәпләренең берсендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли һәм еш кына туган тел дәресләрендә булган очракларны сөйләргә ярата. “Балаларның төрлесе бар. Сәид, Мәрьям, Таисия, Ясминә, Кәрим, Амалия... Татарлар арасында чын үзебезчә матур исемнәр дә еш очрый хәзер. Ләкин барысының да исеме җисеменә туры килми, әлбәттә. Беренче сыйныфларда әти-әни, әби-бабай сүзләреннән башка татарча берни белмәгәннәре дә бар. Ләкин саф татарча матур итеп аралаша алганнары да очрый. “Татар теле – минем туган телем, шуңа күрә мин татар телен бик яратам” дип горурланган балаларны ишеткәндә күңелгә шундый рәхәт. Рус милләтеннән булып та, татарча тулы җөмләләр белән җавап кайтарырга сәләтле укучылар да юк түгел. Аларның җаваплары хәйран калдыра: “Мин Татарстанда яшим. Шуңа татар телен өйрәнергә тиеш”. Әгәр дә гаиләдә әлеге темага сөйләшү булмаса, бала мондый сүзләр сөйләмәс иде, мөгаен. Ике укучының да сүзләре йөрәкләрне җилкендереп җибәрә”. Менә тәрбия нинди булырга тиеш! Үз телебезне онытырга безнең хакыбыз юк!

Безнең телебез – гүзәл әсәрләр иҗат ителгән, бөек фикерләр әйтелгән борынгы тел. Ул күп еллар дәвамында үзгәргән, камилләшкән, күп галимнәр тарафыннан өйрәнелеп, системага салынган, үз кагыйдәләре булган камил тел. Югарыда әйтелгәннәр моны йөз кат, мең кат дәлилли. Шуңа күрә безнең – татарларның үз телебез белән горурланырга тулы хакыбыз бар. Без күкрәк киереп татар телендә аралаша, иҗат, халыкка хезмәт итә алабыз. Безнең телебез рус, инглиз, гарәп, төрек телләре кебек киң таралган телләр арасында зур хәрефләр белән язылырга лаеклы. Күренекле драматург, хикәяче, публицист һәм җәмәгать

эшлеклесе, олпат ил агасы, милләт язмышы өчен кайгырып, ил борчуы белән борчылып яшәгән һәм иҗат иткән олугъ зат Туфан Миңнуллин сүзләре татар милләтеннән булган һәр кешенең девизы булсын иде: “Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар буена чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән. Синең телеңдә катлаулы фәнни хезмәтләр дә, илаһи төшенчәләр дә, гүзәл әдәби әсәрләр дә язылган. Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!”

Татар теле – иң матур тел,иң нечкә, ягымлы, йомшак, татлы һәм туган тел! Яратыйк аны, пычратмыйк! Безнең буыннар да саф, чиста, бөек татар телендә горурланып сөйләшсеннәр иде! Әй син, телем, туган телем, тамыр телем. Җир астыннан тарих серен табар телем... Әй син, телем, рәхәт телем, авыр телем. Телне тешләп канатырлык сабыр телем... Синең белән рәхмәт укыйм, теләк телим. Җырга алып сине, милли көйләр көйлим. Табындагы икмәгем күк телем – телем. Табынам сиңа, синсез бер тәм тоймас телем... Әй син, айлы төнем, якты көнем. Әремнәрдән әче, балдан татлы телем. Сине саклап калыр өчен, күпме белем кирәклеген аңладым мин, белдем бүген...

## ДУСЛЫК – ЗУР БАЙЛЫК

*Прокопьев Артём, Алабуга шәһәре 8 нче урта мәктәбенең 9 нчы В сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Егорова Л.П.*

Дуслык – ул ике кешенең уртак кызыксынулары, бер-берсе белән ярдәмләшеп, авыр чакта терәк булып яшәүләре. Чын дус ул гадел, тыйнак, тырыш, ышанычлы, акыллы, ярдәмчел, юмарт була. Ул – теләсә нинди байлыктан, акчадан кыйммәтрәк, сатылмый торган бөек нәрсә.

Кем соң ул дус? Дус – ул синең партадашың, сыйныфташың, кечкенәдән бергә уйнап үскән күрше малае, я кызы. Ә инде чын дус дип аталучы берәү генә буладыр ул. Ул сине кирәк урында якларга, синең серләреңне саклый белергә, тиеш. Дуслык, барыннан да элек, авырлыклар аша ярдәм кирәк чакта, сынала. Янәшәңдә чын дусларың булганда, бернинди каршылыклар да куркытмый. "Дуслык таулар күчерә" ди халык. Бергә булганда, теләсә нинди авырлыкларны җиңеп чыгарга мөмкин. Кайгы-хәсрәтләр, борчу-мәшәкатьләр онытыла, кыенлыклар артта кала, тик янәшәңдә якын дустың гына булсын. Яхшы кешенең дуслары күп була. Һәрвакыт үзен генә кайгырткан, үзе турында гына уйлаган, тар күңелле кешене чын дус итү кыен.

Минем иң якын дустым − сыйныфташым Айрат. Без Айрат белән балалар бакчасына да бергә йөрдек. Мәктәптә бер сыйныфта укыйбыз. Мин аңа нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәмдә, ул мине кире какмый, һәрвакыт булыша. Мин моны күп тапкырлар сынадым инде. Җәйге каникулда булган бер хәл искә төште. Җәйнең бер эссе көнендә су коенырга барырга булдык. Без велосипедларга утырдык та Кама буена юл тоттык. Азрак барганнан соң, мин велосипедтан егылдым һәм теземне авырттырдым. Тезимнән кан ага башлады. Шунда Айрат белән нәрсә булды дисезме? Ул башта бик нык курыкты. Шунда ук миңа беренче ярдәм күрсәтә башлады. Шул вакытта үзенең күлмәгенең бер җиңен ертып алды да, минем яраны бәйләп куйды, аягыма бастырды. Бездән алдан киткәннәр су коенып кайтып киләләр иде. Шулчак, Айрат аларга минем велосипедны алып кайтырга кушты. Ә үзе мине велосипедының утыргычына утыртты да, табибка алып китте. Табиб яраны чистартты һәм яхшылап бәйләп куйды. Без өйгә кайтырга чыктык. Бераздан мин үземдә атлый ала башладым. Ләкин ул, аннан соң да юл буе миңа булышып кайтты. Өйгә кайтып җиткәч, мин аңа чын күңелемнән рәхмәт әйттем. Чын дус менә шундый була ул!

Дөрестәндә, дуслары булган кеше беркайчанда югалып калмый. Мин шундый дустым булуына шат. Айрат, язмыш синең белән таныштырганга мин бик рәхмәтлемен. Киләчәктә дә шулай дуслыгыбыз нык булсын.

## БАБАМ ЮЛЫ

*Рахимьянов Рамазан, Әлмәт шәһәре 17 нче урта мәктәбенең9 “А” сыйныфы укучысы*
*Җитәкче: Абдуллина Г.В.*

Фиткә урманнары буйлап
Авылга мин еш кайтам,
Монда туган, монда үскән
Бабай, әби һәм атам.
Ык буйларын якын итәм,
Елгасында су керәм.
Һәр агачны, һәр сукмакны
Юлдашым итеп күрәм.
Бабай йөргән бу юллардан
Кабат-кабат үтәм мин,
Аның кебек урманнарга
Җырлап барып керәм мин.
Сабантуйда батыр калган,
Авылны да ул тоткан.
Бабай атка менгән чакта
Тузаннар тузып торган.
Матур, якты хәтирәләр
Күңелгә килеп туа,
Уйлаган уй-теләкләр
Тормышка ашып тора.
Менә инде ничә буын
Үзе бер тарих икән.
Бабай йөргән бу юллардан
Узуы рәхәт икән!

## ТУКАЙ – ШАГЫЙРЬ

Тукай шигырьләрен укып,
Күңелгә илһам алам.
Хәтфә яшел болыннарда
Күбәләк булып очам.
Су анасы, Шүрәлегә
Карап хәйранга калам.
Тукай күңеле – шагыйрәнә
Кайдан шулай көч алган?!
“Су анасын” укыганда
Су буеннан кайталмыйм.
Су анасын тотып алып,
Аның чәчләрен тарыйм.
“Шүрәле”не укыганда
Карурманда адашам.
Урмандагы бар җәнлеккә
Исememне алдашам.
“Былтыр” атын туарганда
Атланып чабып алам,
Аның белән бил алышып,
Юктан көлкегә калам.

Тукай шигырьләрен укып,
Көч алам, сөю алам.
Җиңелмәс олы хисләрең
Шаһиты булып калам!

## СОЛДАТ КАБЕРЕ

*Ризванов Данил, «Әлмәт һөнәри көллияте»нең IV курс студенты*
*Җитәкче: Рафигуллина М.М.*

Чит бер җирдә татар егете кабере
Чит кешеләр куя чәчәкләр.
Таң җилләре сыйпый кабер ташын,
Әйтерсең лә назлап дәшәләр.

Чит җирләрдә ятып калган егет,
Азат иткән илне дошманнан.
Ялгыз каен үсә янәшәдә,
Күптән инде ул да картайган.

Хуҗа булмасын илгә дошман,
Утка-суга кергән балалар,
Батырларча һәлак булды дигән
Язу алган күпме аналар.

Туганнары көткән, сөйгәннәре
Үлгән дигән хәбәр килсә дә.
Кайтыр дигән өмет яшәп килгән,
Күпме гомер үтеп китсә дә.

Дистә еллар үткән улын көтеп,
Гүр иясе инде карт ана.
Сугышчының батырлыгы өчен
Мәңге сүнмәс якты ут яна.

Чит бер җирдә татар егете кабере
Чит кешеләр куя чәчәкләр.
Таң җилләре сыйпый кабер ташын,
Әйтерсең лә назлап дәшәләр.

## БӘХЕТ

*Садыйкова Сөмбелә, Мамадыш районы Түбән Сон урта гомуми*
*белем мәктәбенең 11нче сыйныф укучысы.*
*Җитәкчесе: Мөбарәкшина И.С.*

Бөтен кеше хыялында
Бәхетле,тыныч тормыш.
Һәрвакытта тик яктыга
Син омтылырга тырыш.
Яратып һәм яратылып
Кемнең яшисе килми?
Чын бәхеткә ирешү дә

Җиңел генә бирелми.
Һәр яктан да яхшы булсаң,
Барсына ирешерсең.
Кеше булып кала белсәң,
Бер кайгысыз яшәрсең.
Тормыш юлы катлаулы бит
Сикәлтәле, бормалы.
Ярдәм кулын суза торган
Яныңда кешең бармы?
Якын дуслар янда булса,
Берни куркыныч түгел.
Тормыш сынауларын да
Бергә үтүе җиңел.
Әгәр килеп сыенырлык
Кешең булса яныңда,
Берәүгә дә аны сатмый
Хәзинәң итеп сакла.
Күңелләрдә әле һаман язлар
Көзгә кадәр аңа иртәрәк.
Мәхәббәтсез җирдә яшәп булмый –
әр кешегә бу хис бик кирәк.
Күңел серләреңне чишәр өчен
Янәшәңдә сөйгән ярың бар.
Тик син диеп ул бит янып тора
Шуңа аңа һәрчак тугры кал.
Тирәңдәге шушы кешеләрне
Алыштырма башка берәүгә.
Бары алар йөрәгенең генә
Син торасың иң-иң түрендә.
Бәхетсезләр бәхетләрен әле
Барыбер бер әзләп табарлар.
Бәхетлеләр шикелле үк алар
Сөю хисе белән янарлар.

## АНА БӘХЕТЕ
**(хикәя)**

*Саматова Чулпан, Бөгелмә шәһәре 11 нче урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Килдиярова З.А.*

Булат бүген иртән үк торып, бәйрәмчә киенде. Ул каядыр ашыга, йөрәге үз урынында түгел.

-Улым, син кая җыенасың? – дип, сүз кушты әнисе.

-Мин бүген Рөстәм белән спорт мәктәбенә барам.

Ананың йөрәге сулкылдап куйды. Күзләрендә шатлык яшьләре. Күз алдыннан бер-бер артлы булып узган вакыйгалар үтте.

Гөлфизә үзен дөньяда иң бәхетле кеше итеп тойды. Дөньяга авазын салып, аның баласы туды. Ләкин бу шатлык-куанычлар озакка бармады, аның нарасые гарип иде. Әбиләрнең өшкерү-төкерүләре дә, төрле больницаларда ятулар да аңа ярдәм итмәде. Бу Гөлфизә өчен өмет-хыялларның челпәрәмә килеп җимерелүе иде.

Ана мәхәббәте, назы, аның күңел җылысы бу тормышның иң көчле терәге бит. Гөлфизә дә улы Булатны аякка бастыруга бар көчен бирде: һәр көнне төрле күнегүләр эшләү, массаж ясау. Тешләрен кысып, яшәү өчен көрәшүче кечкенә Булатка да шаккатарлык. Ни могҗиза: ана мәхәббәте уңышсызлыкларны, килеп туган өметсезлекне җиңәргә ярдәм итте. Тырышлык бушка китмәде, Булат ышанычлы адымнар ясый башлады. Инде ул үзлегеннән күнегүләр ясый, яшәү өчен тырыша.

Гөлфизә уйларыннан арынып,улына карады.

- Бар, улым, бар.

Булат белән Рөстәм спорт мәктәбенә юл алдылар.

Әйе, ул бүген иң бәхетле ана. Ни дисәң дә, ышанычлы адымнар белән олы тормыш юлына атлап китеп баручы баланың күзләрендә өмет чаткылары. Ана өчен моннан да зур бәхет, шатлык була аламыни?!

## КАЙТЫП КИЛЕШЕМ

*Сафетдинов Илназ, Актаныш районы  Аккүз төп гомуми*
*белем бирү мәктәбенең  9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Әхмәтова З.Н.*

Еллар узгач, сагынып кайттым әле
Авылыма – туган нигезгә.
Каршылады мине анда шул ук
Балачагым охшап диңгезгә.

Диңгез суы тирән булган кебек
Хәтерләргә бик күп уелган.
Еракларда калган мизгелләргә
Әйтерсең лә һәйкәл куелган.

Ерактан ук мине каршы алды
Кулын изәп, таныш зур урман.
Кайсы гына якка күз салсам да,
Аңа карап мәңге мин туймам.

Шатлык, сагыш, тирән борчылулар
Һәрбер почмагына сыенган.
Анда үскән һәрбер каен кызы
Бик килешле ак шәл ябынган.

Җәйләр җиткәч, бөтен авыл халкы
Бара иде иркен аланга.
Ярышып, чиләкләрне тутырып,
Җиләк, шомырт, гөмбә җыярга.

Бар иде бит шундый рәхәт чаклар
Калды инде сагынып сөйләргә.
Үткәннәрне ешрак искә алып,
Яшьлек сукмакларын эзләргә.

Кайтам әле, кайтам туган якка
Саный-саный йөрәк тибешен.

Чорлар аша ерак үткәннәргә -
Балачакка кайтып килешем.

## МӘХӘББӘТ ЯРЫ
**(нәсер)**

*Сафина Венера, Бөгелмә шәһәре 2 нче лицееның 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Ногманова Д.Р.*

Язмыш безне мәхәббәт ярында очраштырды. Икебез ике ярда. Яр бик биек, ә аста талгын гына елга агып ята. Без бер-беребезгә караш ташладык та басып катып калдык. Телләр түгел, җаннар сөйләшә иде ул чакта. Алар бер-берсенә шулкадәр тартылдылар, хәтта тыеп туктатыр көч юк.

Шундый бер иртәдә син мине үз ярыңа әйдәдең. Авыр тормыш сукмакларын синең ярыңнан бергә-бергә җиңел генә үтәргә чакырдың. Шатлыгыбыз дөньяга сыймый иде. Безнең мәхәббәтебез шундый көчле, хәтта бөтен галәмне чолгап алган кебек тоелды. Шушы мәхәббәттән исереп, бар дөньябызны онытып, бер-беребезнең кочагына ташланырга омтылдык. Мин бер аягым белән синең ярыңа бастым. Икенче аягым белән дә атлыйсы иде дә бит! Юк шул!.. Мин түбәнгә тәгәрәдем... Талгын гына аккан елганың суында бер батам, бер калкам. Синең миңа кулыңны сузуыңны өметле күзләрем белән көтәм. Син үзең дә ни эшләргә белми катып калдың бит ул чакта...

Мәхәббәт! Бар ул мәхәббәт һәм ул көчле! Кирәк булса, бөтен дөньяңны айкап чыгар. Бары тик югалтмаска кирәк аны!

Җаным, матурым! Ычкындырмыйк кулыбыздан мәхәббәтебезне. Тап төшермик без аңа. Суз миңа кулларыңны. Тартып чыгар мине ярыңа! Елга суларында агып китмәсен бәхетебез! Искән җилләр сүндермәсен мәхәббәтебез ялкынын!

## ХЫЯЛ ДИҢГЕЗЕ

*Сәетгәрәева Резеда, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Миңнуллина Р.Ф.*

Яңгыр... Көзге салкын иртә,
Бар табигать түгә күз яшен...
Нәни кызчык хыял диңгезендә
Кысып-кысып коча әнкәсен.

Нәни кызчык инде ничә еллар
Тәрәзәдән алмый күзләрен.
Тик бер тапкыр тели ул әйтергә
“ӘТКӘЙ” белән ”ӘНКӘЙ” сүзләрен.

Нәни кызчык һаман тәрәзәдә,
Һаман көтә газиз әнкәсен.
Нәни кызчык бер дә тоймый үсә
Пар канатның көчле җилкәсен.

Көн дә көтә, күзен алмый көтә,
Күңелдә төрле уйлар:
Нигә монда? Кайда газиз әнкәм?
“Балам” диеп, баштан кем сыйпар?

Кем уятыр аны иртәләрен,
Тәмле ашлар кем соң ашатыр?
“Исән йөрче берүк, балам” – диеп,
Иртәләрен кем соң озатыр?..

Яңгыр шуңа бүген җавап эзли,
Бар табигать түгә күз яшен.
Нәни кызчык хыял диңгезендә
Кысып-кысып коча әнкәсен...
Шәм яктысы, иске сурәт
Күпме уйлар, күпме хатирә,
Тәүге адым,тәүге сүзләр –
Барчасы да, барсы хәтердә.
Менә сурәт, анда нәни кызчык
Әнкәсенең назлы куйнында,
Тагын сурәт, ә бусында әнкәй
Серле йомгак аның кулында.
Оекбашлар бәйли әнкәй,
Биш энәсен алып кулына,
Кыш җитүгә әзер булып торсын
Кызыма, ди, монысы – улыма.
Тагын сурәт, тагын шул ук кызчык,
Тик сабыйлык качкан күзләрдән
Әнкәй назын эзләп тилерә ул
Сурәттәге таныш йөзләрдән.
Серле йомгак ерак тәгәрәде,
Бер башламы бәхет күгендә
Күңел җылың сеңгән оекбашлар
Саклый әле, саклый бүген дә!
Кызчык әле һаман тәрәзәдә,
Һаман көтә газиз әнкәсен.
Мескен кызчык бер дә тоймый үсә
Пар канатның көчле җилкәсен…

## КАЙТУ

(хикәя)

*Сәитов Вилдан, Норлат шәһәре Чулпан урта гомуми белем мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Сәмигуллина Ф.Х*

Ничек кенә кыен булмасын, барыбер кайтырга кирәк ...

Атна ахырындагы яллар җитсә, каникуллар җитсә, нишләп ятасың бу шәһәр дигән җирдә – күңел авылга тартыла. Авыл һавасы бөтенләй икенче төрле шул, кәкре тыкрыклары, бормалы урамнары, авыл башындагы буасы, һәр йорт капкасыннан җиргә кадәр сыгылып төшкән тал, имән, юкә агачлары – барысы да үзгәлеге белән кечкенәдән җанына якын иде егетнең, кешеләре дә икенче төрле – авылча ... гади ... гадел... аңлап һәм аңлатып булмый торган дәрәҗәдә рәхәт иде авылда...

Малай-шалай белән уйнауга караганда һәм үзенең бабасы була торып та, күрше карты Сәет бабай белән көн үткәрү кызыграк иде Азаматка. Дөресрәге, бу кызыклыктан бигрәк, аның күңелендә үзе генә белә торган Сәет бабайдан көнләшү, аңа кызыгу хисе өстенлек итә иде. Азамат буш вакыты булдымы, йөгереп күршеләргә керә иде дә, келәт янында үсеп утырган карт имән төбенә чүмәшә иде. Сәет бабай аның бу гадәтенә күптән күнеккән, “ни хәл ?” дип бер-берсенә дәшеп, кул бирешеп күрешәләр дә, Азамат имән төбенә терәлә, ә Сәет бабай ишегалдында бетмәс-төкәнмәс эшләре белән мәшгуль була иде. Бу вакытта кечкенә генә йөрәге ничек типкәнен, ничек янганын Азамат үзе генә белә иде. Азамат күзен алмый

Сәет бабайның һәр атлаган адымын күзәтә иде; йөрешенә, атлавына, кирәк икән сәндрәгә баскыч буйлап җәһәт кенә менеп китүенә, җитез генә аннан төшүенә, сәнәк-сәнәк печән ташып, мал-туар каравына, кош-кортларга җим сибүенә, коедан су ташуына, бакчада җир казуына, шул рәвешле хатыны Сәкинә апага зур ярдәм итүенә соклана да иде, кызыга да иде малай. Хуҗалыгындагы тавык та чүпләп бетерә алмаслык эшне Сәет бабайның ничек эшләвен − һәммәсен игътибар белән, йотлыгып, күзен алмый күзәтә иде... ә нәкъ шул эшләрне Закир бабасы ихатасында Галия әбисе берүзе эшли иде...

Эх, ник соң Азаматның бабасы да шулай ишек алларына чыгып, хуҗалык тирәсендә көштер-мөштер килеп йөри алмый икән, ник соң аның бабасы да күрше Сәет бабай кебек чыклы таңнарда чыбыркы шартлатып көтү куа алмый, ник соң кызу җәйләрдә болынлыкка төшеп кибән куя алмый, ә кичләрен Азаматын ияртеп, балыкка бара һәм башка бик күп әйберләрне эшли алмый икән?! Закир бабасы Сәет бабай кебек булса, Галия әбигә дә тормыш җиңелрәк тоелыр иде. Авыр иде шул Галия әбисенә, ай, авыр иде. Эх... чыбыркы шартлатырга да Сәет бабайдан түгел, Закир бабасыннан өйрәнәсе килгән иде шул Азаматның. “Ничекләр ярдәм итәргә соң, нишләргә соң?”, дигән уйлар Азаматны гел борчып тордылар...

Әле мәктәпкә кергән чагы гына иде. Көттереп кенә килеп җиткән җәйге ялларның берсендә көне буе малайлар белән уйнап, арып кереп башын гына төрткән иде Азамат, йоклады да китте... Менә алар Закир бабасы белән икәүләшеп атта чабалар, болыннарны, урманнарны урыйлар, елгаларның саерак җирләреннән чаптырып чыгалар да, кире кереп, сикереп төшеп, атларын юалар, атлары су эчкән арада үзләре дә ярыша-ярыша агымга каршы колачлап йөзәләр, аннан тагы сикереп кенә атка менәләр дә иген кырларыннан, күл буйларыннан чаптыралар. Шулай авылны әйләндереп алган басу-кырларны, урман, елга-күлләрне барлап чыкканнан соң, Галия әбисе пешереп көтеп торган коймак белән чәй эчеп хушлангач, ишегалдына чыгып, барлык эшләрне күз ачып йомганчы эшләп керәләр иде. Әй рәхәт иде соң әби-белән бабай янында − аны аңлатып та бетерә торган түгел шул! Малайның татлы йокысы әбисенең, “Улым, Азамат, тор инде, көн кичкә авышты, бу вакытта йокларга ярамый, тор, улым, чәй кайнаган, хәзер бакча капкасын гына ябып керәм” дигән тавышына өзелде. Азамат, әбисе артыннан ишек ябылып калган тавыш ишетеп, сикереп торды да, Закир бабасының бүлмәсенең ишек чаршавын әз генә аерып, бер күзе белән генә карады: бабасы, гадәттәгечә, ап-ак җәймә җәелгән урынында ята иде, күзләре ак кәгазьгә төбәлгән, кулындагы каләме шул кәгазь буйлап я әкрен генә атлый, я бик кызулап йөгерә иде. Закир бабай Азаматның мондый гадәтен белә, караганын сизә, “кер, улым, кер, утыр яныма” дип дәшә иде дә, бүген ниләр язганын укый башлый иде. Шулай итеп, Азамат сугыш турында Закир бабасыннан кечкенәдән ишетеп үсте, сугышның нинди кайгы икәнлеген, сугыш китергән зыян һәм югалтуларны шулай сабый чактан күзаллый алды. Бабасы язганнарны кино караган кебек күзалдына китереп барды: сугыш кыры, дошманның чигенеше вакытында чираттагы бомба шартлавы, Закир бабасының яралы иптәшен коткарганда үзенең ике аяксыз калып контузияләнү вакыйгасы килеп басты. Безнекеләрнең бабасын да, аның иптәшен дә коткару, дошманның безнең илдән куып чыгарылып, безнекеләрнең Берлинга кадәр килеп җитү, җиңү байрагын рейхстагка элү күренешләрендә үзе катнашкан кебек тоелды Азаматка. Менә шулай көнсаен бабай белән онык аралашалар иде, берсе сөйли – икенчесе тыңлый, икенчесе сорау бирә – беренчесе җавап кайтара ... кечкенә малайның бабасына булган горурлык хисе белән беррәттән аның башкалар кебек авыл урамнарында йөри алмаганлыгына борчылу хисе әйтеп бетергесез дәрәҗәдә тигез иде.

Кайвакыт Азамат бабасы сөйләгәнне тыңламыйча үз уйларына бирелеп китә иде, бу уйлар бары тик бер нәрсә турында гына − ничек итеп бабасын аякка бастырырга!

Азаматның сирәк кенә булса да, Галия әбисенең сандык актарганын күргәне бар. Аллы-гөлле төсләр белән чигүле япма җәелгән бу сандык күп сер сыйдырган кебек иде Азаматка. Нәрсә карый соң анда әбисе? Нинди төргәкне кадерләп кенә ачып, сыйпап кына

карап, кадерләп кенә кире төреп куя иде соң ул? Нәрсә салынган соң шул төргәккә? Озак үтмәде, бер уңайлы вакытта Азамат сондыктан төргәкне алып чишеп карады. “Галия-Закир” дип чигелгән кулъяулык белән алтын төсендәге медальне күргәч, җиңел сулап елмаеп куйды ул, төргәкне кире үз кыяфәтенә туры китерергә тырышып, төрде дә, урынына куйды, һәм кулъяулык белән медален кесәсенә салып, бабасы уянганчы, әбисе ишегалдыннан кергәнче дип, сондык торган бүлмәдән чыгып сызды. Ул көнне Азамат күршеләргә дә кермәде, уйнарга да чыкмады, төн йокламады − уйланды һәм карарга килде.

Авылга еш кына ит, сөт җыючылар, киез итек, бияләй, шикәр сатып йөрүчеләр килә иде. Галия әбисенең дә алардан киез итекне майга я күкәйгә алыштырып алганы булганга, бу кешеләр Азаматка әзме-күпме таныш һәм якын тоелалар иде. Сугыштан соңгы ачлы-туклы яшәлгән чорларда мондый кешеләрнең килгәнлекләре авылга тиз тарала иде. Кайсы йортта хәллеләр барлыгын алар да белеп бетергән иде инде, шул сәбәпле хәерче тормышлы өйләргә тукталмыйча узып кына китәләр иде. Менә шулай бер тапкыр Закир бабайлар йортын да узып баручы кешеләр артыннан йөгерде Азамат, кесәсендәге кулъяулыкка төрелгән медален чытырдатып тотып. Куып тотты да “абый, мәгез сезгә медаль, ә миңа акча бирегез, минем бабаемның аякларын ясатырга кирәк, − диде калтыранып. Арба тәгәрмәчләре шыгырдап куйды. Атын туктатып, әле эшнең нидәлеген бик аңлап бетермәгән олырак яшьтәге ир кеше “нәрсә?” дип сорау бирде. Азамат тагын кабатлады: “мәгез сезгә медаль, ә миңа акча бирегез, минем бабаемның аякларын ясатырга кирәк, − диде. Үзе каршында басып торган яланаяклы, арык гәүдәле сабый баланың чып-чын медаль сузган кечкенә кулларына карап, ир югалып калды, ни әйтергә белмәде, аяк астыннан җир убылгандай тоелды аңа. Малайны атына утыртты да кире борылып, Закирлар капкасы янына килеп туктады. Азаматны күтәреп алып җиргә бастырды, җитәкләп, ишегеалдына кереп китте.

Хәтерли Азамат бу мизгелләрне, бик хәтерли.

Галия әбисе тыныч кына чит-ят ир белән килеп кергән пошамандагы Азаматны күргәч, берәр зыян эшләгәндер инде дип уйлап, аларны туп-туры Закир бабасы янына алып кереп китте. Хәзер ни булыр инде дип куркуга калган Азаматка югары тавыш белән эндәшүче, хәтта, куркыныч күз карашы ташлаучы да булмады. Ят ир медальне Закир бабайга сузганда Азаматның күзләре мөлдерәмә тулып, бабасына карыйлар иде. Азамат шикләнү, курку катыш пышылдау белән “мин синең белән җиңү көнне мәктәп бакчасындагы һәйкәл янына барасым килгән иде, мин сиңа аяклар ясатырга теләгән идем” − диде. Мондый җавапны ишетеп, бүлмәдәгеләр ни әйтергә белмәделәр, чөнки әле беренче сыйныфны гына тәмамлаган, ә инде уйлары белән әлләниләр майтарырга тырышып йөргән сабыйны әрләү урынсыз иде. “Улым, ниятең зурдан булган, рәхмәт, ләкин нинди генә афәттә дә, медальгә тияргә, аны сатарга, бирергә, хәтта югалтырга да ярамый! Ул медальгә халкыбыз батырлыгы, безнең тыныч тормыш өчен көрәш рухы салынган, − дип оныгының башыннан сыйпады Закир бабай...

Көннәр, айлар, еллар узды... Менә егет булып буйга җиткәч, ул вакыттагы ялгыш адымын тагы да төбенә төшеп аңлый башлагач, бабасы алдындагы гаебе өчен, улап куйса гына да, йөзе кызара, күңеле тыпырчына, йөрәге бәргәләнә иде. Балачак акылсызлыгы аркасында, әбисе белән бабасы янына кайтып кергән саен, кыенсыну хисе барлыкка килә иде Азаматта, ләкин кайтырга кирәк − аны анда һәрвакыт сагынып көтәләр.

Гадәттәгедән, ашкынып, ашыгып кайттып төште Азамат авылга. Өй янындагы эскәмиядә яңа протезларын киеп чыгып утырган Закир бабасы каршы алырга тиеш иде шул аны бу юлы.

Урамда рәхәт, күңелләр шат, ак шомырт чәчкәләре хуш исенә уралып, җиргә янәдән җиңү язы килде!

## УМЫРЗАЯНЫҢ ДУСЛАРЫ

(әкият)

*Сәйфетдинова Ләйсән, Норлат районы Якушка урта мәктәбенең 11нче сыйныф укучысы*

*Җитәкче:Хәмидуллина Г.И*

Табигатьнең уяна торган чагы җитте кызым, - дип башлады бабам сүзен. Менә шул вакыт гел әбием сөйләгән әкият искә төшә. Кызым, шуны сиңа да бәян итәсем килә. Карлар эреп, сулар йөгергәч бик матур итеп умырзаялар калка, бәбкә үләне шытып, борын тертә. Елга буенда бер умырзая үзе генә яши, ди икән. Аның дусты Көмешкәй яз җиткәч, бозлар агып киткәч, кояшның якты турында уйнаклап, умырзая дусты белән серләшә, ди икән. Ә быел нигәдер ул уйнакламый. Умырзая бик борчыла, кибә, сула башлый. Дустының кая киткәнлеген белер өчен ул сыерчык дустын чакыра. Сыерчык дусты үзенең дусларын да чакырып елганың иңен буен айкап чыгалар. Шулай итеп алар умырзаяга бик авыр хәбәр китерәләр. Янәшәдә генә эшләп килүче завод үзенең пычрагын, агуын шул суга ташлаган икән, шунлыктан биредәге балыклар бик күбесе үлгән, ә күбесе хәлсезләнеп, үлем белән тормыш арасында, ди икән. Шул хәлсезләр арасында Умырзаяның сөйгән дусты Көмешкәй дә бар икән. Умырзая бу хәбәрне ишетеп нишләргә белми, тагын да зур кайгыга баткан, ди. Сыерчык дусты ярдәмгә килгән. Каф тавы артында тере сулы чишмә ага икән. Менә шул суны елгагага бер тамчы гына тамызсаң да агу юкка чыга,ди икән. Әле минем дустым Кыр казы кайтмаган. Шул дустыма җилләр аша хәбәр җибәрик, алып кайтсын шул суны, дигән Сыерчыккай. Алар шулай эшләгән дә. Кыр казы юлга чыгарга бары санаулы гына сәгать калган булган, ди икән. Сөенечкә каршы,Җилкәй вакытында өлгергән.Кыр казы тере суны алып кайтып елгага тамызган, ди. Анда булган һәр җан иясенә хәл кергән, ди. Умырзая да дусты, Көмешкәйнең терелүенә бик шатланган. Алар һәр яз әле дә шулай дус, тату, бер-берсен яратып гомер кичерәләр, ди икән. Ә иң әйбәте Җилкәйнең якын дусты Кеше икән.Ул барында аңа сөйләп биргән. Кеше үзенең хәленнән килгәнчә, бик күп завод-фабрикаларга фильтр куйдырган, су буйларына чүп-чарны түкмәсеннәр дип җил дускаена да эш кушкан, ди. Шул рәвешле бу тирәдәге табигать искиткеч матур, чиста икән. Җилкәй һәр начарлык эшләргә җыенучының колагына пышылдап бу әкиятне сөйли, ди икән.

Бабамның бу әкияте мине дә битараф калдырмады. Без дә, дуслар белән Җилкәйнең әкиятен бөтен җир шарына җиткерәсебез килә. Табигатьне саклагыз! Урманнарны, суларны пычратмагыз! Кошларны, җәнлекләрне үтермәгез! Шул чак җир шарында БӘХЕТ, ШАТЛЫК, УҢЫШ, МӘХӘББӘТ янәшә яшәр!!!

## ЯЛГЫЗ МАЯК

*Сәлимҗанова Лилия, КФУ ның Алабуга, институты студенты*

*Җитәкче: Миңнуллина Р.Ф.*

Тамырыннан корытып, куптарып,
Бугазыннан кысып йөрәкне,
Күмер итеп барча хисләремне,
Өтеп алдың минем үзәкне.
Язгы ташу белән бергә китте
Күзләремнән яшьләр диңгезе.
Таштан түгел, тик томаннан булган
Безнең әкиятнең нигезе.
Кояшта да кара таплар бар ди,
Дүрт аяклы ат та абына.
Диңгез уртасында ялгыз маяк
Бер сүнә дә, тагын кабына...

***

Язлар җиткәч, яп-яшь каеннарның
Кәүсәләрен уеп тишәләр.
Шифа бирә бит ул дия-дия,
Каен суын тәмләп эчәләр.
Яраланган агач күңеленнән
Ага төсле ачы күз яше.
Бер мизгеллек бәхет өчен генә
Кимсетелгән гомер тәлгәше.

## МИН БАШКАНЫ ЯРАТАЛМАМ

Төнге уем үткәнемә илтә,
Сәлам әйтә сиңа тулган ай.
Күңелемдә җил-давыллар бии,
Сөюемнән мин исердем, бугай.
Татлы хыял булып һаман да син
Нур сибәсең кебек еректан.
Кулларымны сузам, тик җиталмыйм.
Хатам җиле исә каршы яктан.
Аккан сулар, искән вакыт җиле,
Безнең сөю инде җуелган.
Якты мәхәббәтнең өстенә дә
Чардуганы инде куелган.
Син бит үзең салкын акыл белән
Тере килеш сөюем җирләдең.
Шулчагында бәхетем өстенә
Таш утыртканыңны сизмәдең.
Сүнде кебек кояш, җилләр тынды.
Кипте кебек хәтта елгалар.
Миннән башка бар җиһан яратыр:
Яратыр ул, яратырлар алар.
Тик мин инде башка ярата лмам!..

## СИҢА

Бөтерелеп, өермәдәй кубып,
Оча-оча бии күрәсең.
Сары күбәләктәй яфрак кебек
Битләреңнән килә үбәсем.
Ак кар булып иңнәреңнән кочып
Иркәлисем килә, назлыйсым.
Адаштыңмы әллә сөюемдә?
Тормышымнан китә алмыйсың.
Һәр яз саен якты кояш булып
Нур сибәсем килә синең өчен.
Җылы яңгыр булып явармын мин
Уңдырмаска сөюнең төсен.
Таңда төшкән чык тамчысы булып
Уятырга телим яратып.
Кошлар кебек сайрар идем лә мин
Моңлы күңелеңне юатып.
Соңгы сулышымны бирер идем

Таралсын өчен бу куе томан.
Язсын иде Ходай безгә дә
Тугры булырга аккошлар сыман.

## САБЫРЛЫК

Биклисе иде хисләрне
Җиде кат йозак белән.
Түшисе иде барсының
Юлларына ак келәм.
Елыйсы килгән чакта да
Елмаясы иде ул.
Горур атларга иде лә
Бик авыр булса да юл.
Дуслар хыянәт итсә дә,
Тугъры каласы иде.
Барыбыз да хаталы шул,
Ходай баласы инде.
Сөйгәнең кире какса да,
Яратырга кирәктер.
Сабыр итеп яшәргә
Язмыш бары өйрәтер.

## СИНЕ КҮРГӘЧ...

Йокысызлык алды мине бүген,
Уйлар ярды карлы төнемне.
Айлар үткәч сине күрдем тагын
Төшемме бу, әллә өнемме?
Үзең якын идең, үзең ерак,
Багалмадым сөйгән күзләргә.
Кисешмәде тагын безнең юллар,
Калды әйтеләсе сүзләр дә...
Горурлыкмы, сөймисеңме бүтән?
Инде бәлки башкадыр ярың?..
Эндәшергә теләмәдең нигә?
Күп сораулар туды миндә тагын...
Йокысызлык алды мине бүген:
Фикерләрем китеп таралган,
Сөю йомгагыбыз чуалган да,
Ак карларга кереп югалган...

## ҮЗӘКЛӘР ӨЗЕЛГӘНДӘ

Кичерә алсаң, кичер сөюемне,
Сине уйлап янып көюемне,
Кар сарган туң тәрәзәгә карап,
Әле һаман сине көтүемне.
Гафу итче хата-ялгышымны,
Йөрәкләргә салган сагышымны.
Инде үтмәс, бетмәс бу газаплар...
Тормышларның шулай агышымы?
Оныта алсаң, оныт үткәнне,
Минем һәрчак сине көткәнне,

Иң бәхетле көннәребезне дә,
Сагыну бәгырьләрне өткәнне...
Ярталсаң ярат син бүтәнне.
Кабул итми йөрәгем читләрне.
Өметләрсез бит инде сөюем.
Аңлый алмыйм һаман ни көткәнне.

## ТАТАР БУЛГАН ТАТАР БАЛАСЫНА

Горур татар диләр, мәгърур татар
Тугъры милләт – татар милләте.
Татар булган “татар балаларың”
Халкым, сине нәрсә эшләтте?

Иелгәнне кылыч кисмәс диеп,
Түбән төшердеңме башыңны?
Ауропага карап чишенәсең,
Оныттыңмы мәккә ташыңны?

Айгөлләрең Кирилларга хатын
Синең үлем шушы түгелме?
Кайда синең Сөембикәләрең
Нигә алар шулай чигенде?

Милләт җаны, динең нуры булган
Түбәтәең киде урыслар.
Күрше - күрше белән аралашмый,
Татарлар да хәзер кырыслар.

Нишләдең син, татар? Кая идешь?
Халкым минем түгел сатлыкҗан.
Бай ла инде словарьный запас,
Чит-ят кәлимәгә юк нужаң.

Татар диләр, бөек татар улы...
Кайда синең горур җаннарың?
Сүз дәшәргә курыкмыйча гына
Атар микән синең таңнарың?

Мин милләтче түгел, тик халкымны
Соңгы сулышкача якларммын!
Күңелендә җегәрләнгән аты
Кузгалырмы берәр татарның?

## КАР БӨРТЕГЕ ТУРЫНДА ӘКИЯТ

*Сәфиуллина Луиза, Әлмәт шәһәре 13нче урта мәктәбенең 9нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гарипова А.Ш.*

Элекеге заманнарда булган, ди, бер Кыш апа.

Яңа ел алдыннан аның кызы туган. Ул бик шатланган, ләкин шатлыгы озакка бармаган: ул кызына нинди исем кушарга белмәгән.

Кыш апа ярдәм сорап Кыш бабайга барган. Ләкин Кыш бабай:

- Мин сиңа ярдәм итә алмыйм. Минем вакытым юк, Яңа елга әзерләнергә кирәк! – дип әйткән.

Кыш апа, моңсуланып, өенә кайтып киткән. Өйдә аны кызы көткән. Әнисе кайтып керү белән, йөгереп килеп кочаклаган да:

- Әни, мин дусларыма кунакка бардым. Алар бик яхшы, һәркемгә булышалар. Мине биергә өйрәттеләр. Менә, кара әле мин ничек бии беләм, - дигән ул, һәм бии башлаган.

- Кызым, син бигрәк матур биисең,- дип мактаган кызын Кыш апа.

- Әни, нигә син шундый моңсу?

- Минем эшем бик күп, кызым, - дип җавап биргән әнисе, - ә син бар, уйнарга чык! – дигән.

Кызы бер сүз дә әйтмичә дуслары белән уйнарга киткән.

Шул вакытта аларның өйләре кырыннан Кар үтеп бара икән. Кар кайгылы Кыш апаны күргән дә сораган:

- Ни булды? Нинди уй-хәсрәткә баттың?

- Кар абый, минем кызым туды, ишеткәнсеңдер инде. Мин аңарга исем уйлап таба алмыйм.

-Мин аңа нинди исем кушарга икәнен беләм. Кара әле, ничек бии ул - чын Кар бөртеге!

Бу вакытта алар икесе дә борылып Кыш апаның кызына караганнар. Бик матур бии икән ул!

Шулай дип атаганнар да Кыш апаның кызын – Кар бөртеге. Шушы вакыйгалардан соң Кар бөртеге гел биеп йөргән, диләр.

Без аның матур биюен хәзер һәр кыш күрә алабыз.

## УЕННАН УЙМАК…

(әкият)

*Сибгатуллина Лилия, КФУның Алабуга институты*
*Җитәкче: Саттарова Г.Г.*

Ерак урманда яшәгән ди, булган ди бик шук куян малае. Исеме Наян булган аның. Көннәр буе туп тибеп, мәтәлчек атып, йөгереп, уйнап үткән ди моның көннәре. Әтисенең дә, әнисенең дә сүзен озын колагының берсенә дә элмәгән- ишетмәгән ди шук Наян. Нәрсә генә әйтсәләр дә, нинди генә эш кушсалар да җавабы - "хәзееер..." булган ди, ә әйткәнен куян малае шунда ук оныта торган булган.

Көннәрдән беркөнне Наян үзе генә өйдә калган. Әти куян белән әни куян ерак урманда яшәүче әбиләренең хәлен белергә киткәннәр ди. Наянга урманга чыгып йөрмәскә, ишекләрне ачык калдырмаска, шырпы белән уйнамаска дип әтисе кат –кат аңлаткан, ә әнисе ерак куян әбисеннән күчтәнәч вәгъдә иткән икән.

Өйдә үзе генә калган Наян башта бөтен урманга "шар ярып" музыка тыңлаган, аннан караваттан- караватка сикереп уйнаган икән. Тегендә төртелгән куян малае, монда төртелгән- бик күңелсез булган ди аңа. Шулай шул, Наян китап укырга яратмаган,рәсем ясау да кызык булмаган аның өчен. Әнә, урман малайларының кайсы җиләк җыя, кайсы гөмбә киптерә. Куян малае гына җәйләрен футбол уйнап, "трай" тибә икән.

Менә шулай Наянның эшсез аптырап йөргән чагы булган, шунда аның күзе мич буендагы шырпы кабына төшкән. Шырпы кабы бик матур, бәләкәй генә серле тартмага охшаган ди. Буе җитмәгәч, Наян, урындык куеп шырпыга үрелгән. Кулына алып селкетүгә, тартма эчендә әллә нинди тавышлар чыгарып шырпы таяклары сикергәләп куйганнар.

Наян шырпы кабын ачкан,ә анда солдатлар кебек тезелешеп шырпылар яталар ди.Ул аларны әле сындырып караган, әле тәрәзәдән урамга аткан, берсен алган, икенчесен куйган һәм кинәт шырпыны сызып та җибәргән.Ах, нәрсә бу? Куян малаеның бармаклары пешә башлаган, ул янып кәкрәйгән шырпыны идәнгә аткан. Ут, шуны гына көткәндәй, идән буйлап алга ыргылган. Менә еландай озын телләрен чыгарып ялкын да эшкә керешкән. Наян куркып калган. Аның кычкырасы килгән, бармаклары янган, ә ут идәндә куян малаеннан калган чүп- чарны ялый да ялый икән. Эх, әтисе күпме әйтте аңа, уйнама ут белән, уеннан уймак чыгар- урман янар дип. Менә хәзер аларның өйләре генә түгел, урман да куркыныч астында калды бит. Ишекне ачып бөтен урманга: “Коткарыгыз, янабыз!”- дип кычкырган Наян. Бәхетенә каршы, аларның өй турыннан Аю абзый үтеп бара икән. Эшнең нәрсәдә икәнен тиз генә абайлаган урман карты, сыбызгысын авызына алып, сызгырып та җибәргән ди. Ул сыбызгы шундый әче сызгыра икән,бу тавыштанНаянның озын колаклары да дерелдәгәннәр ди. Шул арада аларның өе тирәсенә урман халкы җыелган. Бик тырышып- тырышып ут белән көрәшкән ди алар. Матур алан буенда челтерәп аккан инеш тә бу зур эштән читтә калмаган, Наяннар ягына борылып ага башлаган икән.

Куян малаеның әтисе- белән әнисе кайтып җиткәндә, утның “пс-пс, пш-пш” дип сүнеп баруы булган икән. Әни куян, куркудан, улына дип алган күчтәнәчле сумкасын да юл кырына ташлап калдырган булган. Алар бик ашыкканнар, каты итеп чапканар, шуңа да шук малай күчтәнәчсез дә калган ди икән.

Наянны бик каты ачуланган, ди әти- әнисе. Аю абзый да мондый тәртипсез, сүз тыңламаган куяннарны урман мәктәбенә укырга алмыйбыз дип кисәткән ди Наянны. Куянның утта пешкән бармаклары бик сызлаган, урман халкы алдында да бик оят булган ди аңа. И елаган ул соңыннан, и үкенгән икән:“Моннан соң шырпы дигәннәренә тотынмас та идем,”- дип сүз биргән ди. Әтисе белән әнисенең сүзен тыңламыйча уеннан уймак чыгара язды бит куян малае Наян! Аларның ышанычларын аклый алмавына йөрәге әрнегән кечкенә куян малаеның. Уйланмаган шуклык ниди зур кайгы китерергә мөмкин иде бит. Аздан гынаөйләре дә,урман да күккә көл булып очмады!

Шуның белән әкиятебез тәмам.Менә шулай, малайлар- кызлар, бу көннәрдән алып куян малайлары да шырпы белән уйнамый башлаганнар ди. Сез дә уеннан уймак ясамагыз, өлкәннәрнең сүзләрен тыңлагыз.

## ИЛ КАҺАРМАНЫ

*Сибгатуллина Нәзилә, «Яр Чаллы педагогия көллияте» нең 3 курс студенткасы*
*Җитәкче: Минһаҗева Р.Ә.*

Җир йөзендә күпме милләт,
Һәр милләтнең үз батыры.
Татар халкы язмышы да
Синекедәй – моңга тулы.

Илемнең чын каһарманы
Булгансың син, Муса Җәлил!
Һәрчак җиңүгә өндәгән
Шигырьләрең моңа дәлил.

Батырлыгың дастан булыр,
Тугры булып калсаң илгә.
Хаклык өчен, халык өчен
Иманлылар шәһит китә!

Үрнәк ала ничә буын,
Синең батырлыкны күреп.
Туган илен сөйсә генә,
Кеше – горур, кеше – бөек!

## ЮГАЛГАН КОШЧЫГЫМ МИНЕМ!

(хикәя)

*Степанова Анастасия, Алексеевск муниципаль районы Чишмә урта гомуми белем бирүмәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы.*
*Җитәкче: Розыева Г.Р.*

Алсу белән Марат кечкенәдән үк бергә уйнап үстеләр, мәктәпкә дә бергә йөрделәр, бер парта артында утырдылар, кичләрен клубка да бергә йөрделәр. Марат Алсуны ярата иде, әмма кыз моны сизмәде.

Маратка ун яшь булганда, әтиләре каты авырудан үлеп китте. Әнисе өч бала белән ялгыз калды. Көне-төне колхозда эшләде, ә йорт тирәсендәге эшләрне Марат башкарды.

Алсуны колхоз рәисенең улы - Илнурда ярата иде. Алсу белән Маратның дуслыгына бик ачуы килде. Беркөнне клубтан кайтканда, Маратка Алсу янына бармаска кушып: - “Алсу мине сайлады, сиңа анда урын юк”, - дип янап китте.

Мәктәпелларыузып та китте.Алсу югары уку йортына укырга керде. ӘМаратка авылда калырга туры килде, чөнки аңа соңгы вакытта авырап торган әнисе белән энесе һәм сеңлесенә ярдәм итәргә кирәк иде. Әмма, үзендә көч табып авыл хуҗалыгы институтының читтән торып уку бүлегенә укырга керде.

Еллар уза тора.Озак кына авыртып ятканнан соң, әнисе дә үлеп китте. Марат та инде хәзер югары белемле агроном, ә Алсу журналист.

Укып бетерү белән Алсу Илнурга кияүгә чыкты. Әмма бу никахлары уңышлы булмады. Илнур мактанчык һәм көнче булды. Алсуны Маратка гел көнләде, хәтта кул да күтәргәләде. Хатын түзмәде, бер нәрсә дә алмыйча, өйдән чыгып китте.

Илнурның тормышы аска тәгәрәде, эшләре дә бармады. Җитмәсә, соңгы араларда колхозны тикшерергә тотыналар, колхоз рәисенең кырын эшләре ачыла, зур штрафлар салып эштән куалар. Район җитәкчеләре яңа рәис куярга дип ясаган җыелышта Маратны сайлап куялар. Авыл халкы моңа бик риза булды.

Марат җитәкчелегендә авыл бик нык үзгәрде, урамнар, чишмәләр, зиратлар каралды, колхоз ярдәме белән яңа йортлар салынды. Яшьләр авылда кала башлады, сабыйлар туды. Марат һаман гаиләсез иде. Ә энесе һәм сеңлесенең үз тормышы иде. Бары яраткан эше генә аңа онытылырга ярдәм итте.

Бүген колхозда авыл хуҗалыгы семинары үткәреләчәк. Районнан, Казаннанкүп кунаклар киләчәк, журналистлар да көтелә. Тыз –быз машиналар килеп туктый , алардан халык коела.

Бу семинарга Алсу да килә. Читтән генә туган авылын, авылдашларын, Маратны күзәтә. Ә Марат бик үзгәргән: олыгаеп киткән, әйткән сүзләре, фикерләре төпле һәм ышанычлы. Менә кемне эзләгән аның йөрәге. Якында гына йөргән бәхетен ул ераклардан эзләп йөргән түгелме соң!? Шашып типте аның йөрәге, хисләрен егеткә җиткерәсе килде аның? Ул Мараттан интервью алырга дип аның каршысына барып басты. Ул янып торган күзләре белән Маратка күтәрелеп карады

-Алсу! Югалган кошчыгым минем, син бит бу. Мин сине кайлардан гына эзләмәдем, ә хәзер үзең килеп каршымда басып торасың. Ул Алсуны кочаклап алды да:

-Моннан соң бер кая да җибәрмим .

-Мин риза, -дип елмайды Алсу.

## ИҢ ЗУР ХӘЗИНӘМ ТУГАН ТЕЛЕМ

**(публицистика)**

*Тимербулатова Розалина, БДУның Стәрлетамак филиалы студенты*
*Җитәкче: Мукимова Н.А.*

*Тел - халык күңеленең кыңгыравы...*
*Ф.Яруллин*

Кем генә булса да без барыбыз да дөньяны көннән-көн таныргa өйрәнәбез. Әйе, кемгәдер ул җиңел бирелә, ә кемдер моның өчен зур көч сала. Әмма ничек кенә булмасын дөньяны туган телдән башка танып белү мөмкин түгел.

Тел - ул үзе серле һәм мавыктыргыч бер дөнья. Туган тел безгә яшәргә, башка кешеләр белән аралашырга һәм бер-беребезне аңларга ярдәм итә. Ул тормышта зур әһәмияткә ия. Нинди генә әйберне яки күренешне булсада сүз белән аңлатырга һәм тасвирларга кирәк. Әмма бу бик җиңел эш түгел, моның өчен иң беренче чиратта үз телеңне белергә һәм ул телдә уйлый белергә кирәк. Иң гади генә әңгәмәдә дә үз фикереңне дөрес аңлатып бирә белү кирәк.

Тел ярдәмендә без мәгърифәт, фән һәм мәдәният өлкәсендә зур эшчәнлек алып барабыз. Туган илнең тарихын өйрәнү дә телдән башка мөмкин түгел. Чөнки тарих ул халыкның тормышын һәм аның мәдәни үсешен өйрәнә. Шулай ук телнең байлыгы, аның үсеш мәртәбәсе халыкның мәдәни дәрәҗәсен чагылдыра.

Безнең туган телебез татар теленә бу сыйфатларның барысы да хас булуга карамастан, кешеләр аның нинди хәлдә икәнен күрмиләр. Татар теленең язмышы өчен борчылырга сәбәпләр бар. Әмма, кызганычка каршы күпчелек татар халкы үз теленең язмышына ваемсыз караштa. Моңа каршы нинди генә кануннар кабул ителсә дә халкыбызның иң зур өлеше туган телебездә сөйлшүне юкка чыгаралар, киләчәк буынга кечкенәдән үз телебездә аралашырга, аны хөрмәт итәргә өйрәтмиләр. Бу күренешне ничек атарга, халкыбызның җавапсызлыгымы әллә телгә карата карашларның үзгәрүеме? Телдән башка да яшәп буламы? Сораулар артканнан арта бара...

Ләкин иң мөһим әйберне истә тотарга кирәк: туган тел - ул безнең ата - бабаларыбызның ничәмә еллар буена туплап килгән зур хәзинәсе. Телебезне юкка чыгару безне ата - бабаларыбыз алдында зур тарихи гаепкә китерәчәк. Димәк, телебез өчен без, татарлар, хәзерге буын җаваплыбыз. Дөньяда кече һәм зур, кирәк һәм кирәкмәгән телләр юк. Телнең кирәклеге һәм кирәкмәве бу телдәге сөйләшүчеләр санына карамый, ул халкыбызның карашына бәйле. Шушы караш телнең барлык язмышын хәл итә.

Татар шагыйре, язучы һәм драматург Фәнис Яруллин телебез турында мондый күркәм сүзләр әйткән: "Тел - халык күңеленең кыңгыравы. Ә кыңгырауга кагылмасаң чыңламый. Әйдәгез, шушы кыңгырауны ешрак кагыйк. Ул тутыкмасын, тавышы гел саф, гел матур булсын, аның моңы еракка яңгырасын".

Әгәрдә вакытында “шушы кыңгырауга кагылмасак, аны чыңлатмасак” безнең телне аяныч язмыш көтә. Ваемсыз кешеләргә бу зур проблема булып күренмәскә дә мөмкин, ә уйлап карасаң безнең арабызда барысыда бу мәсьәләгә битараф караштa түгел бит. Үз халкыңның язмышын чын күңелдән кичерә белергә кирәк, аның телен һәм мәдәниятын үстерүгә барлык көчне салырга кирәк.

## СЕЗ ҮЗЕГЕЗ ШУНДЫЙ ОЛЫ ҖАНЛЫ!

*Трофимова Сафия, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкчесе: Фатыхова И.И.*

Авыр чакта Сез янымда булып,
Ярдәм кулы миңа суздыгыз.

Бар да миңа яла яккан чакта,
Мине саклап кала алдыгыз.
    Сез үзегез шундый олы җанлы,
    Рәхмәтем зур сезгә, һичшиксез.
    Зур бәладән мине коткардыгыз,
    Онытмамын Сезне берсүзсез.
Тыныч, сабыр, шулчак ярдәмчел дә,
Ходай Сезне җирдә зурласын.
Мәрхәмәтле кеше булган өчен,
Бар изгелек үзегезгә кайтсын.
    Икенче кат туган кебек булдым,
    Җанландым мин, тойдым тормышны.
    Үз колларым белән кочып алам.
    Дөнья буйлап йөргән шатлыкны.
Күпме генә рәхмәт әйтсәм дә мин
Ул бик аз Сез кылган эшләргә.
Дөньядагы булган байлык җитмәс,
Рәхмәт диеп әйтеп бирергә.
    Иртәнге таң сызылып аткан чакта,
    Ходаема сорап ялварам:
    "Сакла аны җирдә, син рәнҗетмә,
    Бәхетле тормыш бир, йә Аллам".
Игелекле, эчкерсез, саф мәрхәмәтле,
Рәхимле кеше Сез, йөрәкле.
Изге җанлы, туры сүзле, тыйнак
Күренекле сыйфат иясе.

## МӘҢГЕЛЕК СЕР
**(хикәя)**

*Фазылҗанова Диана, Биектау районы Бөреле урта*
*гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Шигапова А.Ф.*

Тормыш... Күпме мәгънә ята бу сүздә... Кемгәдер ул киң ишекләрен ачып, кочагын җәя, ә кемнедер ачы сагыш утларында көйдерә, берсеннән-берсе авыр җәзалар белән сыный...

Инде атнадан артык Наилә, елый-елый, әнисен хастәханәдә саклый. Әнкәсенең кулын тотып, эченнән генә бертуктаусыз нәрсәдер сөйли. Тик Резеда апа берни дә ишетми, җавап бирми... Наилә алай да ышана, бирешергә теләми. Әнкәсеннән башка бер туганы да юк бит аның. Резеда апага табынып яшәде ул. Бер көнгә дә аерылганнары булмады бит аларның. Һәрвакыт бергә... Наиләнең дуслары да юк диярлек. Мәктәп дуслары кайсы кая таралып беттеләр, ә группадагы кызлар аны соры тычкан урынына күреп көләләр генә иде. Шуңа күрә ул барлык серләрен бары тик әнисе белән генә бүлешә иде. Тик хәзер әни кеше селкенмичә, баласының җылы кулларын сизмичә ята. Ә Наиләнең йөрәге, палата ишеге ачылуга, урыныннан кузгалган төсле була. Табиблардан начар хәбәр ишетергә курка ул. Әнкәсенең терелүенә чын күңелдән, чын йөрәктән ышана бит балакай. Ничек ышанмыйсын инде... Әни кеше һәркем өчен дә иң якын, иң кадерле кеше бит ул.

Резеда апа белән Хафиз абый Наиләне балалар йортыннан алып кайттылар. Наиләнең туганына ике атна гына иде ул чакта. Беркемгә дә сиздертергә теләмәде алар бу хәлләрне, Наиләнең үзеннән дә яшерделәр. Нигәдер, дөреслекне сөйләргә куркалар иде алар. Аңламас, ачуланыр кебек төрле сәбәпләр аркасында әни кешенең йөрәге дөреслекне ачарга базмады.

Вакыт үтте. Гаилә күрше-күләннәргә үрнәк булырдай яшәде. Алар гаиләсендәге ихтирам, саф мәхәббәт кебек хисләр бер гаиләдә дә юк иде. Ир кеше гаиләне тулысы белән үзе алып барды. Хафиз абыйның эш урыны әйбәт иде, акчасын да вакытында биреп бардылар.Шуңа да ул Резеда апаны эшләтмәде. – Син, бәгърем, бала белән шөгыльлән, өйдәге эшне кара, ә акча табу ирләр эше ул - дип әйтә торган иде мәрхүмкәй. Резеда апа ире белән тулысынча ризалаша иде. Һәрвакыт Наилә белән янәшә булырга теләде ул. Ләкин тормыш Хафиз абыйны бик иртә алып китә. Командировкадан кайтканда юл һәлакәтенә очрап, бик күп канын югалта. Комадан чыкмыйча, тап-таза ир якты дөньядан китеп бара. Әле яшисе дә яшисе иде бит аңа. Бу вакыйгаларны Резеда апа белән Наилә бик авыр кичерделәр. Тик тормышны алга таба алып барырга кирәк. Алар бер-берсенә терәк булдылар. Резеда апа көндез кибеттә ипи сатты, ә кич белән “байларга” өй җыештырырга йөрде. Наилә дә тик ятмады, укудан соң “бәхет агачлары” ясап сатты. Наиләнең кулыннан эш килә иде, бөтен күңелен биреп эшли ул андый эшне.

Шулай көн артыннан көн үтте. Наилә укуын уңышлы тәмамлады. Балалар табибы булып эшкә урнашты. Эшенә ул бөтен күңелен бирде. Резеда апа газиз баласының уңышларына бик шатлана иде.

Иртүк бар да гадәттәгечә булды: торып, тиз генә җыенды Наилә. Әнкәсе белән бергәләп утырып чәй эчтеләр, серләрен бүлештеләр. Наилә, гадәттәгечә, эшкә китте, ә Резеда апа хастәханәгә барырга дип документларын җыйнарга керeште. Шул мизгелдә ишеккә кемдер шакылдатты. Резеда апа сискәнеп китте. Ул Наиләне балалар йортыннан алып кайтканнан бирле һәрбер тавыштан курка иде. Нигәдер, Наиләнең әнисе кире кайтыр дип сизде ул. Һәм бүген, кызганыч, Резеда апаның уйлары дөрес булып чыкты.

Ишекне ачуга, Резеда апаның күзе затлы киенгән, матур йөзле, ләкин күзләре яшь белән тулган ханымга төште. Башта танымады, ул ханым:

- Гафу ит, Резеда! - дип, Резеда апаның аякларына тезләнде. Резеда апаның күзләре яшь белән тулды, бугазына төер кадалды. Аның алдында басып торган ханым аның яшьлек дусты Айсылу иде. Алар студент чакта гел бергә булдылар, бер парта артында утырдылар,тулай торакта бер бүлмәдә тордылар, кинога, клубка бергә йөрделәр. Тик язмыш аларны аерды. Резада апа тыйнак, акыллы, укуда да алдынгы булды, ә Айсылу ханым укырга яратмады, аны күбрәк клуб, бай ирләр кызыксындыра иде. Резеда апа төрле юллар белән Айсылуны начар юлдан коткарырга теләде, тик Айсылу беркемне дә тыңларга теләмәде.Укуын өченче курста ташлады, бер өйләнгән ир белән чуала башлады. Ул ир кеше студент кызның башын әйләндерә, алтын таулар вәгъдә итә, ә Айсылу ханым үз чиратында дөньяга ал күзлек аша карады, аңа ышана. Тиздән балага уза. Ул ир кеше бала тугач, аерылып аңа кияүгә чыгар дип өметләнә. Тик хыяллар чәлпәрәмә килә.Бала турында ишетүгә, ир кеше бөтенләй юкка чыга.

-Минем бала түгел ул, ни теләсәң шуны эшлә, миңа һәм минем гаиләмә якын киләсе булма, тагын бер күрсәм, үзеңә үпкәлә – дип янады. Айсылу ханым шул вакытта баланы бала табу йортында калдырырга дип уйлый һәм шулай эшли дә. Моның турында якын дусты Резеда апага сөйләргә була. Резеда апаның Хафиз абый белән өйләнешкән генә вакытлары иде. Алар ике дә уйламыйча баланы тәрбиягә алырга булалар. Тик Айсылу ханым белән Резеда апа арасында килешү була, һәм ул килешү буенча Айсылу ханым бөтенләй алар тормышыннан юкка чыгарга тиеш була.

Шул көннән башлап Айсылу ханымның кире кайтуыннан курка ул. Наиләгә дөреслекне ачырга теләми, дөреслек ачылса, Наилә үз әнисен эзләп китәр дип уйлый ул....

- Айсылу, ник кайттын, кит, кит, хәзер үк кит –дип кычкырып җибәрде Резеда апа. Куллары калтырый, йөрәге еш-еш тибә башлады.

- Резеда, мин аннан башка яши алмыйм, тешләремә керә. Көнем-көн, төнем-төн түгел минем. Зинһар, бер генә тапкыр булса да күзләренә карарга рөхсәт ит. Зинһар.....Зинһар дип сорыйм. Кире какма, дустым!

- Айсылу.... Юк, юк, юк. Син алай эшләргә тиеш түгел. Мин...Мин теләмим!- дип кычкыра ул калтыравыклы тавыш белән. – Хафиз үлгәннән соң, әле аякка гына бастык, хәзер син... Ходаем, нәрсә өчен бу газаплар?- Резеда апа үксеп еларга тотынды.

- Мин аның энисе, син алай эшли алмыйсың, Резеда, үтенәм.

- Кит, кит, зинһар кит, Айсылу...

- Китәм, тик мин кире кайтачакмын... Наилә мине аңлар, мин ышанам, аңлар.

Резеда апа шашып-шашып елый. Нәрсә эшләргә дә белми ул. Авыр булса да, Наиләгә барлык дөреслекне сөйләргә уйлый.

- Наилә белсә, гафу итмәячәк, мина рәнҗер. Юк болай булмый...- дип сөйләнә-сөйләнә, Наиләнең эшенә йөгерә. Урам буйлап,елый-елый, алдын-артын карамыйча, уйларына бирелеп бара. Тирә-яктагы кешеләр ни уйлаганы аны бу мәлдә бөтенләй кызыксындымый. Юл аша светофорның кызыл төсенә чыгуын күрми дә кала, кызу килгән машина вакытында туктый алмый. Резеда апа машина астында кала....

Өй ишеген ачып керәм дигәндә, Наиләнең телефоны чылтырый. Әнкәен авыр хәлдә хастәханәгә алып китүләре турында полиция хезмәткәре хәбәр итә. Кыз тизрәк ишекне кире бикләп газиз әнисе янына чапты.

Наилә хастәханәгә килгәндә Резеда апаны реанимациядән палатага чыгарганнар гына иде әле. Тизрәк әнисенең салкын кулларын җылытырга кереште ул.

- Әнием, бәгърем, терелә генә күр, зинһар! Мин сине бик, бик нык яратам.

Шул вакытта, палата ишеген әкрен генә ачып Айсылу ханым керде. Наиләнең Резеда апага әйткән сүләрен ишетеп торды ул. Дөреслекне ачарга дип килгән Айсылу ханым, Наиләнең сүзләреннән соң, ниятеннән кире кайтты.

Наилә артында басып торган ханымга карап:

- Исәнмесез. Сез кем буласыз?

- Минем кем икәнем мәңгелек сер булып калсын...- дип Айсылу ханым чыгып китә.

Бу вакытта Резеда апа күзләрен ачып җибәрде. Шатлыктан, теге "сәер ханым" Наиләнең уеннан бөтенләй югала. Хәзерге минутта аны бары тик әнисенең сәламәтлеге генә кызыксындыра иде. Бер-берсенә әйтәсе җылы сүзләре күп иде аларның. Тик булган вакыйгалар Наилә өчен мәңгелек сер булып калачак.

## ОЧРАШЫРБЫЗ ӘЛЕ...

*Фатыйхова Илзия, КФУның Алабуга и нституты студенты*
*Җитәкче: Саттарова Г.Г.*

Үтсә дә күп еллар,
Барысы да беткәч үзгәреп.
Тик йөрәктә бары син булырсың,
Хәтеремдә – синең күзләрең.
Аяз көндә, бәлки усал төндә
Җәйге чиллә, кышкы салкында
Бу хыяллар бер тормышка ашар,
Тавыш бирер йөрәк сак кына.
Җыерчыклар тулы йөзләр булыр,
Чәчләр инде акны йөгерткән,
Гаиләлеме, яки ялгыз килеш,
Тик йөрәктә янар ут-көлтә.
Син һаман да шул ук чибәрлектә,
Яшь кыз түгел үзем күптәннән.
Тик күңелдә янә кайнап чыгар
Яшьлек хисе, сине үпкәндә.

Элеккечә, янәшәдән әкрен,
Хыялланып алга атларбыз.
Миңа калса, тормыш бушка үткән:
Тота алмагач әйткән антлар без.
Агачлар да бер торыкка биек,
Без очрашкан урын инде юк.
Тормыш кыска, очрашулар тагы да,
Сызгырып оча яннан гүя ук.
Мин онытмам мәңге ул сөюне,
Мәхәббәтне, мине җылыткан.
Тик бит сине явызларга тартып
Инде ничә дистә ел йоткан.
Кайдан эзлим сине ул чагында?
Кай тарафта ул сөю тәме?
Күп еллар да безне аера алмас.
Ышан гына!
Очрашырбыз әле...

## ӘБИЕМ БӘЛЕШЕ

*Фатыйхова Таңсылу, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең  10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Смирнова Г.Д.*

Кайтып киләм, урамнарга чыккан
Әбиемнең бәлеш исләре.
Әби салган бәлеш исе белән
Нинди рәхәт авыл кичләре!

Алмагачка сыерчык  кунган,
Узып-узып җырлар сыздыра.
Әби кулы салган бәлеш исе
Барысыннан да бүген уздыра.

Ничек итеп тойган кайтасымны!?
Тәмле итеп куйган пешереп.
Бәлешләрен алган яңа гына
Кайтуымны белгән ничектер.

Әби күңеле сизә диләр аны,
Кайтасымны бүген белгәндер.
Юлларымның хәерлесен теләп,
Бәлеш авызларын бөргәндер.

Чәчәкләрдә уйнап кортлар оча,
Алмагачлар үсә тезелеп.
Түзә алмагач, капкаларын ачып,
Әби көтә мине өзелеп.

Кайтам, әби, тагын яннарыңа
Бәлешләрең салып көт мине.
Әби кулы бөргән бәлешләргә

Җир йөзендә юктыр бер тиңе.

## ДӨНЬЯ ҖАЕ

*Фатыхова Лиана, Тукай районы Кече Шилнә мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Әхмәтҗанов Н.В.*

Дөнья ул шундый нәрсә,
Көтмәгәндә бирә бит сынауларын,
Җәйге аяз көндә дә
Күрсәтә сынауларын.
Авырлыкларны җиңәргә
Кирәк гел пар канатың,
Хөрмәт итсен балалар
Һәрчак ата-анасын!

## ОЛЫ ЮЛГА БАСАБЫЗ

Без булгач белем бирергә
Укучылырыбыз шат,
Тырышып шулай эшләгәч
Йөзләребез булыр ак.
Бердәм дәүләт имтиханын
Тырышып биреп чыгыйк,
Олы юлга тартыйк барсын бергә
Ялкауларын орышыйк.

## СОҢЛАП КИЛГӘН БӘХЕТ

*Фәйзуллина Регина, Зәй муниципаль районы “Түбән Биш урта гомуми белем мәктәбе”нең 10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Әхмәтвалиева И.И.*

Бәхет...

Нәрсә соң ул бәхет? Дөнья яралганнан бирле кешеләрне шушы сорау борчый. Гомере буе шул бәхет турында хыяллана адәм баласы. Ләкин ул җиңел генә бирелми шул.Һәрчак бәхетсезлекләр белән аралашкан була. Күңелне җилкендергән шатлыклы минутлардан соң, хәсрәтле сәгатьләр дә килергә мөмкин.

Әлфия апа йокысыннан уянып китте дә тәрәзәгә карап уйланып ятты. Ә анда шау чәчәккә күмелгән шомырт агачы иде.Ул яшь чакларын искә төшерде.

Яшьлек! Нинди матур сүз! Ә Әлфия апаның яшьлек юлдашы-ятимлек. Әти-әнисе бик иртә вафат булдылар. таяныр, киңәшер кешесе дә булмаган кыз балага иртә кияүгә чыгарга туры килде. Күрше авылларында хатыны үлеп ике бала белән ялгыз калган Халиткә кияүгә барды. Бигрәк тә ике баласын кызганды. Яратмаса да, түзде, сабыйлар хакы бар бит.Ә ире юньле кеше булып чыкмады, Өйләнешеп күпмедер үтүгә чын йөзен күрсәтә башлады.Тиз кызып китә, көнләшә, хәтта кул күтәрүдән дә чирканмый. Әлфия апаны бик нык рәнҗетте, балаларына дә көн күрсәтмәде.

Әйе. Мондый тормыш озакка бармады, ире түбәдән егылып төшеп, умыртка баганасын сындырды. Шул хәлләрдән соң ул озак яшәмәде, улеп китте. Әлфия апа тагын ялгыз калды. Юк, юк ялгыз түгел. Аның ике баласы - Рамил белән Раиләсе бар.Ул бит балаларга хәзер бигрәк тә кирәк. Аларны үстерәсе, укытысы, кеше итәсе бар...

Балалар үсеп җитте. Югары уку йортларын тәмамлап, берсе-табиб, икенчесе – укытучы булды. Үз тиңнәрен табып, матур итеп тормыш корып җибәрделәр. Үстергән әниләрен дә онытмадылар, янына гел кайтып йөрделәр. Әлфия апаның тормышы шулай матур гына үрелеп барды. Ул хәзер оныкларының да яраткан әбисе.

Сүземне бәхет сүзе белән башлаган идем. Бәхетне кем нәрсәдә күрә инде. Кемгәдер ул катлы-катлы йортлар, затлы машиналар булса, кемгәдер үзеңнең кирәклегеңне белү дә җитә. Әлфия апа да бүгенге көндә бик бәхетле, чөнки ул балаларга бик тә кирәк. Аның тырышлыгы бушка китмәде: балалары акыллы, тәүфыйклы булып үстеләр. Ә бу бәхет түгелмени?

## ТӨЛКЕ БЕЛӘН КУЯН

(әкият)

*Фәрдиев Инсаф, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*

*Җитәкче: Шакирзянова Н.Г.*

Борын-борын заманда калын урманда бик дус-тату булып куркак куян, соры бүре һәм хәйләкәр төлке яшәгәннәр.

Шулай беркөнне бүре авырып киткән, ди. Иң беренче бу хәбәрне куян ишеткән. Гомумән, ул кая гына барса да, кемнең генә сөйләшкәнен ишетсә дә, колак салып тыңлап торырга яраткан. Шул хәбәрне ишеткәч тә, бүре янына хәл белергә киткән.

- Бүре дус, хәлләрең ничек? - дигән ул.

Бүре янында куяннан башка тагын күп кенә җәнлекләр дә булганнар. Ләкин алар арасында төлке генә күренмәгән.

Куян бүренең хәлен белгәнннән соң, аланга таба юл тоткан. Шулвакыт юлда төлке белән аюның сөйләшеп торганын ишеткән. Ул тиз генә куаклар астына качып, колакларын торгызып тыңлый башлаган. Төлке аюга әйтә икән:

-Аю дус, син бүре янына барсаң, мине сораса: “Сиңа дару эзләп китте” диярсең. Ә мин тиз генә авыл ягына барып кайтам, мине сатмасаң, сиңа да өлеш чыгар! – дип, хәйләкәр елмайган да юк булган. Ә аю лап-лоп атлап бүре яшәгән якка юнәлгән.

Моны ишеткән куян ялт итеп йөгереп бүре янына барып җиткән, хәлне сөйләп тә биргән. Төлкенең алдакчы һәм хәйләкәр булганына бүренең ачуы чыккан.

Ә бераздан төлке үзе дә күренгән.

- Кайда идең син моңа кадәр? - дигән бүре.

- Мин сиңа дару эзләдем, ләкин тапмадым,- дигән төлке. – Ләкин күчтәнәчсез килә алмадым, – дип бүрегә бер калҗа ит китереп салган.

Шул көннән соң барлык эшләрне дә оста чишә белгәне өчен төлкене– хәйләкәр дип, ә барлык хәбәрне ишетеп, тыңлап йөргәнгә куянны озынколак дип йөртә башлаганнар.

## АК БОЛЫТЛАР

*Фәрҗиева Илүзә, Әлмәт политехника техникумы студенты*

*Җитәкче: Хәйруллина З.В., Камалова З.Ә.*

Зәңгәр күктә ак болытлар
Кая агыла икән?
Алар да безнең кебек
Кая ашыга микән?
Нәкъ ак болытлар төсле
Минем очасым килә
Алардагы җиңеллекне
Җанда тоясы килә.
Очасым килә диеп,
Болытларга үреләм

Менә-менә тотам диеп,
Кояш нурына күмеләм.
Әй, болытлар, көтегезче
Хәзер тотам, аз калды.
Барыр юлга маяк булып
Артларыннан эз калды.
Нәкъ ак болытлар төсле
Минем очасым килә.
Алардагы җиңеллекне
Җанда тоясы килә.
***
Кешене табуы җиңел дә
Авырдыр югалтуы
Җитми минем күңелгә
Кемнеңдер юатуы.
Берсен дә күрә алмаганда,
Канатларың сынмасын.
Күңелең ачу белән тулса да,
Саф хисләрен җуймасын.
Синең ничек елаганны
Берүк кеше күрмәсен
Җаныңда булганнарны
Беркем берни сизмәсен.
Бар газаптан шифадыр
Йөрәктәге сабырлык
Аерылуга дәвадыр
Күңелдәге тынычлык.
***
Тормыштан мин ардым диеп,
Күпләр бездән китәләр
Үлмәгән ул кайтачак дип
Якыннары көтәләр.
Кире кайтыр җирләр түгел,
Шуны аңларга кирәк.
Юксынудан елый күңел
Юатучы бик сирәк.
Якыныңны югалтудан
Авыр нәрсә юк икән
Иң мөһиме йөрәгеңдә
Синең өчен ул исән.
***
Сабыр төбе сары алтын,
Юкка гына әйтмиләр.
Кире кайтасы кешене
Тиккә генә көтмиләр.
Көткәннәрнең минутлары
Сәгатьләргә тиңләшә.
Күрешү көне җиткәч,
Икәү бергә серләшә.
Көтик әле сөйгәннәрне

Рәхәте безгә була.
Күрешү бәхетеннән
Күзләр дә яшькә тула.

## ДУСЛЫК КАДЕРЕ

Нишләр идең икән син,
Якын дустың янда булмаса?
Тамагыңа төер килеп
Бугазыңа синең утырса.
Бу дөньяда якын дуссыз
Яшәп булмый икән, ләбаса.
Авыр хәлдә калсаң таяныргa
Чын дус булсын синең яныңда.
Ник бу тормыш шулай гаделсез,
Якын кешеләрдән аера,
"Үргә менәм" дигән чакта гына,
Синең канатларны каера.
Нишләргә? Кайдан җавап эзләргә?
Моның белән килешергә кала.
Барысына да үч итеп,
Бары алга гына атларга.
Менә күрерсең, бәхет килер
Юлларыңа чыгар өелеп.
Бу тормышның кадерен белеп
Яшик бергә бары сөелеп.

## ӘНИЕМ-ЙОЛДЫЗЫМ

Сокланамын аңа карап,
Тырышамын сиңа ярап,
Әнием – син йолдызым,
Әнием – син моң сазым.
Әнием, син бу дөньяда
Иң газиз кешем минем,
Бары тик синең янда
Ачыла серләр минем.
Һич югалтырга теләмим
Янымдагы кояшны
Таратасың бит, әнием,
Күңелдәге сагышны.
Картайма, мәңге яшә,
Минем якты йолдызым!
Әни дә елмаеп дәшә,
Син бит минем алтыным.

## САГЫНУ

Өйдә ничек рәхәт икәнен
Киткәч кенә аңлыйсың.
Шәһәргә килеп җиткәч тә,
Кайтырыңа көннәр санאיйсың.
Сагындыра икән туган йорт,
Сагындыра һәрбер почмагы,

Сагындыра яңа пешеп чыккан
Әнкәемнең өчпочмагы.
Кайтасы килә диеп,
Көн саен көннәр саныйм
Сагына-сагына тәрзә аша
Кайтыр юлларга карыйм.

***

Өнемдәме, әллә төшемдәме
Сине күреп саташтым.
Татлы хисләргә бирелеп
Күзләреңдә адаштым.
Гашыйк булдым дисезме?
Әйе, мин гашыйк булдым.
Синең якты исемеңне
Йөрәккә мәңге уйдым.

***

Бүген килерме икән дип,
Көн саен уйлар уйлыйм.
Килмәсәң дә, синең белән
Күрешер көннәр саныйм.
Бер генә җылынасы иде
Синең җылы куеныңда,
Беләсеңме син минем
Көн саен бит уемда.
Ялгыш кагылып киткәндә,
Синең исләреңнән саташтым.
Татлы хисләргә бирелеп
Күзләреңдә синең адаштым.

***

Күзләреңә карау белән,
Гашыйк иттерден мине.
Килер юлларга карап,
Иртә-кич көтәм сине.
Сине күргәч, шатлыгымнан
Йөрәгем дөп-дөп тибә.
Күзләрдәге очкыннар да
Бар нурын сиңа сибә.
Йөрәктәге хисләремне
Аңларсыңмы икән син?
Әллә чынга алмыйча
Көләрсеңме миннән син?
Саташтым бугай мин
Сиңа булган сөюдән.
Йа, Ходаем, сакла син.
Мине янып-көюдән.

***

Мәхәббәтнең күзе сукыр диләр
Дөрес микән бу сүзләр?
Безнең икебезнең арабызга

Ходай кертмәсен читләр.
Бер-береңне яратканда,
Кирәк микән буш сүзләр?
Безнең саф сөюебезгә
Тимәсен чит-ят күзләр.
Янында терәк барында
Яшәве дә бик рәхәт.
Әле дә ярый син булганга,
Көн саен әйтәм "рәхмәт"

## ТЫЛСЫМЛЫ ЧӘЧӘК

(әкият)

*Фәрхетдинова Гөлназ, Алабуга шәһәре 9нчы урта гомуми белем мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Нөркәева Г.Ф.*

Борын-борын заманда яшәгән ди Айсылу исемле бер кечкенә кыз. Аның бик усал үги анасы булган. Әнисе аны яратмаган. Бервакыт Айсылу бәйләмен алып, урамга чыгып киткән. Ул бик матур болын табып, шунда утырган һәм җырлый-җырлый бәйли башлаган. Шулай бәйләп утырганда аның кулыннан энәсе төшеп киткән һәм үлән арасында югалган. Ул бик курыккан. Кайгырып өенә кайтып киткән. Өйдә әнисе янына килгән һәм барысын сөйләп биргән.

Үги әнисе аңа әйткән:

- Бар, энәңне эзләп тап. Энәсез өйгә кайтма.

Кыз елый-елый кире болынга йөгергән һәм биек үлән арасыннан үзенең энәсен эзли башлаган. Ул эзләгән саен үлән тизрәк үсә башлаган. Кыз башын күтәреп караса, үлән аннан биегрәк булган.

Эзли-эзли торгач, Айсылу икенче бер болынга барып чыккан. Анда кошлар сайрый, төрле-төрле чәчәкләр үсә, зәңгәр күктә кояш балкый. Матур-матур күбәләкләр оча. Күбәләкләр чык тамчыларын җыеп, чәчәкләргә су сибәләр. Бу чәчәкләр гади генә түгел, ә тылсымлы. Аларны иснәсәң, хуш исеннән бик бәхетле, игелекле буласың. Айсылу чәчәкләрне җыеп, үзе белән алган. Юлда очраган кыргый усал хайваннарга бирсә, алар шундук игелеклегә әверелгәннәр.

Шулай бара торгач, Айсылу янына бер карт әби килеп баскан. Әби кыздан эчәргә салкын су сораган. Айсылу йөгереп кенә тылсымлы инештән салкын су алып килгән һәм әбигә биргән. Әби бик сөенгән, Айсылуны үзенең өенә чакырган.

Айсылу әбинең өенә керсә гаҗәпләнгән. Монда бик пычрак булган. Ул әбигә әйткән:

- Әбием, син бакчада ял итеп, йоклап ал, ә мин монда җыештырам.

Әби риза булган. Ул бакчага чыгып, зур агач астына яткан.

Айсылу тиз генә су алып килгән. Савыт-сабаларны юган, тузаннарны сөрткән, идәннәрне юган, өстәлгә матур чәчәкләр куйган. Мендәр-юрганнарны каккан, урыннарны җыештырган. Тәмле бәлеш пешереп, өстәлгә куйган. Әби йокысыннан уянып, өйгә керсә, бик сөенгән. Ул кызга әйткән:

- Кызым, теләсәң мин сине хәзер өеңә кайтарып куям, - дигән.

Кыз әйткән:

- Юк, әбием. Мин бу болында үземнең энәмне югалттым. Үги әнием энәсез өйгә кайтмаска кушты.
- Әй, балакаем. Менә бит ул синең энәң. Бәйли башлаган оегыңны да бәйләп бетердем.

Кыз бик сөенгән. Әбине кочаклап, битеннән үбеп алган.

Әби аны өенә кайтарып куйган. Кыз үзе белән тылсымлы чәчәк тә алган иде. Ул аны әнисенә бүләк иткән. Әнисе бу чәчәкне иснәгән һәм игелекле кешегә әверелгән. Ул кызны ярата башлаган. Шушы көннән Айсылу бик бәхетле кыз булган.

## ТУГАН ТЕЛ

*Филипова Юлия, Мөслим районы Яңа Усы төп мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Григорьева С.М.*

Телләр бик күп җирдә, тик шуларның
Бары берсе җанга кадерле.
Бишек җыры булып, төшләремдә
Бер моң булып телә бәгырьне.

Телләр бик күп җирдә, тик нигәдер,
Онытыла газиз туган тел.
Искелектән, имеш, шулай качып,
Ят телләрдә сөйләшәбез гел.

Телләр бик күп, әмма ана теле,
Һәрвакыт яңгырый күңелдә.
Яралы коштай һаваларны иңли,
Туган телем илем күгендә.

## ТУГАН ҖИРДӘ МИН БИК БӘХЕТЛЕ!

Бәхет эзләп, анда-монда чабып,
Башларына инде чал кунгач,
Туган нигез тарта кешеләрне,
Җирси кеше, гомере узгач.

Уйланмаган, яшьрәк вакытында,
Сукмакларга үлән үскәне.
Су буенда үскән куш каенны,
Утын, – диеп кемдер кискәне.

Чишмәләрнең күптән суы бетеп,
Чалышайган агач бурасы.
Күпме йортны караучысыз итеп,
Бакыйлыкка күчкән хуҗасы.

Бетеп бара, – дибез авылларны,
Сирәк туа бала-чагалар.
Алары да, үсеп җитәләр дә,
Чит җирләргә канат кагалар.

Туган якны, үскән нигезеңне,
Ташлаганга кем соң гаепле?
Ә мин, монда, туып-үскән җирдә,
Гаиләм, дуслар, бик тә бәхетле!

## НИГӘ?

*Хадиева Алия, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбе 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Мәхмүтова Г.Р.*

Мәхәббәтнең нинди хис икәнен
Тою һәркемгә дә бирелә.
Тик нигәдер, берәү тиңен таба,
Кайберәүләр ярсыз тилмерә.
    Кемдер сөя, сөелә, гаилә кора,
    Бик бәхетле гомер кичерә.
    Яшерен сөю, җавапсыз мәхәббәт
    Кемнәрнеңдер күңелен көйдерә.
Нигә ходай бөтен кешегә дә
Мәхәббәтне тигезләп бүлми?
Кемнең генә икән бу дөньяда
Иң бәхетле buласы килми?

## УРАМДА ЯЗ

Урамда яз. Ә кыш әле
Җыенмый бирешергә.
Әллә телиме яз белән
Чын-чынлап көрәшергә?
    Китәсе килмидер дә бит,
    Соң, нихәл итмәк кирәк?
    Язгы кояш җылытканда,
    Эри хәтта туң йөрәк.
Кышның ап-ак карлары да
Тамчылар булып тамар.
Урам иңләп, юл тутырып
Гөрләвекләр дә агар.
    Кыштан аклык, сафлык көтсәк,
    Язлар өмет уята.
    Агачлар яфрак яралар,
    Алмагач чәчәк ата.
Яңа тормыш башлана күк,
Күргәч мондый хозурлык.
Барысы өчен рәхмәт әйтеп
Тәңребезне олылыйк.

## ТӨШЕМДӘ КҮРГӘННӘР…

*Хамидов Лазиз, Башкортостан Республикасы Салават районының Нәсибаш төп гомуми белем бирү мәктәбе укучысы*
*Җитәкче: Михайлова М.Ф.*

Буген йокым - йокы булмады. Чын кино кебек, язучылар, әллә нинди укучылар белән саташып чыктым. Бер абый белән бик озак сөйләштек. Аның яныннан кеше дә өзелми. Әле тегендә чакыралар, әле монда. Мрнем белән дә сөйләшә, нәрсәдер язып та ала. Тукта! Ул бит аерылышканда миңа нindидер язу бирде: « мендәр астыңа куй, торгач укырсың, диде. Кеееm? Нәкый Исәнбәт!? Менә сиңа мә! Нинди Кеше белән очрашканмын бит! Их, тиле баш, сораулар да бирмәгәнмен. Ә хат кызык язылган, укып карагыз.

Исәнмесез! Әйе, бу мин - Нәкый Сиражетдин улы Исәнбәт - бүген сезнең арагызда! Мин 1899 нчы елның 29 нчы декабрендә Татар Малаязы авылы мулла гаиләсендә туганмын. Башта мине әнием укырга өйрәтте. Аннан авыл мәдрәсәсендә укуымны дәвам иттем. Бәләкәй чагымда ук әдәбият белән кызыксына идем. Шигырьләр, хикәяләр укырга ярата идем. 10 яшьтә беренче шигыремне язып карадым.

Өй артында каеным бар,
Тибрәтә җилләр исеп:
Әнкәм йорты – яшел бишек,
Онытыйм ничек итеп?
Гөлләр үсә безнең өчен,
Без үсәбез – ил өчен…

Шулай, шигырь кеше күңелендәге тирән фикерләрне ачык итеп әйтә дә бирә!

Яңг(ы)рап үткән ул гомернең
Мин авазын тыңладым
Яңг(ы)рап үтте гомерләр,
Син сазыңны уйнадың!

Илһам Шакиров гомер буе мине шигыремә язылган “Син сазыңны уйнадың”ны җырлады. Халык та бик яратты бит бу җырны.

Малаяздан киткәч, мин укуымны Уфадагы “Хөсәения”, “Галия” Казандагы “Мөхәммәдия” мәдрәсәләрендә дәвам иттем. Көннәрдән беркөнне минем янына мәдрәсәнең өлкән шәкерте килеп керә. Ул - Агыйдел буеннан килгән Шәехзадә Бабич. Безнен сөйләшү болайрак барды:

*Ш. Бабич.* Нәкый, сине шигырь язарга ярата, диләр. Нәрсә язасың? Җә, күрсәт әле. Мин дә шигырьләр язам бит.

*Мин.* (Шигырь дәфтәрен чыгарып). Менә, мин шигырьләремне шушы дәфтәргә җыеп барам. Берәрсен укып күрсәтимме?

Нинди салкын, җанга рәхәт,
Нинди ямьле җәйге төн.
Таулар, урманнар, болыннар,
Нинди серле, нинди тын!

*Ш. Бабич.*Шигырьләрең әйбәт икән. Сиңа бер киңәш, Нәкый, язуыңны туктатма. Халык җырларыннан өйрән язарга. Ярый, уңышлар сиңа!

Ул очрашу минем тормышымда бик әһәмияткә ия булып чыкты. Чонки, мине, эле яшь шагыйрьне беренче булып, әдәбият мәйданына чыгаручы - башкорт, татар әдәбиятының классигы Ш. Бабич булды. Ә соңыннан ул куен дәфтәренең икенчесен дә сорап алды. Вакыт үтү белән кире кайтарып биргәндә мине рухландыручы сүзләр язылган була.

*Ш. Бабич*

Яшә, Нәкый!
Мин сине тәбрик итәм
Шигъриң белән, Әхмәтнәкый!
Бик шат булдым,
мәмнүн булдым мин сиңа,
Рәхмәт Нәкый!

Минем турыда халык авыз иҗатына нигезләнеп бик күп шигырьләр һәм поэмалар язган дип сөйлиләр, хәзерге язучылар, укучылар, критиклар. Ш*улайдыдыр да, чөнки а*лар туган илгә, халыкка хезмәт итү, саф мәхәббәт, табигый матурлык һәм җан җылысы эзләү темаларын үз эченә ала.

*Минем турыда тагын: «җ*аны, рухы белән Нәкый сәнбәт бөек Тукайдан эстафетаны алып калучы әдип исәбенә керә», - дип тә сөйләргә яраталар. Булды шул, Тукаебыз турында язмый кала алмадым мин:

Зур шагыйрьләр дөньясына күзне салганда,
Анда оҗмах төсле татлы көн күрүләр нуры ялтырый.
Мин дә кермәкче буламын шул иҗат дөньясына,
Гомерың, Байроннарың йөзгән шагыйрь дәрьясына.
Тик җыен көндәш белән тулган минем арт-алларым,
Шул теләгемнән көлә минем барча дошманнарым.
Барча азгын, барча дошман булса ни дә торса – чурт!
Зур шагыйрьләрдән Тукаев булса – хәлфә, мин – шәкерт!

Февраль революциясеннән соң, кыска сроклы педагогия курсларын тәмамлагач, 1917 елның көзеннән алып 1920 елның җәенә кадәр мин тугани төбәк авыллары (Атау, Тазтүбә, Үрге Кыйгы) мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыттым.

1920 - 1922 елларда, укытучылык хезмәтеннән аерылмыйча, Уфа Халык мәгарифе институтында һәм Харьков университетының халык мәгарифе факультетында белем алып, аннары яңадан мәктәптәге эшен дәвам иттердем: Мәсәгуть педагогия курсларында, Уфадагы урта белем бирү һәм совет-партия мәктәпләрендә, театр училищесында тел-әдәбият укыттым. Укытучылык бик ошый иде мина.

1929 елның ахырларында Татарстанга күчеп килдем һәм 1940 елга кадәр Казандагы сәнгать техникумында, химия-технология институтында һәм рабфагында, кооператив техникумында - укытучы, «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында - эшче (1930—1932) һәм Әтнә районында мәктәпләр буенча методик кабинет мөдире булып эшләргә туры килде миңа. 1940 елдан бирле- язучы-профессионал сыйфатында әдәби һәм гыйльми иҗат эше белән генә шөгыльләндем.

Истәлекләр, истәлекләр… Укучыларым мине Исәнбәт фамилияле дип беләләрдер әле. Ә замандашларым, якташларым Закиров дип тә искә алалардыр. Анысы да дөрес. Закиров – ул минем атамның фамилиясе. Ә Исәнбәт дигәнне мин соңрак псевдоним итеп алдым.Ул минем җиденче буын ерак бабам булган.

Минем бәләкәй чактан ук яраткан тагын бер шөгылем бар иде. Кешедән ишеткән табышмак-мәкальләрне, әйтемнәрне җыеп, теркәп бардым мин. Бу яраткан эшемне үсеп, укытучы булгач та, язучы, галим булып җиткәч тә ташламадым. Миңа, аркама шушы юл капчыгын аскан хәлдә, кәгазь, каләм белән бик күп авылларда булырга туры килде. Халыктагы авыз иҗаты җәүһәрләрен җыеп, бергә туплап калдырасым килде. Искә төшереп карыйк әле.

Әке, бәке, кыек сәке
Чәүкә, чыпчык, син кал, син чык.
Менә шундые да бар иде: бер, ике, өч,
Әнә теге якка күч.

Шулай итеп, халыкның хикмәтле әсәрләрен җыеп, тәртипкә салып басмага тапшырдым. 40 мең мәкальне үз эченә алган өч томым дөнья күрде. «Тиңе булмаган хәзинә, сокландыргыч хезмәт!», - диләр. Бәлки, шулай булсын өчен тырышылгандыр да. Халкыма, балаларга атап җыйган байлыклар бит алар!

Мәкальләрне генә алыгыз! Укучылар, кечкенә балалар бик ярата мәкаль әйтешеп уйнарга. Укытучы апалары мәкальнең башын әй талә, ә балалар дәвам итәләр. Кызык бит!

- Ни чәчсәң... - шуны урырсың.
- Кем эшләми... - шул ашамый.
- Какма кеше капкасын... - үзеңнекен кагырлар.
- Ачтан үлсәң дә.. - эти-әниеңне ташлама.
- Бер тиенлек - куян... – ун тиенлек зыян.

Яшь буын минем иҗатымны онытмый: яттан шигырьләр сөйләнә, уеннар уйнала, җырлар җырлана, мәкальләр беләсез икән - минем хезмәт бушка китмәгән дигән сүз. Укучым

күңелендә халык иҗатын, балалар фольклорын җыючы итеп искә алалар икән, мин моңа бик шатмын.

Шул ук вакытта тәрҗемә эше дә бик кызыксындырды мине. А. Пушкинның «Бахчисарайский фонтан» («Бакчасарай фонтаны», 1937), «Полтава» (1937) поэмаларын, «Каменный гость» («Таш кунак», 1937) трагедиясен, Мольерның «Тартюф»ын (1937), Шекспирның Гамлет»ы белән «Король Лир»ын (1947), А. Грибоедовның «Горе от ума» «Акыллылык бәласе», 1947) комедиясен татар теленә ул тәрҗемә иттем әле мин..

Зиһен ягын ходай биргән
Гыйлем ягын мәдрәсә
Берүзендә әллә ничә
Институт ләбаса!...

Нәфис әдәбият өлкәсендәге иң зур уңышларым, мөгаен драматургия белән бәйледер. Әле революциягә кадәр үк сәхнә әсәрләре язуда каләм тибрәткәли идем, соңрак бу жанрга төп игътибары юнәлтеп  бер-бер артлы күренекле комедия, драма Һәм трагедияләрен иҗат иттем. Шулай итеп, утыздан артык сәхнә әсәре язылды.

Әйе, хезмәтемә хөкүмәт, халкым зур бәя бирде. Әдәбият, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәтләрем өчен Ленин ордены (1957), Хезмәт Кызыл Байрагы (1969), Халыклар Дуслыгы (1980) орденнары белән бүләкләндем һәм 1957 елда -Татарстан АССРның, ә 1959 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек булдым. 1968 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирделәр миңа.

Менә шулай, дустым. Кем микән ул Нәкый Исәнбәт дип утырмассыңдыр бит инде? Сөйләшү кызык булды синең белән. Иҗатка борын төртуче дустым, уңышлар телим сиңа! Менә шулай, белдең инде хәзер язучы хезмәтенең нинди икәнен!

## ТОРМЫШ, БУРАН, КЕШЕ

*Хафизова Регина, Әлмәт шәһәре 15 нче урта мәктәбенең*
*10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Красильникова Г.Г.*

Кышкы кичтә көчле буран,
Тәрәзәгә кагып сызгыра.
Ә мин уйга чумып басып торам,
Җылы өйнең тәрәз төбендә.

Көчле буран үз эшендә,
Кар көртләрен өя юлларга.
Ә кешеләр аңа бирешмичә,
Тагын эзләр сала буранга.

Тормыш мәшәкатен күмәм диеп,
Әй ашыга тышта, бу буран.
Ләкин кеше алны-артны күрми,
Мәшәкатькә таба борылган.

Тынды ахры буран, тынычланды.
Кар яктысы җирдә – ак пәрдә,
Әкияттәге төсле, тар сукмактан,
Тормыш дигәннәре агыла.

Тормыш, буран һәм дә кеше!
Берсен-берсе уза алмыйча,
Сабантуйдагыча куыша-куыша,
Көннәр, сәгатьләрне судай агыза.

## ҖӘННӘТ – ӘНИЛӘРНЕҢ АЯК АСТЫНДА

*Хәлиуллин Адел, Әлмәт шәһәре 17нче урта гомуми*
*белем бирү мәктәбенең 9нчы сыйныфы укучысы*
*Җитәкче: Кашипова Н.Җ.*

Күренекле педагог, мәгърифәтче, галим Ризаэтдин Фәхретдин тарафыннан әйтелгән әлеге гыйбарә күпләрне уйланырга мәҗбүр итәдер, минемчә.

Әни, әнкәй, инәй... Кеше өчен алтын – көмешләрдән дә кыйммәтле, үз җаныннан да кадерле, барлык изгелекләрдән дә изге сузләр - шушыдыр. Үз гомерендә адәм баласына бу сүзләрне ничәмә – ничә тапкыр кабатларга туры килә икән? Әмма күпме генә кабатламасын, әлеге сүзләрдән ул һич кенә дә туймый, киресенчә, еллар узган саен "әни" сүзенең тәмен ныграк тоеп яши. Күпме наз, күпме җан җылылыгы бу сүздә!

Әнкәйләр – безгә тормыш биргән гүзәл затлар. Һәр кеше өчен үз әнисе кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием - кадерлеләрнең дә кадерлесе. Барлык балаларныкы кебек, минем дә телем "әннә" сүзе белән ачылган. Әнием мине күкрәк сөтен имезеп үстергән, көннәрен дә, төннәрен дә миңа - газизенә багышлаган. Әнием – минем җан юлдашым, терәгем, киңәшчем, яклаучым һәм таянычым. Аллаһы Тәгалә тарафыннан эти булу бәхетенә ирешеп, үз сабыйларымны кеше итәр, күңел түремә әнием салган тәрбия җимешләренең куанычын татыр көннәрем алда әле минем. Шул көннәрдә дә янәшәмдә әниемнең булуын, аның кытыршы кулларының җылысын тоясым, "балакаем" дигән татлы сүзен ишетәсем, "әнием – бәгырем" дип өзелеп торасым килә. Учларыма әнием кулын алып мин ниндидер изге әйбергә кагылган кебек булам: минем җаным яктырып китә, тормыш аңлаешлы һәм гади булып тоела башлый, борчулар һәм хәсрәтләр онытыла. Янәшәмдә әнием булганга минем тормышым дәвам итә, киләчәгемнең яхшы һәм бәхетле булачагына ышанычым арта. Мин шуны яхшы аңлыйм: тормышта мин бәхетле икән, әнием дә чиксез бәхетле булачак, чөнки ана һәм баланы гомер азагына кадәр бәйләп торучы күзгә күренмәс җепләр бар. Шуның берсе генә кинәт өзелсә дә, бу ике кешенең яшәү мәгънәсе бетәчәк. Әниемне бәхетле итәр өчен кулдан килгән бөтен нәрсәне дә эшләргә ризамын, бары әниемнең күзләреннән шатлык чаткылары сүнмәсен дә, Ходай биргән гомерендә бала хәсрәте татырга язмасын иде.

Бүгенге көндә мәгънәсез сугышларда, тәртипсезлекләргә корылган Армия сафларында вафат булган сөлектәй ир – егетләребезнең, наркотик дигән афәттән котыла алмаганнарның, вәхши яшьтәшләре тарафыннан мыскылланып, җәберләнеп үтерелгән егет һәм кызларның газиз әниләренә сабырлыклар телим. Күпме сабый "әни" дигән кадерле сүзне әйтә алмыйча чит кешеләр гаиләсендә, я булмаса, балалар йортларында тилмерә. Үз әнием янәшәсендә менә шундый "күке" аналарның күп булуы да борчый мине. Килер бер көн, бу сабыйлар үсеп җитәрләр, үзләре тормыш корып җибәрерләр. Шул вакытта аларның бусагасында кайчандыр ташлап калдырган аналары пәйда булыр. Бу аналар балаларының күзләренә ничек карар да, үзләренең яшьлектәге гамәлләрен ничек аңлатыр икән? Бала күңеле ананы кичерерме?

Уйлансаң, уй җитәрлек. Мәрхәмәтсезлек тулы дөньяда яшибез, илебездә картлар йортлары артканнан арта. Гаиләдә 4-5 бала тәрбияләп үстергән аналарның да кайберләрен

шушы йортта күреп җан сыкрый. Төннәр буе бишек тирбәтеп, балам сәламәт, бәхетле булсын, җитеш тормышта яшәсен дип җан аткан ана үзенең картлар йортыннан соңгы юлга китәсен күз алдына да китермидер, мөгаен. Каян килә бу гамьсезлек? Әллә соң балаларының шундый булуында әниләр үзләре гаеплеме? Әллә үз балаларын бар нәрсәдән дә өстен куеп яратканга аларны Ходай шулай сыныймы? Сорауларга җавап табасы бар, дөньядагы ана хакы турында уйланасы бар. Инша исемендә китерелгән “Җәннәт – әниләрнең аяк астында” дигән юлларны һәр кешегә ишеттерәсе, аңына җиткерәсе бар.

Әй, кешеләр! Дөнья рәхәтлекләрен читкә куеп, җәннәт эзләп гомер итмәгез. Янәшәгездә газиз әнкәйләрегез булу, аларның җылы карашын, назын тою, татлы сүзен ишетү, менә шушыдыр – сезнең җәннәтегез. Әнкәйләрне олылагыз, яратыгыз, якты йөзегезне, игътибарыгызны кызганмагыз. Әнкәйләрегезне рәнҗетүдән, аларның рәнҗешләрен татудан сакланыгыз!

Язмасын ялгыз калырга
Тормыш шаулап торганда.
Әйләнә – тирә ягыңда
Кешеләр кайнаганда.
Беркайчан да онытмагыз
Алда Сират күпере.
Әниләр безне кичерер,
Тик Ходай кичерерме?
(Р.Низамова “Сират күпере)

## КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕННӘН

*Хәмәдишина Алсу, Мөслим районы Баек төпмәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Садриева Г. М.*

***

Менә тагын кышлар килде,
Бар дөнья акка төренде,
Гүя бөтен табигать
Энҗе-мәрҗән, көмеш киде.

Табигать юрган ябынган,
Яз килгәнче йокыга талган.
Кар-бураннар сыйпый анадай
Нарасыен бәпләп йоклаткандай

Килер бер көн, уяныр табигать,
Ял итеп, йоклап туйгач та.
Тынып калыр карлы бураннар да,
Язлар җитеп, җылысын өргәч.

## КЫШ

Учларыма кунды кар бөртеге,
Ялгыз калганмы әллә аерылып.
Күзләремне төбәп тордым аңа,
Эремәсен, эремәсен...

И, син, ялгыз бөртек!
Ни сәбәпле, аерылдың да кундың учыма.
Ялгыз калып, буран ясап булмый,
Ялгыз бөртек кар тавы да булмый, –
дип әйтәлми дә калдым,
Кар бөртеге шундук эреде.
Кышның суыгымы, эрегән бөртегеме
Тизләттеләр барган юлымны,
Әмма уем калды
Һәм бер фикер туды,
Ялгыз булу – җиңел түгеле.

## ФЕВРАЛЬ

Тышта салкын, нәкъ кышкыча.
Чыксаң, битне өшетә.
Киезләрне элдерттерә,
Җылыга йөгерттерә.
Кайчак давыл куптарып,
Буран дулата тышта.
Кайчак кояш каратып,
Тамчы тамдыра хәтта.

Әбиләр әйткәндәгечә,
Кышның чилләсе булыр.
Үзенчә матур "елмайган",
Үзе кул изәгән язга ,
Февральнең үзе булыр,
Тышта нәкъ кыштагыча…

## КҮҢЕЛ

Күңел бу ел никтер язны көтә,
Гөрләвекләр шаулап акканын.
Төркем-төркем булып кошлар кайтып,
Дөньяларны шауга күмгәнен.
Умырзая күзен ачканын,
Алмагачлар чәчәк атканын.
Күңел никтер язны көтә, ярсый...

## ХЫЯЛЛАРЫМ МИНЕМ КАНАТЛЫ

*Хәсаншин Айназ, Чирмешән районы  Иске Кади урта мәктәбе*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Муксинов Н.Ф.*

Хыялларым минем, канатлы син,
Төрле җирләргә алып барасың.
Шул хыялның матур мизгелендә,
Мәктәп елларына кайтасың.
Һәрвакытта хыялланып яшим,
Ул тормышның шатлык бизәге.
Ак канатым белән күктә очсам,

Кочармын мин төрле илләрне.
Хыялларым минем, канатлы син,
Очар кошлар кебек талпына.
Хыяларым биргән канатларым,
Уку йортларына талпына.
Хыялларым минем – канатларым,
Балачактан салган эзләрем.
Шул юлларда адашмаска теләп,
Мәктәп елларымны эзләрмен.
Хыялларым минем ап-ак канат,
Очар кошлар кебек талпына.
Ак канатым минем әле хәзер,
Туган мәктәбемә тартыла.

## ЗИРӘК ПЕСИ БАЛАСЫ

(әкият)

*Хөсәенова Гөлназ, Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Агмалова Э.Э.*

Элек-электән үк кешеләр бик тырыш, уңган булганнар. Шул тырышлыклары аркасында кешеләрнең уңышлары да бик күп булган, ди. Ләкин тычканнар уңышларына зыян китерергә ратканнар икән. Кешеләр ничек кенә тырышсалар да тычканнарны куып җибәрә алмаганнар. Шулай берзаман кешеләр ярдәм сорап эткә килгәннәр.

- Эт дус, тычканнар бит безнең уңышыбызга зыян салалар, булышчы безгә, - дип мөрәҗәгать иткәннәр.

Ничек тырышса да эт тычканнарны тота алмаган. Ярдәм сорап, башка җәнлекләргә дә мөрәҗәгать иткәннәр, ләкин алар да тычканнарны куып җибәрә алмаганнар.

Бервакыт песи үзенең ярдәмен тәкъдим иткән: "Әгәр сүз миңа өегездә торырга рөхсәт итсәгез, мин сезгә тычканнарны өйдән куып чыгарырга булышырмын" - дигән.

Кешеләр песигә ышанмаганнар, чөнки ул бик ялкау булган һәм бик тә тәмләп йокларга яраткан, ди. Бик күп уйлап киңәшкәннән соң, кешеләр песи баласын сынап карарга булганнар.

Шул көннән башлап, песи баласы кеше өендә яши башлаган, ди. Ул өйгә кергән дә тәмләп йокыга талган. Шулвакыт тычканнар песи баласы янында йөгереп йөри башлаганнар. Бервакыт песи баласы иң зур тычканны тотып алган да: "Мин сине ашыйм!", - дигән. Тычканнар куркудан песи баласыннан җибәрүен сорый башлаганнар. "Әгәр сез бу өйдән китәсез икән, мин сезне җибәрәм", - дигән песи баласы.

Шул көннән башлап тычканнар өйдән чыгып китәргә мәҗбүр булганнар. Песи баласы булган өйдә тычканнар булмаган. Шушы көннән башлап песи кеше өендә яши башлаган һәм кешеләрне дә сөендергән.

## ФИКЕРЛӘР ДӨНЬЯСЫ

*Хөсәинова Камилә, Әлмәт шәһәре 13нче урта мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гарипова А.Ш.*

Бер ерак шәһәрдә, үзәк урамда, бер агач үскән ди. Карап торышка, гади генә агач: кәүсә, ботаклар, яфраклар... Шулай да ул барыбер тылсымлы булган, чөнки аңарда төрле Фикерләр яшәгән: Акыллы, Яхшы, Усал, Юләр, Күңелле һәм Искиткеч Фикерләр урын алган.

Һәр иртә беренче кояш нурлары белән Фикерләр торалар, җыеналар һәм шәһәрдә яши торган кешеләр янына очалар икән. Һәр кешегә җитешкәннәр алар: гәҗит таратучыларга, табибларга, укытучыларга, төзүчеләргә, машина йөртүчеләргә... Алар укучылар янына да ашыкканнар. Хайваннарны да онытмыйлар икән Фикерләр: песи-этләргә, күктәге кошларга һәм елгадагы балыкларга килгәннәр. Менә шуңа күрә бөтен кешеләр һәм хайваннар иртән-иртүк төрле-төрле гамәлләр эшләгәннәр: кемдер акыллы, кемдер юләр, кемдер яхшы, кемдер усал гамәлләр кылганнар.

Фикерләрнең эшләре бик күп булган, ә эшләрнең күбесен Күңелле, Яхшы һәм Акыллы Фикерләр башкарган. Алар бөтенесенә дә җитешергә, берсен дә онытмаска тиеш булганнар. «Безнең шәһәрдә гел әйбәт һәм елмаеп торучы кешеләр булырга тиеш,» – диләр икән алар. Күңелле, Яхшы һәм Акыллы Фикерләр зур урамнар өстендә үзләренең зарарлы туганнарын - Усал, Юләр һәм Ямансу Фикерләрне куып йөриләр икән.

Бөркөнне Назир дигән тылсымчы бу шәһәргә кап-кара болытлар җибәргән. Шәһәрдә шул вакытта ук вакыт яңгыр ява башлаган, бөтен җир караңгыланган. Шәһәр кешеләре дә моңсуланып калганнар. Ә бу Назир шәһәрне үз кулына алырга килгән икән. Күңелсез кешеләр бик көчсез һәм минем белән сугыша алмаслар, дигән фикер белән болытлар җибәргән була ул. "Их, рәхәт, кешеләр хәзер көлә алмаслар," - дип Усал, Юләр һәм Ямансу Фикерләр уйлаганнар. Ә Күңелле, Яхшы һәм Акыллы Фикерләр мондый хәлгә карап елый гына алганнар. Ләкин начар Фикерләр юкка шатланганнар. Алар Искиткеч Фикер турында онытканнар. Искиткеч Фикер сирәк чыккан, ә бер чыкса, шәһәрдә могҗиза башлана торган булган.

Бу көнне Искиткеч Фикер шәһәрнең падишаһына килгән. Һәм падишаһ бөтен шәһәр кешеләре белән бәйрәм әзерләргә уйлаган. Кешеләр мондый яңалыкны ишеткәч, урамга чыкканнар һәм бергәләшеп җырлый, бии башлаганнар. Шул ук вакытта кешеләргә Күңелле, Яхшы һәм Акыллы Фикерләр килгән. Ә Усал, Юләр һәм Ямансу Фикерләр Назир белән бергә үпкәләп киткәннәр. Шулай шул, дөрес фикерләр могҗиза ясарга сәләтле алар...

## ОЗЫН ТОЛЫМЛЫ КЫЗЛАР ...

*Хөснетдинова Клара, Башкортостан Республикасы,*
*Бакалы районы Камышлытамак урта мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Яппарова Ф. З.*

Соңгы елларда халыкның туган жиренә, теленә, үткәненә, тарихына, мәдәниятенә игътибар көчәя бара. Бу үзгәреш һәр кешедә милләтнең традицияләренә мәхәббәт, ихтирам тәрбияләү ихтияҗын тудыра.

Халыкның буыннан-буынга күчеп килгән, соңгы вакытта югалып бара торган күңелле бәйрәмнәре, йолалары яңадан халкыбызда яшәсен, күңелләрдә уелып калсын өчен мәктәптә бәйрәмнәр уздырыла. Шул бәйрәмнәрнең берсен – «Озын толым» бәйгесен тәкъдим итәм. Ул озын толымга, татар кызларының матурлыгыңа, сафлыгына, тыйнаклыгына багышлана.

**Урман аланы күренеше. Аланда челтерәп чишмә ага.**

**Егет**: Татар кызы ...
Толым-толым үргән чәчкәйләрең,
Чылбыр-чылбыр артка салынган.
Җиргә җитсен өчен очларына
Талир тәңкәләре тагылган.
Аңлый белсәң, ул толымнар сөйли
Яхшы атлыгын татар кызының.
Татар кызларына алиәһәлек бирә

Шушы сихри чәчләр толымы.
Үстерегез матур толымнарны,
Чулпы белән чәчәләр үрегез!
«Озын толым» бәйрәме бит бездә –
Гүзәлләрне күреп китегез!

**Кыз**: Озындыр толымнарың.
Чулпыларың ялтырый.
Урамнардан узган чакта
Еракларга яңгырый.
Син ул – чын татар кызы,
Сокланырлык үзеңә!
Толымнарда гүзәллегең,
Кистерә генә күрмә!

**Егет**: Гомер-гомергә татар кызларының озын толымы матурлык, горурлык билгесе булган. Кемнәр генә сокланмаган озын толымлы татар кызына. Аны мактап җырлар җырланган, шигырьләр язылган.

**«Толым-толым чәчкәйләрең» җыры башкарыла. Кызлар сәхнәгә чыга.**

**Кыз**: Бәйгебезнең барышын бәяләп бару өчен жюри әгъзалары сайлап үтик. (Жюри сайлана)

**Егет**: Безнең бәйгебез берничә биремнән торачак һәм өй эшләрен тикшерү белән аралашып барачак.

**Кыз:** 1 бирем "Үзем турында"дип атала. Кызлар үзләре белән таныштырачаклар.

**Һәр кызны сәхнәгә чакырганда шигырь укыла.**

**Мәсәлән**:
Чәчләрегезне һәрвакыт
Жыегыз һәм тарагыз.
Матур прическалар белмәсәгез
Альбинадан сорагыз.
Чәчләрне матур йөртергә
Ул киңәшләр бирә ала.
Каршы алыгыз ул кызны
Киңәшчебез Диләрә.
Толым-толым чәчләреңдә
Ал чәчәкле такыя.
Ничек үрдең чәчләреңне
Безгә дә әйт, Алия.
Чәчләреңне тарап үрсәң,
Килешеп тора үзеңә.
Иринаның матурлыгы
Ташлана һәркем күзенә.
Озын толым чәчәләреңне
Матур итеп үрәсең.
Венерадагы чәчләрне
Тагын кайда күрәсең.
Тегеләй жыйсам, болай жыйсам,
Ничек булыр икән, –дип,
Галия һәркөн баш вата
Матур булачакмын, – дип.

**(Түгәрәк әгъзасы Закирова Рима шигырьләре)**

**Егет**: Кошлар җырына кушылып,
Без дә бер җырлыйк әле.

Дөнья мәшәкатьләрен
Онытып торыйк әле.
**Музыкаль пауза.**

**Кыз**: Бәйгебезнең 2 биреме «Калфагым да калфагым» дип атала. Калфак – ул төрки халыклар көнкүрешендә киң таралган баш киеме. Калфак – баш киеме буларак та, бизәнү әйберсе буларак та татар хатын-кызларының рухи
матурлыгын, күңел байлыгын, тегү-чигү эшенә осталыгын, зәвыгын чагылдырган сәнгать җәүһәре дә. Аның тарихы болгар чорына, хәтта аннан да элегрәк заманда кулланылган гади һәм йомшак баш киемнәренә барып тоташа.

**Кызлар үзләре чиккән калфакларын киеп, сәхнәдә көй агышына йөриләр.**

**Егет**: Тибрәт кенә керфегеңне
Жан дертли, күз камаша.
Чү, яшьлекнең, гүзәллекнең
Үзе бит син, ләбаса!
**Музыкаль пауза**.
**Кыз**: Алдагы биремебез “Уңган хужабикә” дип атала
Бәйгедә катнашучы һәр кыз үзе әзерләгән милли ризыкны сезгә тәкъдим итәчәк. Кызларыбыз бик уңганнар икән. Алар һәрберсе йөрәк җылысын биреп әзерләгән ризыкларының ничек әзерләнүен сезгә аңлатып китәчәкләр.

**Егет**:
Тыйнак та син,
Тырыш та син,
Батыр да син,
Матур да син.
Киң күңелле
Татар кызы.
Кояштан да иртә торып,
Жиң сызганып,
Зур эшләргә тотынасың
Оҗмах кызы.

**Музыкаль пауза**.

**Алтынчәч керә, сөйли**:
Биек тау итәкләрендә
Җиләк җыйганда
Ишеттем мин матур җыр
Толым турында.
Шул ялкынлы җырга таба
Ашкынды күңелем.
Үзегезне күрергә дип,
Бирегә килдем.
Исәнмесез, гүзәл кызлар, матур малайлар!

**Кыз:** Исәнме, Алтынчәч! Хуш киләсең! Синең белән очрашуга бик шатбыз. Без синең татар халкының горур, гүзәл, озын чәчле кызы икәнеңне беләбез. Безнең кызларыбыз да сиңа сокланып, сиңа ошарга теләп, матур
толымнар үстерәләр.

**Алтынчәч**: Дусларым, ә минем матур такыям бар. Әйдәгез әле, шуның белән
бергәләп уйнап алыйк.
Такыям гади түгел!
Аның шундый сере бар:
Кем кулына эләгә,

Жырлата да биетә,
Матур сүзләр сөйләтә.
**Балалар түгәрәккә басалар. Бию көенә тәкыяны бер-берсенең башына кидерәләр. Көй туктаганда такыя кемдә кала, шуңа җәза бирәләр.**

**Алтынчәч**: Дусларым! Сезгә карап сөендем, һөнәрләрегезне күреп, сокланып туя алмадым. Толымнарыгызда чыңлаган чулпыларыгыз сезне тагын да күркәмрәк күрсәтә, кызлар теләгем шул сезгә:
Кистермәгез, үстерегез
Матур озын толымнар...
Без татар кызлары диеп,
Чыңлатыгыз чулпылар!
Ә хәзер миңа китәргә вакыт житте, сезнең белән бик
күңелле булды. Ярар, дусларым, хушыгыз инде.

**Егет**: Кояш үбүе аңар биргән назлар,
Сезнең өчен генә килгән язлар.
Син аларны, зинһар, әрәм итмә,
Толымыңны кисмә, яме, кисмә!
**Музыкаль пауза.**

**Кыз**: Ә хәзер бәйгебезнең иң кызган өлешенә күчәбез. Безнең кызларыбызга иптәшләре матур прическалар ясап, алар безнең алдыбызга кичке күлмәкләрдә чыгачаклар.

**Егет**: Кызлар әзерләнгән арада бәйрәмгә чакырылган озын толымлы апалар чәч тәрбияләү серләрен ачачаклар.
**(Табигать шифаханәсе серләре)**

**Кыз**: Гөлгә тиң юк дисәм
Бакчы татар кызына
Буе-сыны зифа, йөзе күк йолдызы.
Эшләгән кулларында балкый кояш үзе.
Сокланыгыз, сокланганда
Күз тидерми генә.
Таудай бәхет, саф мәхәббәт
Юлдаш булсын аңа.
Үрнәк булсын эштә, лаек булсын санга,
Кайгы-хәсрәт кагылмыйча үтсен аңа!

**Егет**: Кызлар, сәхнәгә рәхим итегез!
**(Прическаларны бәяләү)**

**Кыз**: Татар кызы!
Сөбханалла, күз тимәсен
Озын толымнарыңа!
Бәхетле мизгелләр генә
Чыңлап гомер-гомергә
Торсын синең бизәкле
Көмеш тәңкәләреңдә!
Безнең “Озын толым” бәйгесе тәмамлана. Әйдәгез
кичәбезгә йомгак ясау өчен сүзне жюрига бирик.

**Жюри әгъзалары чыгышы. Котлаулар. Бүләкләү.**
**Дәртле көй яңгырый.**

## ХИСЛӘР ТАШКЫНЫ

*Цыплина Ангелина, Бөгелмә шәһәре 13нче урта мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче:Мортазина Л.Д*

Ап-ак кардан сине уйлап барам,
Як-ягымда моңсу каеннар,
Бир кулыңны диеп эндәшәләр,
Безнең  зарны диеп кем тыңлар.
Ап-ак кардан сине уйлап  барам,
Күңелемдә хисләр йомгагы.
Салкын карга  кайнар яшьләр тама,
Күңелемдә язлар ташкыны.
Ап-ак кардан эзләреңне  эзлим,
Сикәлтәле тормыш юллары,
Баскан җиргә  күптән карлар кунган
Без аеры бүген  аеры…
Юк шул, бәгърем, күпме эзләсәм дә,
Юктыр  тиңнәр  якты дөньяда.
Эзләреңне карлар капласа да,
Хис  бураны тынмый  һаман да.
Ап-ак кардан сине эзләп барам,
Менә таптым, менә синеке…
Кара мәрмәр салкын кабер ташы,
Кеше гомереңнең башымы син, әллә ахыры.

## ҖЫР – ШАТЛЫКТАН, ҖЫР – КАЙГЫДАН

*Шакирова Гөлфинә, КФУның Алабуга  институты студент*
*Җитәкче: Нуриева А.Р.*

Җанны бер бушатканчы елыйсы иде. Күз яшьләренә тыгылып, буылып йөрим, тик елап кына булмый. Бер бушансам, җиңеләеп китәр иде. Мөлдерәмә күңел савытым, чайкалыпмы чайкала, тик кырларыннан һаман ташып чыга алмый. Тик мин бик яхшы аңлыйм, кем дә булса саксыз кагылса, шундук ургып чыгачаклар алар, язгы ташкын төсле булып, тирә-якны басачаклар. Язгы ташкынны еш кына карарарга, аның көченә сокланырга дип карарга төшәләр. Боздә кайчандыр эти, әни, мин су буен басулардан төшкән ташкынны карарга төшә идек, кечкенә генә инешебез кырларыннан ташып чыга иде, ул үзен шул вакытта мөган зур елга кебек хис иткәндер, бәхетле мизгелләр кичергән, шул форсаттан файдаланып иске генә, агачтан ясалган, күп кенә басмалары инде какшаган күперне ул шул тупланган көчен күрсәтеп, ургып-ургып ага иде. Нинди сокландыргыч мизгелләр! Елына бер генә була, кайбер елларда кар аз яуган булу сәбәпле язгы ташкынны күрергә насыйп та булмый кала.

Минем яшь ташкыны, алай сокландыргыч түгел шул, киресенчә. Миңа соклану түгел таяныч кирәк, авыр вакытта ярдәм кулын суза алучы, мине читкә какмыйча, үз канаты астына алучы кирәк. Кечкенә чакта сиңа очар канат булып ата-ана тора, үскән саен алар урынын синең сөйгән кешең ала. Шуннан сез очар бәхет кошының берегез бер каната, икенчегез икенче канаты булып, тормыш дигән дәрьяга чумасыз. Шул кош кеби, бәхетле чакта очып кына йөрисез, кирәк чакта йөзеп китәсез, авырлыклар килгәндә, җәяүгә каласыз. Шул-шул, чын мәгънәдә бәхетле булыр өчен, кирәк вакытта очарга, йөзергә, җәяү дә йөрергә кирәк, һәркайсының үз урыны үз вакыты бар.

Тик нишләмәк кирәк, әгәр очар канатың сынса, җәяү йөрергә аякларың хәрәкәттән баш тартса, кая барырга, нишләргә, әгәр сине тормыш бер урынга гомерлеккә бәйләп куйса, сине хәрәкәт итү ирегенннән мәхрүм итсә. Кеше кулларына калып яшәргә дучар итсә. Нишләргә?

Ни сәбәптәндер кешенең иң курыккан уй-фикерләре тормышка аша. “Кеше кулларына калырга язмасын, Ходаем” – дип теләгән кеше, кеше кулына кала, аларның күзләренә карап ятарга мәҗбүр була. Нәрсә бу, ачы язмышмы, тормыш шаяртуымы. Нәрсә? Тормыш дигәннәрең гел ал да гөл түгел шул ул, бер алдын күрсәтә, ике артын күрсәтә. Үзебезгә килгән бәхетне без еш кына аңламый калабыз, аны бәхеткә санамыйбыз, күз күнеккәнияләшелгән була, шулай булырга тиеш кебек кенә карыйбыз. Югыйсә, кечкенә генә авырлык туса без шундук чаң кагабыз, тормышым җимерелә, башка яшисем килми дибез. Үзебезнең өстән төшерер өчен, еш кына кемнәрдәндер гаеп эзлибез һәм аны табабыз. Ни генә дисәң дә, бәхет ул чагыштырмача төшенчә, төрле кеше аны төрлечә аңлый, төрлечә кабул итә, ни хикмәт бу төшенчәне күпләр матди әйберләр белән бәйләп карыйлар.

Сиңа бәхет өчен нәрсә җитми дисәң? Минем яңа күлмәк аласым килә, аның янына яңа туфли белән сумка да кирәк әле, ди. Икенчесе күптәннән машина алырга җыенам, яки машинаны алыштырасы бар иде, монысыннан туйдым инде, ди. Тагын әллә ниләр диләр, тик шунысы ачык күренә, бу кешеләргә күлмәк тә, машина да түгел, акча җитми. Аларны тыңлаган башка берәү, бу кеше болай да бәхетле, туеп сикергән бу, симергән дияргә мөмкин, чөнки аның үзенең алыштырырга машинасы түгел, өстәлендә ашарга бер сынык икмәге дә булмаска мөмкин. Өстәлдә икмәк булу аның өчен бәхет санала.

Авыру кеше булса ул, һичшиксез, бәхет – сәламәт булуда, дөньяның бөтен байлыгын бирер иде шуны кире кайтарырга дигән теләктә. Тик бөтен авыруга да дәва юк шул, берәүләрнең санаулы гына көне, я сәгате калып килергә мөмкин. Башкаларның якты дөньядан якын кешеләре: ата-аналары, балалары, туганнары китеп барырга мөмкин, аларны югалткач кына, ни кадәр кадерле булганын аңлый башлыйсын, тик соң була шул инде, соң.

Шулай итеп, чагыштырулар дөньяны аңларга ярдәм итә, килгән бәхетне дә, авырлыкны да чагыштырып карыйсың. Әле җитмәсә, авырлыклар турында “минем хәлем синекеннән күпкә авыррак” диябез. Шатлык. сөенеч була калса, “карале бу бит миннән бәхетлерәк, бәхет дигәннәрең ишелеп кенә килгән моңа”, диләр. Ничек тә үзләре кызганычрак булып калалар.

Тик, еш кына тышкы елмаю аша кешенең күңелендә нинди авыр таш ятканын, нинди газаплар кичергәнен белми калалар. Берәүнең дә бурасы буш тормый. Чынлап торып авырлыкка дучар булган кеше, чат саен аның турын да кычкырып йөрми, ә киресенчә сабыр булырга тырыша.

Вакыт күбесен онытырга ярдәм итә, вакыт – дәва, диләр. Тик күп нәрсә безнең кодрәттән килми шул, язмыш безнең белән гел үзе теләгәнчә идарә итә. Онытырга теләгәнне оныта алмый интегәбез, баштан һич тә чыгарып ата алмыйбыз, я киресенчә искә төшерә алмыйча баш катырабыз. Сиңа эшләгән яхшылык онытыла, үзең эшләгәнне гел тукып торасың, янәсе онытмасыннар, менә мин нинди, күрдегезме!

Минем тормыш та май белән балдан гына тормый, еш кына абынырыга, яңадан торып китәргә, ярадан тамган канны кысып бәйләп, тешне кысып, елмаеп алга атларга туры килә. Килгән авырлыкны кешегә күрсәтмә, дошманнарың сөенмәсен диләрме әле. Мөгаен шуңадыр да мин авырлыкларга ничек тә түзәргә, аларны үзем чишәргә, ерып чыгып булмаса, сөзеп чыгарга тырышам. Кешеләргә ярдәм сорап барырга ашыкмыйм, үз кайгымны үзем кичерәм, башка төшкән авырлыкны үзем күтәрәм.

Тик, вакытында сыгылмасаң сынуың да бар шул, тулы савытка бер тамчы төшсә, ул кырларына ташып чыга башлый, бер кечкенә авырлык та сиңа шул соңгы тамчы булырга мөмкин. Күрәмсең, минем күңелем савыты тулган булгандыр, менә ул чайпалды-чайпалды да түгелеп китте, күздән ачы яшьләр бәреп чыкты. Нишлисең бит, шул вакыт ана кеше моны

күреп тора. “Елама кызым. Түзәргә кирәк, авырлыклар күп була ул, бирешмәскә, көчле булырга кирәк”, – ди.

Тик күпме көчле булып була ул, аның чиге кайда, нинди үлчәмнәр белән үлчәнә ул, аны үлчәрдәй герләр бармы дөньяда? Кайчан бетә алар? Кайда аларның чиге? Ерактагы горизонт кебек кенә түгелме ул. Менә-менә килеп җиттем дигән саен ерагаймыймы ул бәхет дигәнең.

Туйдым, ардым көчле булудан! Минем дә елыйсым килә, миңа да башымны иңнәренә куя алырдай кеше кирәк, миңа шатлыкны гына уртаклашучы түгел, кайгымны, авырлыгымны да бүлешер кеше кирәк. Нигә мин генә кешегә ярдәм итәргә тиеш, нигә миннән көтәләр ул ярдәмне, мин бит үзем мохтаҗ аңа, суда батучы коткару көткән кебек, мин дә көтәм, ә мин бит йөзә белмим.

Кеше үз гомерен елап та, җырлап та уткәрә дияр идем мин, чөнки кеше шатлыктан да, кайгыдан да елый. Теле белән булмаса күңеле белән җырлый. Җыр аша яралы җанына дәва таба, күңелен бушата. Менә мин дә шулай, авырлыкны җырлап үткәрәм:

“Уңга карасаң да юк, сулга карасаң да юк.
Уңга карап, сулга карап утырып еласаң да юк.”

Бу арада бу минем яраткан җырларымның берсе, еш кына, үзем дә сизмстән, шушы җырны көйлим. Шуннан әни әйтте дә инде: “бу әбиеңнең яраткан җыры иде, башына төшкән авырлыкларга түзә алмыйча, шушы җырны җырлый-җырлый елый иде бичаракаем”, – диде. Авырлык килгәндә, ярдәм кулын сузар кешесе булмаган, кайсы тарафка гына караса да ялгыз башы үз хәсрәте белән, үз утында янган. Менә бит ничек, язмыш диген, икебезгә бер җыр, икебезгә бер юаныч, әби генә юк янда, авырлыклар исә чиктән ашкан, очы-кыры юк. Ничә буын кешесен бер-берсе белән тоташтыручы, күңел юанычы җыр. Бу җырны аеруча яратып әни җырлый:

“Баланны өзәләр бит,
Җепләргә тезәләр бит.
Ятып елар чаклар бик күп була –
Үзәкне өзәләр бит.
Колакта чыңлый һаман,
Эндәшә кебек әнкәм:
“Авыр чаклар бик күп булыр –
Түзәргә кирәк, балам...”

Бигрәк тә соңгы шушы ике юлын еш кабатларга ярата әнкәй. Мин дә әнинең шушы җырын кабатлыйм, тешемне кысып түзәм. Балан ачысына түзеп булса да, тормыш ачысына теш кысып кына түзеп калып булмый шул, сынмас өчен сыгылырга туры килә, елап күңелне бушатырга, җырлап күңелне ачарга.

## МИН-АВЫЛ БАЛАСЫ
**(хикәя)**

*Шакирова Мәдинә, Мөслим районы Баек төп мәктәбенең*
*9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Латыйпова Л.Т.*

Мин Дусай авылында тудым. Сабый чагымда челтерәп аккан чишмә тавышын, талларга кунып сайраган сандугач тавышын да ишеттем,йолдызлы күкне, тулган айны күреп сокландым. Безнең авылның табигате искиткеч матур.Мин, капка төбебезгә чыгу белән, үземне яшел хәтфә җәелгән җиргә баскан кебек хис итәм. Бәбкә үләннәре, вак ромашкалар, сары чәчәкләр үзләре үк мине бер сихри дөньяга алып кереп китәләр. Үзем яшел чирәмнән атлыйм, күзләрем тирә-якны күзәтә. Әнә якында гына боргаланып инеш ага. Җәй көннәрендә анда каз-үрдәк тавышлары ишетелә. Инеш буенда таллар үсә. Алар яз көне аксыл-яшел төскә

керәләр, җәй башында яшел яфракларга төренеп, авылга ямь бирәләр, кичләрен кошларның матур тавышлары бөтен су буен җанландыра. Авыл башына чыгуга, зифа каеннар яфракларын шаулатып, сары алкаларын селкетеп, безне каршы алалар. Бу каеннарны кайчандыр безнең бабаларыбыз утырткан. Читкә киткән кешеләр үз авылы каеннарын сагыналар.

Ак каеннар азмы далаларда,
Япандагы олы юлларда.
Бер кайда юк, ләкин сезнен сыман,
Сагындырган каен-беркайда!

Зифа каеннардан соң киң кырлар башлана. Бу кырларда игеннәр күкрәп үсә. Авылдан ерак түгел урманнар бар. Урманны бөтен кеше дә ярата торгандыр дип уйлыйм мин. Җәй көне урман кешеләрне үзенә тарта. Җәй уртасында урман аланнарында чалгы тавышлары ишетелә, ә көз көне кешеләрне үзенең сап-сары чикләвекләре белән сөендерә.

Туган ягым гүзәл дә, аның кешеләре дә минем күңелемә якын.Бүген мин авылда яшим, мәктәптә укыйм. Теләгем мәктәпне бик яхшы билгеләргә генә тәмамлап укуымны дәвам итү. Кая гына барсам да, туган ягым, әти-әни йорты миңа якын да, газиз дә булыр! Үземнең туган ягыма булган ярату хисләремне,үзебезнең авылда туып үскән шагыйрә Лилия апа Садриеваның шигыре аша әйтеп тәмамлыйсым килә:

Сезнең туган авылыгызда
Салкын чишмәләр бармы?
Чишмә буйларын ямьләп
Каен үсәме, талмы?
Туган авылыгызда сезнең
Алма бакчасы бармы?
Алмалары тәмлеме?
Җете кызылмы, алмы?
Бездәгедәй киң күңелле,
Юмартмы сездә халык?
Килегез безгә кунакка
Китәрсез сез таң калып
Менә шундый минем авылым
Аңлата алдыммы барын?
Тик мин үзем шуны беләм
Юк башка мондый авыл!

**КОЯШ,ҺАВА ҺӘМ СУ**

(әкият)

*Шәйхулова Алсу, Әлмәт муниципаль районы “Яңа Кәшер санатор интернат – мәктәбе” 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Шәйхулова Г. Ф.*

Борын-борын заманда, әле без тумаганда җир йөзендә караңгылык, салкынлык, корылык хакимлек иткән. Бар тереклек тә бу яшәү рәвеше белән килешкәндәй, үз җайларына гына яшәп ятканнар. Үсәсе әйберләр тиешенчә үсә алмаган, кыска гомерле булганнар. Галәм моңсу гына ялгызы бар дөнья белән хакимлек иткән. Ялгызлык, һаман бертөрлелек, җир өстендәге яшәешне алып барырга көче җитмәү галәмне тәмам ялыктырган. Бервакыт ул җылы җил искәнен тойган һәм бу анда зур кызыксыну уяткан.

- Кайдан килде мондый җылылык, яктылык? – дигән ул җитез җил кызына.

- Әнә теге утрау ягыннан, - дип җавап биргән аңа җил кызы. Ул утрауда шундый сөйкемле, шундый якты бер кыз яши. Ләкин ул бик оялчан, кыюсыз. Шуның аркасында күк йөзенә күтәрелергә дә ояла, - дип сөйләп биргән җил галәмгә.

Галәм хуҗасы исә үз чиратында җилгә әлеге кызны үз янына эндәшергә кушкан. Җил бу хәбәрне әлеге җылы, яктылык таратучы кызга җиткергән. Әлеге кыз, бик итәгатьле генә итеп үзенең ризалыгын белдергән. Әмма биеккәрәк күтәрелергә кыюлыгы җитеп бетми икән. Шулай итеп ул күк йөзенә үк күтәрелеп җитмәгән, тирә-ягындагы тереклекне генә үзенең җылы, шифалы нурлары белән иркәләгән. Ә җир йөзендәге яшеллек, үсемлекләр аңа таба күтәрелгәннәр, аның җылы нурларына таба сузылганнар һәм алар көн дә аның чыгуын зур түземсезлек белән көтә башлаганнар.

Көн тугач кына чыкканга аны "көн" дип атарга булган бер-иш үсемлекләр, ә икенчеләре ул безгә яшәргә көч тә бирә бит әле дип "яшәү" дип атауны кулай күргәннәр. Ике як бер фикергә килеп, ике сүзнең дә берәр өлешен алып "кояш" дип атарга булганнар. Әле аңа карата җыр да чыгарганнар:

Яктылык, нур сибә
Яшәргә көч бирә,
Шифалы нурлары
Гөл-чәчәк үстерә.
Бар дөнья тартыла
Шул җылы, яктыга
Яшәсен, көч бирсен,
Без моңа шат кына.

Шатланып көтәбез,
Һәр көн таң атуын
Җылы нурлары белән
Безне яратуын.

Чәчәкләр, үсемлекләр көн дә шушы җырны җырлап кояшны каршы алалар. Ул киткәндә боегып калалар, ди. Кояш үзенә булган җылы карашны тоеп сөенгән һәм көн дә бервакытта күккә күтәрелә башлаган. Ә бар тереклекнең кояшны күргән саен тормышны, дөньяны ратулары артканнан-арта барган. Чәчәкләр кояшның җылы, шифалы нурларында коенганнар, алар тирәсендә бөҗәкләр тыз-быз йөгерешеп йөргәннәр. Кояш үзенең алтынсу керфекләре белән әллә кайларга, еракка-еракка сирпелеп, елгалар, күлләр өстендә, калтырап һәм дерелдәп үзенең нурларын биеткән. Ләкин вакыт-вакыт ул җылысын ныграк та сибә икән, хәтта аның кайнарлыгы үсемлекләрне, яшеллекне көйдерү дәрәҗәсенә җиткән ди. Кояш та, бар тереклек тә моңа бик борчылганнар. Җил, галәм, кояш бөтенесе бергә киңәшеп, нәрсә эшләргә кирәклеген уйлый башлаганнар. Җитез, тиз йөри торган җил тирә-якта сулыклар, елгалар барлыгын әйткән. Тик ул суны бар җиргә дә ничек итеп сибәргә соң? Әлбәттә инде моның өчен бердәмлек кирәк. Бергәләп эшләгәндә генә алар корылыкны җиңә алачакларына төшенгәннәр. Җил үзенең көчле куллары белән йөгерек дулкыннарны тибрәткән, кояш тагын да биеккәрәк күтәрелеп, галәм хуҗасы белән икесе әлеге дулкыннарны үзләренә тарта башлаганнар, ә су үз чиратында парга әйләнеп күккә күтәрелгән. Эшләренең барып чыгуына сөенә-сөенә, тиз генә әлеге су парларына йомшак мендәр-ястыклар әзерләгәннәр. Әлеге мендәр-ястыкларны ясау өчен җил үзенең җитезлеген, күк йөзе зәңгәрлеген, кояш кайнарлыгын биргән, ләкин кайберләренә аның җылысы җитми калган, ди. Хәзер алар алдында тагын бер бурыч, бу су парларын җиргә яудыру бурычы килеп баскан. Җил үзенең бар улларын-кызларын чакырып, әлеге су парлары тутырылган мендәр-ястыкларны бер-берсенә бәрдерергә кушкан. Алар шулай эшләгәннәр дә. Менә могҗиза! Тамчы-тамчы булып җир өстенә су коела. Җылы, шифалы су тамчылары. Ул көне бу су тамчылары бер дә тынмый, җиргә көмеш уклар кебек ява да ява. Дым тирәнгә үтеп, җирдә тузан бетә. Бар табигать яшәреп китә. Ул да булмый ялт итеп кояш күренеп китә, ул бу хозурлыкка сөенә-сөенә, үз артыннан бик озын тасма суза. Ә җирдәге чәчәкләр рәхмәт

йөзеннән әлеге тасмага үзләренең матур төсләрен җил кызы аркылы биреп җибәрәләр. Җил кызы әлеге төсләрне бер-бер артлы чиратлаштырып, бик матур итеп күпер сала.

Күктән су тамчылары яуганда бар җирдә шатлыклы авазлар яңгырап тора икән. Су тамчылары җиргә төшкәндә бар дөнья яңгырап торганлыктан «яңгырау» сүзеннән чыгып, бу күренешне яңгыр дип атаганнар. Аңа карата бик матур җыр да чыгарганнар.

Яңгыр, яңгыр, яу син, яу
Синдә шифа, куәт бар
Тамчыларың дару кебек,
Сине көтә бар тереклек.

Көтә сине кешеләр дә,
Көтә сине агачлар да,
Челтер-челтер чишмәләр дә
Матур сайрар кошлар да.

Галәм хуҗасы һаман исемсез икән. Аның кояш белән җилне, яңгырны бергә туплап, дуслаштырып үзенең киңлекләрендә аларга урын тапкан өчен олылап, хөрмәт итеп һава дип атаганнар.

Кояш, җил, һава, яңгыр бар дөньяга ямь керткәннәр. Һәркайсының үз эше, үз вазифасы бар. Алар үзләренә йөкләнгән бар эшләрне дә җиренә җиткереп тиешенчә башкарганнар. Тик менә кешеләрнең табигатькә карата булган салкын карашы аларның ачуын китерә икән. Шуңа күрә, вакыт-вакыт табигать безне үзенең давыллары, яшенле яңгырлары белән куркытып та куя. Бу вакытта инде җиргә кешеләрнең табигатькә карата эшләгән явызлыкларына нәфрәтләнгән болытлардан ява икән яңгыр.

## СӘГЫЙТЬНЕҢ УЙЛАНУЛАРЫ

*Шәкурова Гөлназ, КФУның Алабуга институты студенты*
*Җитәкче: Галләмов Ф.Г.*

Горизонтны кояшның алсу нурлары каплады. Тиздән караңгы төшәр дә күк йөзендә янә алтын бөртекләр сикерешә башлар. Бу вакытта Сәгыйть өстәл артында Әбелмәних хәзрәтнең “Тәрҗемәи Хаҗи Әбелмәних” китабын укып утырыр. Әби, Коръәнне укый-укый арып, мич артында йокыга киткән булыр.

Тынлык. Лампаның кечкенә генә пыскып утырган уты Сәгыйтьне уйланырга мәҗбүр итә. Утны сүндермәс өчен аңа керосин өстәп торырга кирәк, алайса ул сүнәр. Ул китабын читкә куйды да уйга калды. Барыргамы аңа Бохарага? Ул аңа нәрсә бирәчәк? (Китсә дә ул инде Урта Азиягә китүчеләр белән, Каргалы аша китәр.) Күптән түгел генә яңа китап чыгаралар дигән хәбәр таралган иде, бер хәзрәт үзенең чит илләрдә күргәннәрен язган, имеш. Бу китап Сәгыйтьне кызыксындырды, кайчан гына ул аның кулына килеп эләгер икән? Беләсе иде бит, ничек икән ул чит илдәге тормыш? Безнең авылларда да тормыш бара, әлбәттә, ләкин изелү астында яшәү кемгә ошый. Барысы да мулла булып, аштан ашка йөрсә, һичшиксез, җиңелрәк булыр иде. Әмма гади кешеләрнең наданлыгын ничек бетерергә? Сорау арты сорау... Муллалар да хәзер икенче, Екатерина 2нченең Дииния нәзарәте төзегәннән соң, указ алганнарны гына мулла итеп куя башладылар. Указ алды да мулла булды ди, ләкин указлы мулла – ул чын мулла дигән сүз түгел әле. Университет та яхшы гына эшләп килә, Аллага шөкер. Яңа гимназия ачылу да безгә файдага, эх, татар, төрек, рус телләрендә яңа китаплар да булса иде! Күпме белем бирер идек, без хәлфәләр, чит илләрдә үзебезнең белемнәргә куллану эзләп йөрмәс идек. Салихҗан Кукляшев, Ибраһим Хәлфиннәр татарлар өчен күпме көрәшкәннәр, дәреслекләр, сүзлекләр төзегәннәр. Эх, бер генә күрешеп

сөйләшергә иде бит Әбелмәних агай, яисә Шәмсетдин Зәки, Габделҗаппар Кандалый, Һибатулла Салихов кебек кешеләр белән! Кичләрен әби шигырьләр укый иде безгә, мин шундый кызыга идем ул шагыйрьләргә, алар кебек татарлар өчен көрәшәсем, үз хисләремне шигырь юлларына саласым килә иде... Төн уртасы. Хәзер инде хәлфә үзенең лампасын сүндерер, сүнгән лампа белән аның уйлары да шушы дүрт стена эчендә сүнеп калыр кебек.

Бисмилләһ-иррахман-иррәхим. Көнем хәерле, файда белән үтсен. Өйдә берсе дә күренми, йоклап калмагае әле. Әби күптән инде торып намазын укыган, чәй кайнатадыр. Эх,тәмле дә соң сөтләп ясалган татар чәе! Бал белән булса тагын да күңеллерәк. Чәй кайнатыр өчен самауырны бар кешләр дә ала алмый, аны чутлы гына чит җирләрдән алып киләләр иде. Чәен дә саклап кына тотыш. Кытайдан Оренбургка кайтаралар, Оренбургтан сәүдәгәрләр аны безгә җиткерә. Сәүдәгәрләрдән урыслар чәй эчми дигән сүз ишеткәнем бар иде, нәрсә эчә микән соң алар, ачы бал, кымызмы? Замана икенче хәзер, чит илләрдә әллә нинди яңа нәрсәләр бар. Барысын да татып карыйсы килә шул. Менә китәм дә Бохарага, чәен дә эчәрмен, китаплар да укырмын.

– Сәгыйть, улым, намазыңны укыдыңмы, әйдә чәйләп алыйк.

– Хәерле иртә әби, укыдым. Син бигрәк өлгер инде, каян барысына да җитешәсең.. Мин кичә Бохарага юл тотарга уйладым.

Самоварыннан чәй агызган әбием миңа кинәт кенә уйчан караш ташлады.

– Анда сиңа ни калган? Белем артыннан куасыңмы һаман?

– Әби, минем чит җирләрне күрәсем килә, монда уку җитми миңа, китаплар да аз, газета, журналларны да чыгарырга рөхсәт бирмиләр әле дә.

– Мин сиңа каршы килә алмыйм, улым, Аллаһ тәгалә белем алырга кушкан, хәерлегә булсын.

Мин чәемне бер йотым йоттым да әти миңа бер хикәят сөйләп куйды:

– Бер вакыт мулла абзыең ашап утыра, ди, кинәт бисмилләсен әйтергә онытканын сизгән дә кире бисмиллә әйтеп ашый башлаган, ди, кырында утырган пәйгамбәр көлә башлаган, ди . Ник көләсең дип сорагач, пәйгамбәр әйткән: “Әнә, мулла ашый башлагач, аның авызына бер шайтан килеп утырган иде, бимилләсен әйткәч, егылып төште өстәл астына”.

Каршыма китереп куйган хуш исле чәй, җитмәсә кабып куйган бер калак татлы бал мине каядыр еракка алып китте. Бохара турында икән уйларым.

– Амин, рәхмәт, әбием, – дидем дә камзул белән кәләпүшемне элэктереп (чабатамны да онытмадым) тышка чыгып киттем. Атларга су эчерәсе бар. Нинди гүзәл көн. Яңа туган август һавасы күңелләрне күтәреп җибәрде. Күпме генә яшәсәм дә яратып, сокланып туймасмын мин. Авылымның бормалы урамнары, чишмә буенда кояш баюлары ни генә тора. Күпме генә көмеш бирсәләр дә алыштырмас идем мин аны. Эх, ма. Челтерәп аккан чишмәгә суга дип килгән идем шул, тиз генә әйләнеп өйгә кайтырмын дигән идем...Көянтәләрен аскан кызлар чишмәгә таба юнәлгәннәр. Мин дә аларга иярдем.

– Кызлар, әй, кызлар, миңа да чишмә суы эчерәсезме?

Оялып, яулык очлары белән алсу битләрен каплаган булалар. Чибәр дә инде үзләре... Чишмә суы чиста, чиләктә бу барлыгын сизүе дә авыр, кайчак су алдыммы соң мин юкмы дип шикләнеп карап куйган буласың. Уйлар башны бутый, нәрсә эшләгәнеңне дә онытасың кайчак. Алмачуарымның да кәефе яхшы бүген, мин янына килү белән сәлам, хуҗа, дигән кебек кешнәп куйды. Алмачуаркаем. Ул булмаса ничек итеп без бу эшләрне эшләп бетерер идек икән? Аларсыз тормыш алып барып булмый. Юк, дустым. Нәрсәне генә алсак та, сугышмы, бакчамы, хуҗалык эшеме, чит җиргә барумы атлар кеше белән бергә. Бергә яши, бергә эшли. Атымның ялын сыйпап куйдым. Коерыгы белән сыртына кунган чебеннәрне куалый, мышный-мышный бер чиләк суны эчеп бетерде, малкаем. Бохарага баруны уйларга кирәк... күрше Галим абзый үткән җомга намазына барганда, сине дә ияртермен Бохарага дигән иде, шуның янына кереп чыгарга уйладым. Күрше булгач эндәшмичә генә ишек

алдына кердем, куе яшел бәбкә үләне арасында сары чебешләр йөри, алар янында анасы кеткелди. Бания апа да күренми, атларының тәртәләре монда, димәк, өйдә булырга тиеш болар. Тәрәзә янынарак китеп, Сәгыйть абый, дип кычкырып җибәрдем, минем тавышка теге кечкенә йомры чебешләр тынып калдылар. Әү, күрше, дип, башындагы кәләпүшен рәтләп, Галим абый да килеп чыкты.

– Әссәламегаләйкем, Галим абый.

– Үәгаләйкемәссәлам,энекәш, хәлләрегез шөкер генәдер?

– Рәхмәт, күрше, Аллаһка шөкер. Исеңдәме Бохарага барам дигән идең, мине дә алырсың микән?

Галим абый бераз кыенсынып куйган төсле булды.

– Шулай килеп чыкты бит әле, энекәш, көзгә таба өйдә эшләр күбәя, гаиләне ташлап чыгып китеп булмас, язга таба барырга уйладым мин. Ләкин беләсеңме безнең дус Габденнасыйр шул якка юл тота. Гадәттә ул бездә туктала иде. Икенче кич атнада килеп җитәргә тиеш ул. Шулар белән китсәң ничек булыр икән?

– Ярар, Галим абый, килсенннәр, эшдәшерсең миңа, – дидем дә, күрше белән кул кысышып өйгә кереп киттем.

Габденнасыр абый килер көн килеп җитте, иртәдән үк әйберләремне, китап, кульъязмаларымны җыеп куйдым. Атны эчергәндә, күрше ишегалдына күз салдым, берсе дә күренми иде. Көн буе борчылып, уйланып утырдым. Кичен әбием өйгә тиз-тиз атлап керде дә: “Килделәр,”– дип, миңа эндәште. Килделәр. Менә ул иртәгә иртән юлга чыгачак... Киләсе көнне иртәнге намаздан соң күрше мине чакырып китерде, әби белән саубуллаштым да олы юлга чыгып киттем. Юллар, юллар. Уйларга мәҗбүр итәләр...

## САБАК АЛУ

*Шәрипова Алинә, Алабуга районы Иске Юраш урта*
*мәктәбенең10нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Юнусова Л.М.*

Катнашучылар:
Алмаз – 4 нче сыйныф
Самат – 4 нчесыйныф
Фәрештә - мифологик зат
Шайтан – мифологик зат

Мәктәп. 4 нче сыйныфларның кабинеты. Парта, урындыклар, укытучы өстәле. Кинәт бөтен җир нурга күмелә. Фәрештә керә. Ул ап-ак киемнән, йөзендә елмаю.

Ф ә р е ш т ә*( җиңел адымнар белән кабинет буйлап әйләнеп йөри, кулында гөл).* Кая куйым микән?*(Сокланып.)*Бу гөлдән нинди матурлык, нинди сафлык бөркелә.*(Залга карап.*) Әле минем белем учагының эченә үк кергән юк иде. Менә монда инде мин бөтен хыялларымны тормышка ашырачакмын. Бөтен балалар әйбәт укыячак, тәртипле булачак. Имтиханнарын да яхшы билгеләргә генә бирәчәкләр. Мин һәр баланы әкрен-әкрен генә үз артымнан ияртәчәкмен. *(Сөенеп, әйләнеп ала.)* Дөнья, нинди матур син!

Кинәт бөтен җир караңгылана. Шатырдаган тавышлар ишетелә. Фәрештә куркып китә.Шайтан керә. Ук кара киемнән. Бер кулыбелән мөгезен тоткан, икенчесе белән койрыгын.

Ф ә р е ш т ә *(куркып).* Син? Син? Син ничек мине таптың?

Ш а й т а н (*җиңүле кыяфәт белән күкрәк кага, үкерә).* Мин бөтен нәрсәне дә беләм: аскы, өске дөньяда ниләр барын да, виртуаль дөньяны да, телефоннарны да. Кайсы баланың күпме вакыт компьютерда уйнаганы да - барысы да минем менә монда язылган язылган. *(Горур гына мөгезенә күрсәтә.)*
Ф ә р е ш т ә (*ачынып).* Мин бөтен мәгълүматны яшердем. Аны беркем күрергә тиеш түгел иде.
Ш а й т а н Син күбрәк яхшы хәбәрләр белән эш итәсең. Ә мин - начарлары белән. Менә миңа бу мәктәптә начар укучылар, эти-әниләрен тыңламаучылар ялкаулар бар, диделәр. Һәм миңа бөтен ишекләр үзләре ачылды. Хәтта син куйган “код” белән дә чиләнәсе булмады.
Ф ә р е ш т ә. Юк, юк, Шайтан, алар үзгәрәчәкләр. Мин аларга булышачакмын.
Ш а й т а н. Син үзең дә беләсең: кеше үзе яхшы якка үзгәрергә теләсә генә, бу шулай булачак.Ә мин аларга гел: “Тыңлама, эшләмә”,- дип әйтеп торачакмын.
Ф ә р е ш т ә (*ачынып).*Алар үскәч нишләрләр? Алар начар укыгач, беркая эшкә дә урнаша алмаячаклар, һөнәрләре дә булмаячак. Аңлыйсыңмы?
Ш а й т а н. Әйе, нәкъ менә шулай. Ә алар үзләре гаепле. Әти-әниләренең, укытучыларның сүзен тыңламыйлар. Ә миңа шул гына кирәк тә. Мин аларны аннан соң батырачакмын.*(Куллары белән күрсәтә, сөенеп, кулларын ышкый.)* Әле мин тагын бер сихер өйрәнәм: тыңлаусыз балалар миннән башка яши алмаячаклар. Ә компьютерда озаклап утыручылар минем колыма әйләнәчәкләр. Мин компьютер эченә керәчәкменһәм...*( Куркыныч кыяфәт белән йөренә.)*
Ф ә р е ш т ә. Зинһар, тукта. (*Борчылып, башын тота. Тавышлар ишетелә.)*Ой! Кемнәрдер килә.

Фәрештә белән Шайтан качалар. Укучы киеменнән Алмаз беләнСамат керә, портфель тотканнар. Саматның киемнәре эленке-салынкы, Алмаз бик пөхтә киенгән.

А л м а з. Ләлә апа апа сиңа булышырга кушты. Математикадан эшләдеңме?
С а м а т. Сиңа кушканнар бит. Син эшлә.Туйдырдыгыз инде, өйдә әти-әни, монда Ләлә апа, хәзер син.
А л м а з. “2”ле була бит, Самат. Нишләрсең соң син, утырып калсаң?
С а м а т. Әле уку елы башланды гына. Менә компьютердагы барлык уеннарны уйнап бетерәм дә укый башлыйм. *(Шайтан сөенә.)*
А л м а з. Самат, әйдә математикадан өйрәтәм.
С а м а т. Ярый, хәзер.
Ш а й т а н *( читтән генә пышылдый)* Юк, өйрәнәсе килми, калдыр мине. Ләлә апага ярарга тырышасыңмы?
С а м а тЮк, өйрәнәсе килми, калдыр мине.Апага ярарга тырышасыңмы?
А л м а з (*үпкәләп).* Тагын нигә киреләнәсең?
Ш а й т а н *( пышылдый).* Бәйләнмә.
С а м а т. Бәйләнмә.

Шайтан арттагорургынайөри. Малайларанықүрми. Алмаз кулын селти дә китә.Шайтан Фәрештәгә, ике кулын сузып, куып җибәрү хәрәкәтләре ясый. Фәрештә юкка чыга. Саматның каршында Шайтан пәйда була. Самат курка.

Самат. Кем син?
Ш а й т а н. Мин синең дустың. Укырга теләмәүче балаларны бик-бик яратам. Әйдә, минем белән компьютерда уйнарсың.
Самат. Юк, мин синнән куркам. Ләлә апа безгә чит кешеләргә ышанмаска кушты. Аннан соң син кешегә дә ошамагансың. Мөгезең, койрыгың бар. Мин куркам. *(Елый башлый.)*

Ш а й т а н*(ачуы белән*). Бигрәк җебек малай булдың әле. *(Йомшак итеп.)* Әйдә, мин сиңа нәрсә соң әле? Ә-ә-ә, кәнфи-и-ит бирәм.
С а м а т. Юк-ла, кирәкми. Ләлә апа чит кешедән әйбер алырга кушмый.*(Елый.)*
Ш а й т а н*( үзалдына).* Нишләргә моның белән? *(Пышылдап.*) Синең белән китәм, диген. Әпсен-төпсен, минемчә булсын!
С а м а т. Ю-ю-к.
Ш а й т а н. Нәрсә булды соң бу сихергә? Ә-ә, хәзер, дөреслибез аны.*(Мөгезен рәтләп куя.*) Ләлә апаңны да, әти-әниеңне дә тыңлама. Әйбәт түгел алар.
С а м а т*(елап).* Юк, алар бик әйбәт. Мин аларны бүгеннән тыңлый башлыйм.
Ш а й т а н*(ачуы белән үкереп).*У-ух, кире малай! *(Үзенә.)*Эш барып чыкмый бит. Дөрес сөйләшмәдем, ахрысы. Белемне күтәрергә кирәк, белемне. Психологка барам. Хәзер үк.*(Юкка чыга.)*

Самат аптырап басып тора. Елмаеп Фәрештә керә. Саматны кулыннан җитәкли.
*Пәрдә*

## БӘХЕТ

*Шәрипова Гөлүсә, БДУның Стәрлетамак филиалы 3 курс студенты*
*Җитәкче: Габбасова Г.З.*

Нәрсә соң ул Бәхет? – дигән сорау
Күпмеләрне инде һаман борчый.
Һәкем аны үзенчә аңлый,
Һәммәсе дә үзенчә фикерли.

Ә сезнеңчә, нәрсә соң ул Бәхет?
Әйтсәгезче, зинһар, нәрсә ул?..
Әйтерсез сез, Бәхет бит ул, диеп –
Бай тормышта гомер кичерү.

Ә минемчә, Бәхет, исән-имин булу,
Сырхауларсыз тормыш, көн күрү.
Һәр көн иртән яхшы кәеф белән
Туган таңны, көнне сәламләү.

Әгәр өйдә көтеп торса сине
Сөйгән ярың, якын кешең.
Буладыр ул менә шушы
Үзе иң зур Бәхет.

Ә мин саныйм тагын Бәхет диеп,
Булса әгәр сиеныр почмагың,
Җылы ашың, көтеп торган гаиләң,
Якын туганнарың, тугры дустың.

Мин Бәхетсез, димә беркайчан да,
Ничек кенә авыр булса да!
Җибәрелгән сиңа бу шартлар
Сиңа бит ул бары сынаулар.

Һич төшермә күңелеңне
Менә алмасаң Карпат тауларга.
Зөһрә йолдыз, Ай һәм Кояш, диеп
Ашкынма син әллә кайларга.

Кирәк түгел сиңа Бәхет өчен
Диңгез төбендәге энҗеләр.
Шөкер итеп бар булган өчен
Кирәк җирдә яшәүләр.

## ТУГАН ЯГЫМ

Туган якны сагынуларым
Тынгы бирми җаныма.
Бары төшләремдә генә
Кайтамын авылыма.

Тәрәз каршында
Керфеген какмый,
Әнкәем минем
Көтәдер анда.

Язлар җиткәндә,
Кайтырмын әле.
Яшел күлмәкле
Таллар янына.

## ШИГЫРЬ ЯЗАМ

Күңелләрем тулган чакта,
Җылы кояш чыккан якка
Утырам да тәрәзәгә карап
Шигырь язам...

Язам шигырь: туган якны,
Әткәй-әнкәй торган якны,
Әби-бабай булган якны
Мактап зурлап.

Мактап, зурлап, яратам, дип
Сагынам, дип, туган якны.
Саргаям, дип, карап торып,
Кошлар кайткан туган якны.
Язам шигырь.

Язам шигырь:
Кошлар кайткан туган якка!
Бар да монда. Сандугач та!
Моңлы көен суза
Бакчамдагы алмагачта.

## ТУКАЙ!

*Шәяхмәтова Миләүшә, Мөслим районы Салавыз-Мухан төп
белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы
Җитәкче: Латыйпова Г. Х.*

Тукай!Тукай!
Безнең күңелләрдә
Син һаманда әле яшисең.
Ихлас язган шигырьләрең белән
Туган телне гүзәл бизисең.
Һәрбер язган шигъри юлда синең,
Тирән мәгънә ята күмелеп,
Мавыктыргыч әкиятләрең исә,
Күңелләргә бирә сөенеч.
Шигырьләрең синең безгә маяк,
Яктырталалр барыр юлларда.
Синең көчле шәхес булганлыгың,
Арта бара һәрбер елларда.
Туган телне, илне сөяргә дип,
Өйрәтәсең күпме буынны.
Синең кебек шундый зур шәхесләр
Бизәсеннәр иде дөньяны.
Яшә, Тукай, шулай җанландырып,
Алга әйдәп татар милләтен.
Син яшәсәң, без дә тырышырбыз
Кайгыртырга милләт киләчәген.

## БӘЙРӘМ ҖИТСӘ...

Бәйрәм җитсә,  рәхәт миңа:
Бар да көлә шаяра.
Шат көлүдән йөзләребез
Нур кебек балкып тора.
Бәйрәм җитсә, мул табыннар
Әзерләргә торабыз.
Ә аннары җан-фәрманга
Кунаклар каршылыйбыз.
Дуслар белән кунелле дә,
Бергә утырулары.
Якыннар белән бергәләп,
Бер жырлап алулары.
Шулай бит ул, бәйрәм көнне
Бөтен халык ял итә.
Кумәкләшеп бии, жырлый,
Тагын бәйрәмнәр көтә.

## КОШЛАР КАЙТА ТУГАН ЯГЫМА

Туган җиргә шатлык таратып,
Кошлар кайта туган ягыма.
Канатларын җилпеп-җилпеп,
Ашкыналар тизрәк яныма.
Үзләренә матур оя табып,

Җырлар суза туган якларга.
Шушы җыры, шушы моңы өчен
Аларны бит кирәк якларга.

## МУСА ҖӘЛИЛ – МИНЕМ ГЕРОЕМ

Муса Җәлил бөек, данлы кеше
Гомре буе балкып яшәгән.
Сугыштагы олы батыр эше
Аңа мәңге яшәү китергән.
Аның шигырьләре сихри дөнья
Терелтәләр үлгән кешене,
Шифалы су булып барып җитеп
Сүндерәләр янган йөрәкне.
Сугыш кырын горур атлап үткән
Муса Җәлил – минем героем.
Яу кырында аның язган шигырьләре
Яктырталар илне көн саен.
Туган илен яклап алга барган
Муса Җәлил – минем героем.
Татар халкы аңа мең рәхмәтле
Саклаганы өчен татар милләтен.
Муса Җәлил – батыр шагыйрь
Безнен герой бабабыз.
Тарихта да, әдәбиятта да
Балкып янучы йолдыз.

## ГОРУР ШАГЫЙРЬ – МУСА ЖӘЛИЛ!

*Шигаепова Алинә, Мөслим районы Салавыз-Мухан төп*
*белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Латыйпова Г. Х.*

Горур шагыйрь – батыр татар улы,
Исемнәрең  яңгырый  куңелдә,
Муса Җәлил кебек  туры сүзле
Бармы тагын туган илемдә?
Күпме авырлыклар күргән,
Кыска гына гомре эчендә.
Иле, халкы өчен хәтта җанын
Койган шагыйрь Герман җирендә.
"Иленне сат?!"– дип "ялынганнар",
Зыян салмаган ул халкына.
Башын горур тотып, сатылмаган,
Тугры калган биргән антына.
Шуңа бүген Муса исемен
Йөртә бик күп бистә, урамнар,
Шигырьләре яңгырый җыр булып,
Һәйкәлләре бизи мәйданнар.
Рәхмәт, сиңа, бөек татар улы,
Рәсемең каршында мин баш иям.
Бик яратып шигырьләреңне укыйм
Һәйкәлеңә чәчәкләр илтәм.

## КАЗ БӘБКӘСЕ

Каз бәбкәсе чирәмдә
Сары. йомшак, кечкенә,
Нидер җирдә селкенә.
Бу бит безнең күршекәйнең,
Каз бәбкәсе чирәмдә.
Тизрәк сикереп торды да,
Алпан-тилпән атлады.
Як-ягына каранып,
Нидер эзли башлады.
Әнә, әнә күр әле
Киерелде, җилпенде,
Вак-вак атлап, сөенеп,
Әнкәсенә йөгерде.

## УКЫТУЧЫМА

Укытучы булу өчен
Зур сабырлык кирәктер.
Алар кебек тырыш булу
Безнең олы теләктер.
Иртән алар кабул итте,
Кичен зурлап озатты.
Күңелебез тулган чакта,
Әнкәй кебек юатты.
Алар һәрчак үрнәк булды,
Һәр эштә, һәркайда.
Сәхнәдә дә иң булганнар,
Калышмыйлар спортта да.

## ТИМУРГА НӘРСӘ БУЛГАН?

(хикәя)

*Шикаева Мария, Норлат шәһәре “4 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең*
*9 сыйныф укучысы*
*Җитәкчеләр: Мостафина Н.К., Тямаева Г.С.*

Кушаматсыз гына яшәүчеләр сирәктер бу дөньяда. Җае гына чыксын, сорап тормый гына тагалар да куялар аны. Һәм мәңге котылам димә. Үпкәлә, гарьлән, кимсен – башкаларның соңыннан анда бер эше дә юк.

Мин дә башкалардан ерак китмәгән, үзара гына әйтелә торган кушаматым бар...

Ялгышмасам, 5 нче сыйныфлар иде, бугай. Татар әдәбияты дәресе. Язгы як күрәсең, чөнки күңел, уйлар белән инде урамда йөргән чак. Шуңа күрә күзләр дә, кайчакларда, дәрес вакытында онытылып, шул якка карап катып калган вакытлар.

Нәкъ шундый көннәрнең берсендә булды бу хәл. “Эх, хәзер җепшек кенә карны учыңа алып, аны карда аунатa-аунатa кар бабай ...” дип уйлап бетерергә өлгермәдем Гөлсем Камиловна:

- Тимур, бу портретка кара әле, анда сурәтләнгән язучының күзләрендә нәрсә күрәсең? – дип тиз генә дәрескә кайтарып, урыныма утыртты.

Мин торып бастым да, хыял аралаш иптәшем сөйләгәннәрдән истә калганны кабатлый башладым:

- Ул уйчан, күңелсез, моңсу, борчулы..., - дим.

Укытучым минем белән килеште дә:

- Игътибарыңны читкә юнәлтмә, - диде.

Кая инде ул?! Башымны иеп ризалаштым да утырдым. Тик тәрәзәнең икенче ягындагы күзне камаштырган кар, шаян кояш үзенә карата гына бит!

Юк, болай булмас, укытучы апа нәрсә диде? Нинди әсәр өйрәнәбез, ди? Әллә Нәҗип ди инде?! Минем әтинең дә абыйсы – Нәҗип. Тик ул бер дә әсәрдәге койма башында йөргән малайга ошамаган. Үтереп көләсе килә... Зур гәүдәле, озын буйлы, тик бик җитди минем Нәҗип абыемның өй кыегына менеп утыруын күз алдына китерсәң...

Күз шул ук минутта мәктәпне урап алган коймага, аның каршында тезелеп киткән өйләнең кыегына төште.

“Булды, хәзер эләгә синең, Дускай!” дип, бөтен көчемне җыеп тәрәзәдән күземне алырмын гына дигән идем, кечкенә генә кар суыннан ясалган күлләвектә коенып утыручы күгәрченне күрдем. Аның матурлыгын күрсәгез! Канатларына эләгеп калган кар тамчылары кагынып җибәрүгә төрле якларга очып китә. Кошчык үзе, салкын булса да, шул суда коенып чистара алуына шатланадыр кебек иде.

Мин тәрәзә аша урамда барган хәлләрне күзәтеп, уйларга чумып утырган арада дәреснең ахыры да якынлашкан. Укытучы, дәрескә йомгак ясап, сораулар бирә. Мин аларны ишетәм, тик ... тик күңел коенып туя алмаган күргәрчендә.

“Әгәр мин дә кош булсам, шул...” дип кенә өлгердем, таралган уемны җыярга булышкандай, “гөрес” дигән тавыш айнытып җибәрде. Бу, кызулык белән очып килеп, тәрәзәне күрмичә, анарга килеп бәрелүче карга булып чыкты. Тагын уйлар урамда. Күгәрчен инде онытылды. Хәзер уйда бары карга. Ничек икән ул анда? Яраланмадымы икән? Очып китә алдымы икән?..

Шул уйлар эченнән сирәк кенә укытучының сораулары ишетелгәли.

- Ул нинди бәлага дучар була, нәрсә була аның белән?

Бүлмәдә балалар гөрләшә, кул күтәреп җавап бирергә атлыга. Гөлсем апа Гөлгенәне тыңлый.

- Ул үз тормышында бик зур сынаулар кичерә. Тормышының чәчәк аткан чагында ул бик зур бәхетсезлеккә юлыга — паралич сугып, ике аягы да йөрмәс була.

“Йөрмәс була”... Бу сүзләр минем йөрәгемне кисеп үттеләр. Күз алдыма бер читән, бер койма башында йөрүче малай, бер абыем килеп басты.

- Ничек? Ничек инде йөрмәс була? Коймадан егылып төшәме, әллә өй кыегыннанмы? – дип сикереп торып сораганымны сизми дә калдым.

Сыйныфта тып-тын иде. Иптәшләрем бер миңа, бер укытучыга карап тора бирделәр. Укытучы бу хәлне күреп:

- Тимур, нинди койма, нинди өй кыегы, акыллым? Ул бәхетсезлеккә юлыга һәм паралич сугып йөрмәс була, - диде.

Мин әле дә бу яшь, шук малайны кызганудан аңыма килмичә:

- Аннары, аннары нәрсә була Нәҗип белән? - дидем.

Бу юлы инде сыйныфташларым да, укытучы апа да түзмәделәр, кычкырып көлеп җибәрделәр. Ул вакытта мине уңайсыз хәлдән кыңгырау тавышы коткарып калды. Мин, соңгы дәресебез булганга, тиз генә җыендым да өйгә таба йөгердем. Кайта-кайта очраган коймаларны, өй кыекларын карап кайттым. Үзем, башкаларның бу хәлдән көлүләре турында уйладым, аларны аңламадым. Аннары гына, кайтуга китапны алып, хикәяне, автор турында укыгач кына – үзем дә кычкырып көлеп җибәрдем. Алар минем Нәҗибем түгел, ә Фатих Әмирханның авыр язмышы турында сөйләгәннәр икән.

Икенче көнне мәктәпкә бардым. Үземнең игътибарсызлыгым аркасында оятка калуымны беләм, тик сиздермим. Калганнар бу хәлне эзсез генә калдырмадылар. Шул көннән башлап мине сыйныфташларым үзара Нәҗип Әмирханов дип өйртә башладылар.

## ТӨЛКЕНЕ ДУСЛЫК ҖИҢГӘН

(әкият)

Борын-борын заманнарда яшәгән ди, булган ди бер тиен. Ул урманның иң караңгы, иң куркыныч җирендә торган ди. Шуңа күрәме, әллә кечкенә булгангамы, аның дуслары аз булган. Бер көнне тиен болынга барырга җыенган. Андагы матур чәчәкләрне иснисе килгән. Әмма барыннан да күбрәк аның болында булган җәнлекләр белән танышасы килгән.

Менә бер матур көнне тиен болынга китте. Анда ул матур-матур аллы-гөлле чәчәкләр күрде. Шунда аның күзе бер елап утырган куян кызына төште.

- Нигә елыйсың? – диде.

Куян әйтте:

- Минем өйгә төлке керде һәм мине ашыйм, - диде. Ә мин чаптып да чаптым.

Тиен әйтә:

- Борчылма, без аны өеңнән куып чыгарырбыз.

Бер өч көнләп куян кызы тиендә кунды.

Менә дүртенче көнне тиен әйтте:

- Әйдә куян, төлкене өеңнән куып чыгарыйк, - диде.

Куян уйга батты, моны күреп тиен:

- Әйдә, аю абзый белән киңәшеп карыйк.

Менә куян һәм тиен аю абзый янына килделәр.

- Аю абзый, аю абзый, - дип кычкырдылар. Ул чыкты.

- Нәрсә кирәк сезгә, эшемнән бүлдереп йөрисез. Тизрәк әйтегез, нәрсә булды? – диде.

Тиен әйтте:

- Куянның өенә төлке кергән һәм аны ашарга теләгән, шуңа күрә куян качып киткән, төлке анда яшәп калган.

- Ә... Аңладым мин сезне, - диде аю. – Сез төлкене куянның өеннән куып чыгармакчы буласыз, ләкин куып чыгара алмыйсыз. Әйдәгез сон бергә барыйк, нигә куянкайны кыерсыта ул?!

Алар бергәләп төлке янына юл тоттылар. Барып җитү белән ишеккә шакыдылар. Ишекне ачучы кеше булмады. Тагын шакыдылар.

- Ач, ишекне! – дип бер әйтүе булды аюның, ишекләр ачылды.

- Нәрсә кирәк сиңа аю абзый? - диде.

- Миңа син кирәк, төлке дус!

Төлке гаҗәпләнеп:

- Минем нигә кирәгем чыкты, аю абзый?

- Син нигә куянны өеннән куып чырдың һәм аның өенә хуҗа булдың? Аны яклар кеше булмас диденме?!

Төлке югалып калды.

- Ни, бит... куян үзе...
- Яхшы чакта китеп кал, куян һәм аның өе янында эзең дә булмасын!

Төлке бер куянның куркудан калтырап торган йөзенә, бер каршында торган аюга күз ташлады да, артына да кармыйча, куе урман эченә йөгереп кереп китеп һәм күздән югалды.

- Ярдәм кирәккәндә мин һәрвакыт әзер! - диде аю.

- Мине зур бәладән коткарганың өчен бик зур рәхмәт, аю абзый. Сина да рәхмәт, тиен дус, - диде куян һәм шатлыгыннан өй тирәли йөгереп йөри башлады.

Бу сүзләрне ишеткән тиен бик шатланды. “Димәк, минем дә монда дусларым бар, мин алар янында ялгыз түгел,” дип уйлады тиен.

- Үзеңә рәхмәт, куян дус. Аю абзый, сиңа да рәхмәт. Сез булганга, Дус булганга рәхмәт сезгә.

Шул көннән башлап аю, куян һәм тиен якын дуслар булып, авыр вакытларында берберсенә булышып, шатлыкларын бергә бүлешеп тату гына яши башлаганнар. Тиеннең өендә дә, караңгы урманда булса да,  еш кына кунак булганнар. Бу дуслыкны күреп, башка хайваннар да алар белән дуслашырга теләгән. “Дуслыкта, бердәмлектә - көч!” дип юкка гына әйтмәгәннәр шул.

## БЕЗНЕҢ ТУГАН ТЕЛЕБЕЗ

*Якупова Диләрә, Алабуга шәһәре  2 нче гимназиясенең*
*10 нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Мостаева В.М.*

“И, безнең туган телебез,” –
Уйлап куям кайчакта.
Сине йөрәкләрдә саклыйбыз,
Мәңге якын булырсың миңа.

Сине дошманнардан саклыймын,
Айлы төннәрен йоклый алмыйча.
Изге телем, синең белән оныталмыймын,
Дөрес юлын тапмыйча.

Күңелемдә минем күп уйлар,
Сөйләп бетерерлек түгел.
Яраткан телемнең матур сүзләре,
Сезне генә көтә күңел.

Әй, Ходаем, мең-мең рәхәт,
Анам телемдә сөйләшкәндә.
Минем йөрәгемә биргән ул мәхәббәт,
Син минем телем, син минем күңелемдә.

## ОХШАШ ЯЗМЫШ

*Якупова Ләйсән, Казан шәһәре 62нче урта мәктәбенең*
*9нчы сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Гарәфетдинова А.Р.*

– Тагын 5 кенә минут, әнием – диде Хафизә әнисенә, әйтерсең, ниндидер 5 минут йокысы килүен басар да, шушы вакыт аңа нидер бирер. Тик әнкәсе инде болай да, җәлләп, 10 минутка соңарып уятты кызын. Шуңа да, мәктәпкә соңга калуын теләмичә, берничә мәртәбә килеп, “балам, тор”, дип кабатлады.

Эх, иртүк торып утырасылары! Уянуга, “кичә нигә иртәрәк ятмадым инде?!” дигән сүзләр белән үз-үзеңне тиргәп, “булды, бүген 9дан да калмыйм”, диеп, үзеңә үзең сүз биргән буласың, ахыр чиктә ул 5 минут йокы һаман җитми, һаман иң татлы йокы булып кала бирә.

Кояшын да әйтер идем инде... Әнинең килеп шапылдата-шапылдата сөюе, биттән үбүе һәм назлы сүзләр белән торырга әйдәве генә җитми, кояш та, үз вакытын белеп, төгәл Хафизәгә торыр чак җитү белән, аның бүлмә тәрәзәсе каршында туктала да, үзенең җылы нурларын туп-туры Хафизәнең нәни йөзенә юнәлтә, күзләрен чагылдыра, шаян елмая һәм шул 5 минутлык йокыны да тәмам качырып бетерә.

Әнисе бүләк иткән 10 минут кичтән барлап куйган китаплар өчен дип саналса, ә кояшның иркәләвенә сарыф ителгән 5 минутны каян аласы?! “Ярар, бер көн зарядка ясамаудан әллә ни булмас”, дип юатырга кереште кыз үзен.

– Нинди хәл инде бу, Хафизә? Сиңа дип пешергән йомырка тәбәсе суынып бетергә дә өлгергәндер.

Әнисенең күрше бүлмәдән кычкырган шушы сүзләре “ничек тә торырга” дигәнне аңлатты, чөнки аның өчен генә пешерелгән иртәнге ашны суыту, ашамый калдыру 10нчы сыйныфка күчкән Хафизәнең әнисенә карата хөрмәте булмау турында сөйли. Ничек кенә булмасын, яшьтән үк атасыз калган кыз бала бар булганына: сулаган һавасы, туар таңнары, ашаган ризыгы һәм кигән киеме өчен бердәнбер газиз кешесе – әнкәсенә рәхмәтле.

Әтисе турында сораша башлаганда, әни кеше азсүзләнә иде, шуңа күрә, юньләп бернәрсә белмәгәнгә, аңламаганга, кыз әлеге көнгә кадәр бу турыда ачык кына берни әйтә дә, уйлый да алмады. Әнисе дөреслекне ачып бирүне кирәк дип тапмагач, Хафизә дә, төпченеп, очы-кырыена чыгып, сорашып тормады. Ни өчендер бу Хафизәгә 4 яшь тулганнан бирле шулай булып килде. “Синең әтиең эчкече, әнкәңне кыйнап яшәгән, хыянәт иткән” кебек сүзләрне дә ишетмәде түгел кыз, әмма әнисе аңа гел әйтә килде, янәсе “кешене билгесезлек борчый, шуңа да җыен тузга язмаган сүзләр кычкырып йөриләр, игътибар итмә, кызым”. Ничек игътибар итмисең ди?! Әнисенең нидер яшереп йөрүе генә җитмәгән, башкалардан йөрәккә ук булып кадалырдай сүзләр ишетү һичничек игътибарсыз кала алмый.

Күпме генә бу сүзләрне тыңларга, аларның хак булуына ышанасы килми йөрсә дә, әнисе бу ел кызының кисәктән генә үсеп китүе, инде төпле фикер йөртеп, бала-чага булудан туктавын күреп, ничәмә-ничә еллар буена әйтелмәгән, уртага салып сөйләшенмәгән теманы үзе үк кузгатып, йөрәк парәсенә барысын да җиңел генә сөйләп бирде. Күңелсез чынбарлык шушы җиңеллек белән кызына күптән булып узган гадәти бер вакыйга гына булып ирешер күк тоелды аңа. Тоелды... Шулай шул, тоелды гына...

Инде менә атна-ун көн Хафизә әнисе сөйләгәннәрне башыннан һич кенә дә алып ата алмый йөрде. Һәр әйтелгән сүз кызның баш миендә кассета лентасына язылган сыман сакланып куелган һәм кат-кат сүзгә-сүз кабатланып килде. Кич ятса, тиз генә йоклап китә алмады, берәр эшкә тотынса, бу уйлар тагын тынгы бирмәде, иртән күзләрен дә, янә бар да башта кайный башлаудан куркып, озак ачасы килми ятты. Менә бүген дә нәкъ шушы хәл кабатланды. Ашавы ашау, эчүе эчү булмады, әле ярый бердәнбер аңлаучысы һәм ничек тә ярдәм итүчесе бар. Ул да булса йокы. Әкияти, сихри, матур дөньяга алып кереп китә иде ул Хафизәне. Тик бу рәхәтлек дәвам итүгә әлеге дә баягы я будильник, я әни тавышы, я кояш юл куймады.

Суынып бетә язган чәен аннан-моннан эчеп, җәһәт кенә киенде дә, бусагада көтеп торган букчасын уңайга эләктереп, Хафизә мәктәпкә юл тотты. Соңгы арада әнкәсе кызын озатып калудан туктады. Аның каравы, кыз анасын аңлый иде: күңелдә инде онытылып, күмелеп калган тирән хатирәләрне яңарту, барын бәйнә-бәйнә сөйләп бирү җиңел түгел. Сөйләгәндә бер күз яшен түкмәде ана, кызына да, үзенә дә авыр булыр дип курыкты, Хафизәнең күзләренә дә карарга оялган кебек тоелды. Тик сөйләшү тәмам булганнан соң, кечкенә якка чыгып, күз яшьләренә буыла-буыла елады. Әле дә, баласын күрүе була, тамагына төер тыгыла. Шуңа күрә 10 көн бер-берсеннән качып йөрергә туры килде аларга.

Мәктәбенә дә бармас иде дә бит, күрмәс иде шул кайчандыр ышанырга теләмичә, әмма дә ләкин хәзер ышанырга туры килгән сүзләрне сөйләп йөрүчеләрне, оныттым гына дигәндә, уйларны яңартучыларны. Үзендә көч табып, Хафизә мәктәпкә бармый калырга ярамаганлыкны аңлады, дәресләр вакытында да һаман актив булып утырды, шуның белән яман уйлар таралыр дип уйлады ул. Икенче яктан мәхәббәте дә аңа бертөрле көч, дәрт биреп торды. Чөнки бер сыйныф югары укыган Нәфис Хафизәне чын сөю белән, ихлас яратты, терәк булып килде, үз мәхәббәте өчен барына да әзер торды. Әйе, Хафизәгә кызыгып йөрүчеләр аз түгел иде шул. Андый акыллы, күз явын алырлык чибәр, тырыш, тәрбияле кызга гашыйк булмаучылар бармак белән генә санарлык иде. Шуңа да егет үзенекен итте, кечкенәдән үк, кайчандыр барыбер аныкы буласын белеп, Хафизәсе янына берәүне дә

китермәде. Кыз да эченнән генә гыйшык тотып йөрде. Ә быел менә күпләрне көнләштерерлек, күпләр кызыгырлык яшь пар барлыкка килде.

...Беренче сентябрь көне иде бу. Егет кызның танылмас дәрәҗәдә үзгәрүен, үсеп, тагы да матураеп китүен күрү белән, бер мәлгә авызын ачып, әйтергә теләгән фикерен әйтә алмый сүзсез калды. Гомердә булмаган хәл: Нәфиснең аяклары йөрмәс булып, атларга кыен иде, авызы кипкән, күзләре шардай, башта чуаланып беткән төенчек.

Менә егет аның каршында басып тора, менә аларның карашлары очраша. Кыз, ягымлы гына елмаеп, Нәфиснең ни әйтергә теләгәнен сизеп, сабыргына көтеп торды. Ниһаять, егетнең авызыннан “сәлам”, дигән бердәнбер сүз яңгырады. Хафизә югалып калды, онытылып, исәнләшергә кирәк икәнлекне дә башыннан чыгарды. Бар да башкачарак килеп чыгар дип өметләнгән иде лә ул... Ә егет, кызның тирән карашына әсирләнеп, пәрәвезгә буталып калган чебен кук, бер җирдә тыпырчына бирде. Үзалдына тырышып-тырышып нидер мыгырданды да, ахыр чиктә бирелде. Мәхәббәт ятьмәсенә килеп капкан “чебен”не “үрмәкүч” кызганган итте, җавапка хәйләкәр елмаеп китеп тә барды. Ай оялды Нәфис шул чак! Кайчандыр аның юлында торган егетләр дә бирөдә иде бит, барысын ап-ачык күреп тордылар, кайсылары хәтта аннан кычкырып көлергә дә җөрьәт итте. Әмма Хафизәнең мәхәббәте артык көчле иде шул. Озак борын чөеп, масаеп йөрмәде, егет тә үз дигәненә иреште – отты.

“Шул көннән соң да хәйран сулар агып, хәйран вакыт узган икән”, дип төгәлләде Хафизә уйларын. Уйланырга ярата иде ул. Бу аның хоббие иде. Күңелле уйлар аны елмайта, ә тискәреләре йөзен сагышка мана иде.

Юл буе кеше язмышы турында уйланып килде кыз. Ничек тә этисе турындагы уйлардан арынырга теләсә дә, елмаю күренмәде яшь кызның йөзендә. Алар аны кайда да эзәрлекли, шәүлә кебек береккән иде.Бары 5 дәресне көч-хәл утырып чыгып, сөеклесе белән күрешкәннән соң гына, бераз рәткә килеп, елмайганда гына чыга торган ике як бит чокырлары күренде.

– Сөеклем, район күләмендә уздырылган ярышка мине һәм тагын 2 егетне алып, дәресләрдән азат иттеләр. Әйтми киткәнемә үпкәләмә, зинһар?! Гафу ит. Бар да уйламаганда һәм бик тиз килеп чыкты. Үземә дә буген генә хәбәр иттеләр” – дигән сүзләреннән соң да, Хафизәнең йөзеннән елмаюы качмаганны күреп, Нәфис тынычланды, өстеннән авыр йөк төшкәндәй булды.Хафизәнең теге вакыттагы тирән, уйчан карашы, серлелеге егетне уйга салды. Тынлык.

– Сөеклем! Син бит беркайчан да миңа авыр сүз әйтеп, кул кутәрмәячәксең?

Нәфис әлеге сорауның нигә бирелгәненә аптырап, беравык коелып төште, “син ни сөйлисең?”, дигән караш ташлады.

– Юк, әлбәттә, кадерлем!

– Ә ташлап китмәячәксеңме?

– Юк! Юк! Бердәнберем минем! Юләркәем! Нигә шундый сораулар биреп, башымны катырасың? Кабат шул очсыз-кырыйсыз уйлар, кабат шул хисләр дөньясымы? – дип, каты итеп кочты егет сөйгән ярын һәм маңгаеннан үбеп алды. Кызның кысып йомылган күзләреннән бер-бер артлы ике күз яше атылды. Ун көн уйларга бирелеп йөрүнең нәтиҗәсе иде бу. Күңел халәте, йөрәк сыкравы, җан ачысы...

Хафизәнең шушы күз яшьләре, 70 ел узып, 86 яшь тулган карчыкның күзләренә күчте. Ничек тырышсаң да, артыгын тартып алып та булмый иде шул инде. Еларлык күз яше калмаган иде Хафизә әбинең. Тормыш аны туп урынына типкәләп, камыр урынына изгәләде, сагыш, кайгы дигәннәрен бәйләм-бәйләм, олау-олау биреп, һәрдаим хәсрәт юллап торды. Тик нигә? Ни өчен бар да Хафизәгә? Кай җирдә абынды? Кайда хаталанды ул? Нигә язмыш бәхетне кешегә тигез итеп бирми, Ходам?

Ниһаять, ике тамчы күз яше Хафизә әбинең җыерчыклы битеннән авыр һәм озак юл үтеп, фотосурәт дәфтәренә тамды. Ул җыерчыклар карчык узган тормыш юлының никадәр катлаулы һәм сикәлтәле булуын күрсәтә иде. Тик сыгылмады ул, нык торды, алга үрмәләде.

Менә аларның Нәфис белән өйләнешкән көнне төшкән сүрәтләре. Бәхет тулы караш, елмаю, шатлык аларның йөзендә. Хафизә ап-ак күлмәктән сөйгәне кочагында. "Гомер буе янәшәңдә булырмын, суыктан, салкыннан саклармын", дип сүз биргән иде дә ләбаса Нәфис ул көнне. Тик бик иртә ташлап китте үзенең Хафизәсен, яшьли гүр иясе булды. Менә бүген кышкы, буранлы, салкын кичтә Хафизә ап-ак яулык һәм ап-ак күлмәктә япа-ялгызы туңып утыра. Янәшәсендә бары шушы истәлек тулы фотоальбом, узган тормышы.

Ә менә монысы әнкәсе белән төшкән фотосурәт. Коеп куйган әнисе инде. Ирен өстендәге миңенә хәтле кызганмаган, озын чәчләрен, матурлыгын бүләк иткән ул аңа. Хәтта язмышлары да охшаш. Исерек ир, ызгыш, талаш, кул күтәрүләр – бар да шул ук, бар да кабатлана. Тик бүләк итеп калдырырлык бәхетсез язмыш дәвамчысы гына юк. Балалары булмады Нәфис белән Хафизәнең. Була алмады. Шуңадырмы, Нәфис эчкечелек белән бәйләде тормышын. Кичәгесеннән айнып бетә алмас борын, күзен ачуга, баш төзәтү иде бар уе.

Беләсеңме, Ходам?! Сокланам мин үз язмышына каршы торып, аның белән суккалаша алырдай көч табып, батырларча һөҗүм иткән кешеләргә! Андыйлар хәзер бармы икән ул? Аздыр, мөгаен. Һәр туган вак проблемага да бирешеп, ниндидер бер төпсез коега эләккән шикелле, төшенкелеккә бирелеп, чыгу җаен үлемдә табучылар күбрәктер. Ә Хафизә, башта йөрәк өянәге белән үлеп киткән әнисен, кабат, җәберләп яшәвенә карамастан, сөекле Нәфисен кара туфрак asларына салганда, ниләр уйлаган, нәрсә кичергән икән? Анда да бәхетле хатын, бәхетле ана булу теләге яшәгәндә, ни өчен ул шушындый аяусыз язмышка дучар булган? Фотоальбомның әле чиста битләрендә Хафизәнең ире һәм балалары белән төшкән гаилә фотосына урын табылмадымыни соң? Язмыш кадәр язмыш белән көч сынаша алырлык кеше ник хәмергә каршы тора алмаган?

Һәр иртә Хафизәнең күзләрен чагылдырган кояш бүген тәрәзә каршында кирәгеннән дә артыграк тоткарланды, әмма чиста бите ачык фотосурәт дәфтәрен күкрәгенә куйган карчык инде башка күзләрен ачмады...

**ЭЧТӘЛЕК**

1. Айдашев Камил, (Алабуга шәһәре). Яхшы сабак.................................................. 3
2. Аиткулова Фәридә, (Нурлат шәһәре). Мин ишетәм синең адымың..................... 4
3. Алыбаева Даткаем, ( Б.Н. Ельцин исемендәге Кыргыз Рәсәй Славян университеты студенты, Бишкек). Иссык-Күл турында риваять................................................. 4
4. Анисин Иван, ( “Советлар Союзы герое генерал-полковник Василий Николай улы Гордов исемендәге Минзәлә кадет мәктәп-интернаты).. Минем шаян песием.; Хәерле иртә телим. ; Татар теле- туган телем.; Кыш айлары................................................................ 5
5. Ахкамеев Тимерлан, (Әлмәт шәһәре). Алабугам................................................ 7
6. Әбүзәрова Гөлүзә, (КФУның Алабуга институты). Туган ягым.; Бәхет.......... 7
7. Әбүзарова Илүзә, (КФУның Алабуга институты). Гомер агышы.; Бәхет эзләп...................................................................................................................... 8
8. Әхмәдишина Алина, (БДУның Стәрлетамак филиалы). Ак һәм кара.; Укытучы турында шигырь.; Син.: Туган җирем. ............................................................................ 9
9. Әхмәдуллина Ләйсән, (Чирмешән районы Иске Кади авылы). Сагышлы яз....10
10. Әхмәтова Әдилә, (Норлат районы Киекле авылы). Нур таралсын Бөек Киеклемә............................................................................................................... 12
11. Әхмәтова Гөлгенә (Алабуга районы Иске Юраш авылы). Бер утырып уйлар уйладым................................................................................................................ 12
12. Әюпова Регина, (БДУның Стәрлетамак филиалы) . Мин яратам сине, татар телем!; Сәнгать, әдәбият, мәдәният....; 9 май – Җиңү көне!.......................................................14
13. Большакова Вероника, (Яр Чаллы шәһәре). Ишеттеңме мине?/ Have yju heard me?; Койма янында/ At the fence……………………………………………………………16
14. Буланова Анастасия, (Түбән Кама районы Югары Чаллы авылы). Нәрсә бик кирәк?.................................................................................................................... 17
15. Васильева Регина, (Мамадыш шәһәре политехник көллияте). Әни..; Яшьлек. ......18
16. Вахитова Әлфиназ, (Әлмәт дәүләт нефть институты). Туган авылым (Фәрдия әбием истәлегенә)...........................................................................................................19
17. Вәгыйзова Гүзәл, (Алабуга шәһәре). Әниемнең “Дәү әти”се. ( Бөек Ватан сугышы ветераны, бабамның бертуган абыйсы Кәшбиев Валихан Кәшбелгаян улының якты истәлегенә багышлыйм )...........................................................................................21
18. Вәлеева Лиана, (Алексеевск районы Чишмә авылы). Үзең нәтиҗә яса балам!...... 22
19. Вәлиева Рузилә, (Норлат шәһәре). Туган телем............................................... 23
20. Вәлиева Чулпан , (КФУның Алабуга институты). Вакытында бир син үгетне..... 23
21. Вәлишина Алсу, (КФУның Алабуга институты). Әдип.................................... 23
22. Вәлишина Алсу, (КФУның Алабуга институты). Апама....................................24
23. Габделхаков Илнур, ( Алабуга шәһәре). Безнең яклауга мохтаҗ...................... 24
24. Габидуллина Алсу, (Мамадыш районы Түбән Сон). Яратабыз без аны (Габдулла Тукайга багышлана).; Туган авылым.; Дәү әбием кәҗәсе.......................................24
25. Габтенурова Гөлназ, (Алабуга шәһәре ). Игезәк малайлар язмышы................. 25
26. Гайнетдинова Алисә, (Алабуга шәһәре). Онытырга моны ярамый!; Тукай абый.....................................................................................................................26
27. Гайнуллина Айгөл, (КФУның Алабуга институты ). Көттермәскә иде әнкәйләрне.... (хикәя)...............................................................................................27
28. Гайнуллина Гөлия, (Алабуга районы Иске Юраш авылы). Һәйкәл куяр идем....... 28
29. Галәветдинова Диләрә, (КФУның Алабуга институты). Меломан................... 30
30. Галеев Риназ, (Алабуга районы Олы Шүрнәк авылы). Каракошның йөзәргә өйрәнү вакыйгасы.;Тыйнак кара икмәк һәм һавалы ак күмәч (әкият).......................................31
31. Галиәкбәрова Эльвина, (Бөгелмә шәһәре). Чыршыларым................................ 32

32. Галимова Лилия, (Башкортостан Республикасы, Бакалы районы, Камышлытамак авылы). Тылсымлы кыз (зурлар өчен әкият)................................................ 33
33. Галләмова Айгизә, (Актаныш авылы). Әллә язмыш, әллә ялгыш..................... 34
34. Галләмова Диана, (Алабуга шәһәре). Тормыш сабагы...................................... 36
35. Галләмова Эльвина, (Башкортстан республикасы Дүртөйле районы Иванай авылы). Туган җирем – газиз ягым………………………………………………… 37
36. Гараев Алмаз, (Алабуга шәһәре). Төнбоек; Саксызлык бәласе (әкият)............ 38
37. Гарипова Элина, (Әлмәт шәһәре). Урман кызы (әкият)................................. 39
38. Гарифуллина Алинә, (Казан шәһәре). Ядкярләрдә Тукай рухы........................ 39
39. Гарифуллина Алия, (Әлмәт шәһәре). Тиздән яз килер; Җәй җитәр.................. 41
40. Гарифуллина Лия, ( КФУ ның Алабуга институты). Бабам истәлекләре (хикәя)...41
41. Гарифуллина Лия, (КФУның Алабуга институты). Авыл баласы мин.; Сагыну.; Абыема.........................................................................................................43
42. Гафурова Гөлия, (Чирмешән районы). Исхакый эзләре буйлап....; “Сөннәтче бабай” әсәрен укыгач.......................................................................................... 45
43. Гаффарова Алсу, (КФУның Алабуга институты). Минем гүзәл шәһәрем (шигырь) ........................................................................................................... 46
44. Гәрәева Алинә, (КФУның Алабуга институты). Ана (шигырь)....................... 47
45. Герасимова Клара, (Норлат районы Урта Камышлы авылы). Укытучыма!..... 47
46. Гильманова Фәридә, (БДУның Стәрлетамак филиалы). Язмыш сынауларын үткәндә (очерк)................................................................................................... 48
47. Гильфанова Сөмбел, (Зәй районы Түбән Биш авылы). Минем туган авылым..... 50
48. Гиниятуллина Рания, (Чистай районы Татар Талкышы авылы). Иртә язда гомер көзе.......................................................................................................................... 51
49. Гомәрова Алисә, (Алабуга районы Иске Юраш авылы). Дуслык; Тәртипсез малай (әкият)...............................................................................................53
50. Гыйльфанова Регина, (Мөслим районы Салавыз-Мухан авылы). Каз бәбкәсе чирәмдә; Яңа елданниләр көтәм мин?; Кышкы матурлык................................... 56
51. Дәүләтшин Самат, (БДУның Стәрлетамак филиалы). Балачак хәтирәләре: Әбием. Көчек. Көз............................................................................................... 57
52. Девятых Анжела, (Алабуга шәһәре). Бай ничек бәхетле булган? (әкият).........59
53. Евдокимова Алёна, (Мамадыш районы Шәдче авылы). Һәркемнең үз байлыгы; Мине көзләр бүләк иткән.................................................................... 60
54. Егорова Екатерина, (Әлмәт шәһәре). Җиңү көне............................................... 62
55. Ермакова Анастасия, (Алабуга шәһәре). Син кирәк булдың миңа., Әбием....... 62
56. Җаббарова Илнара, (Алексеевск эшчеләр бистәсе). Соңга калмагыз................63
57. Җәләлова Алия, (Алабуга шәһәре). Ерак сугыш җилләре.................................65
58. Закирова Зөһрә, (Казан шәһәре). Һәр нәрсәнең җае бар (әкият)........................66
59. Закирова Эльвина, (Яр Чаллы). Вакыт кадере (шигырь)....................................66
60. Закирянова Рушания, (Яр Чаллы шәһәре «Яр Чаллы педагогия көллияте» ). Сөюләрең булсын ихлас синең. ........................................................................... 67
61. Захарова Ольга, (Мамадыш шәһәре политехник көллияте). Туган авыл. Укытучы апа........................................................................................................ 67
62. Заһидуллина Айгөл, (Мөслим районы Түбән Табын авылы). Бабамның батырлыгы. ; Спорт – сәламәтлек, спорт – уңыш...............................................68
63. Зәитов Айрат, (Пермь крае Барда районы Каенавыл авылы). Нинди гүзәл син, туган як......................................................................................................................69
64. Зиатдинов Булат, (Яр Чаллы шәһәре). Очу теләге.............................................70
65. Зиннәтуллина Эльнара, (Башкортстанның Илеш районы Югары Яркәй авылы). Язмышлардан узмыш юк......................................................................................71

66. Ибраhимова Алсу, (КФУның Алабуга институты). Син бит мине үзең эзләп таптың... .......... 74
67. Идрисова Гүзәл, (КФУның Алабуга институты). Сагыну хисе.......... 74
68. Имамиева Айсылу, (КФУның Алабуга институты). Туган тел.......... 75
69. Исхакова Рәзилә, ( Әлмәт политехника техникумы). Сагынсаң учларыңны битеңә куй.; Китмәс идем...; Нәрсә соң ул бәхет?; Әтием.; Яшьлек еллары..........75
70. Кавиева Глюсә, (Алабуга шәһәре). Эх, бу дөньа каба таба бара? ..........77
71. Кадирова.Г.Ф. (Әлмәт шәһәре). Әнием.; Чын кеше (Укытучым Кадрия Ринатовнага багышлана).......... 77
72. Калимуллина Роза, (Алабуга шәһәре). Шук Әмир (әкият)..........78
73. Камашев Марат, (Минзәлә кадет интернат мәктәбе). Кечкенә мәҗара (әкият)..... 79
74. Кариев Альгиз, (Пермь крае, Барда районы Сараш авылы). Сараш авылы тарихында эз калдырган Сәгыйть Сүнчәләй..........80
75. Кашапова Зилә, (Башкортостан Республикасы Салават районы Нәсибаш авылы). Герой абыем..........82
76. Киямова Элиза, (Б ДУның Стәрлетамак филиалы). Утә еллар, кала хәтер…...83
77. Кузнецова Валерия, (Мамадыш районы Җөри авылы). Тормыш сынаулары....84
78. Куляева Марианна, (Түбән Кама районы Югары Чаллы авылы). Кышкы манзара..........85
79. Мазгутова Ләлә, (Чистай районы Татар Талкышы авылы). Шигърият күгендәге йолдыз.......... 86
80. Мандрейкина Олеся, (Норлат районы Егоркино авылы). Кышкы хозурлык....86
81. Маркова Ольга, (Алабуга шәһәре). Әниемнең кызы юк бит.......... 87
82. Марьина Дарина, (Алексеевский районы Биләр авылы). Рәнжетмик, Жир-Ананы!; Мин-Тынычлык илчесе!..........87
83. Мәрданшина Ләйсән, (КФУның Алабуга институты). XIX гасырга сәяхәт.....88
84. Мингалимова Эльвина, (КФУның Алабуга институты). Дисбе (хикәя).......... 90
85. Мингалимова Эльвина, (КФУның Алабуга институты). Саташкан җаннар.; Көнләшү.; Югалту.; Хисләнү.; Син җитмисең. ..........92
86. Минехәерова Айгөл, (Әлмәт шәһәре). Ялгыз картлык нинди була? .......... 94
87. Мирзаһитова Гөлдания, (КФУның Алабуга институты). Ялгыз тормыш ачысы...95
88. Мирсалихов Нәргиз, (Мөслим районы Мари Бүләр авылы). Әтиемнең бахбайлары.......... 95
89. Мирсияпов Илгиз, (Чистай районы Татар Талкышы авылы). Тукайга....; Өзгәләнеп әрни үзәгем.... ..........96
90. Мифтахова Альбина, (Әлмәт районы Яңа Кәшер авылы). Куанып яшик.........97
91. Мөбәрәкшина Фирдинә, ( КФУның Алабуга институты). Күңелемдә шатлык көлә.......... 97
92. Мөбәрәкшина Чулпан, (Мамадыш районы Көмеш Күл авылы). Ачы үкенү..........98
93. Мөслихова Айгөл, ( Алабуга шәһәре). Күрдегезме әле бүген, дуслар?.......... 100
94. Мөхәммәтҗанова Илзирә, (Мамадыш районы Урта Кирмән авылы). Һәрчак сабый булып каласы.; Кем?.......... 100
95. Мөхлисова Таңсылу, (Мамадыш районы Урта Кирмән авылы). Сагындым, авылым. Алмагачлы яз.; Әгәр кош булсам мин.; Кыш.. ; Кар бөртекләре. ..........101
96. Мурзина Айгөл, (Зәй районы Чыбыклы авылы). Укытучым.......... 103
97. Нәҗипова Әлфия, (КФУның Алабуга институты). Әби.; Әниемнең туган көне.; Кая бара дөнья?.......... 104
98. Нәҗипова Диләрә, (Алабуга шәһәре). Әнкәй назы. ; Кыш.......... 105
99. Нигъмәтҗанова Алинә, (КФУның Алабуга институты). Тукайга..........106
100. Низаметдинова Линара, (Норлат шәһәре). Әнием.; Мәктәбем ..........107

101. Нуриәхмәтова Алинә, (Актаныш авылы) Тукай абыйга.; Һәйкәл.....................107
102. Нуриева Элиза, (Бөгелмә шәһәре). Табигать киләчәге – кешелек киләчәге......108
103. Оразов Ораз, (КФУның Алабуга институты). Türkmen talyby/ Төркмән студенты……………………………………………………………………………………..110
104. Осипов Вадим, (Алабуга шәһәре). Өч кыз (әкият)........................................... 111
105. Платонова Диана, (Биектау районы Бөреле авылы). Татар телен хөрмәт ит, сакла һәм үстер!............................................................................................................... 112
106. Прокопьев Артём, (Алабуга шәһәре). Дуслык – зур байлык........................... 114
107. Рахимьянов Рамазан, (Әлмәт шәһәре). Бабам юлы.; Тукай – шагыйрь........... 115
108. Ризванов Данил, (Әлмәт шәһәр, «Әлмәт һөнәри көллияте”). Солдат кабере...116
109. Садыйкова Сөмбелә, (Мамадыш районы Түбән Сон авылы). Бәхет. ............. 116
110. Саматова Чулпан, (Бөгелмә шәһәре). Ана бәхете............................................ 117
111. Сафетдинов Илназ, (Актаныш районы, Аккүз авылы). Кайтып килешем....... 118
112. Сафина Венера, (Бөгелмә шәһәре). Мәхәббәт яры.......................................... 119
113. Сәетгәрәева Резеда, (КФУның Алабуга институты). Хыял диңгезе................ 119
114. Сәитов Вилдан, (Норлат районы Чулпан авылы). Кайту................................. 120
115. Сәйфетдинова Ләйсән, (Норлат районы Якушка авылы), Умырзаяның дуслары (әкият)................................................................................................................. 123
116. Сәлимҗанова Лилия, (КФУның Алабуга институты). Ялгыз маяк.; Мин башканы ярата алмам.; Сиңа.; Сабырлык.; Сине күргәч...; Үзәкләр өзелгәндә.................... 123
117. Сәфиуллина Луиза, (Әлмәт шәһәре). Кар бөртеге турында әкият.................... 126
118. Сибгатуллина Лилия, (КФУның Алабуга институты). Уеннан уймак............. 127
119. Сибгатуллина Нәзилә, (Яр Чаллы шәһәр, «Яр Чаллы педагогия көллияте»). Ил каһарманы................................................................................................................. 128
120. Степанова Анастасия, (Алексеевск районы Чишмә авылы). Югалган кошчыгым минем! ........................................................................................................................ 129
121. Тимербулатова Розалина, (БДУның Стәрлетамак филиалы). Иң зур хәзинәм – туган телем…………………………………………………………………………… 130
122. Трофимова Сафия, (Алабуга шәһәре). Сез үзеге шундый олы җанлы!.......... 130
123. Фазылҗанова Диана, (Биектау районы Бөреле авылы). Мәңгелек сер............ 131
124. Фатыйхова Илзия, (КФУның Алабуга институты). Очрашырбыз әле.............133
125. Фатыйхова Таңсылу, (Алабуга шәһәре). Әбием бәлеше.................................. 134
126. Фатыхова Лиана, (Тукай районы, Кече Шилнә авылы). Дөнья җае.; Олы юлга басабыз........................................................................................................................ 135
127. Фәйзуллина Регина, (Зәй районы). Соңлап килгән бәхет...................................135
128. Фәрдиев Инсаф, (Алабуга шәһәре). Төлке белән куян (әкият).........................136
129. Фәрҗиева Илүзә, (Әлмәт шәһәре Әлмәт политехника техникумы). Ак болытлар.; Дуслык кадере.; Әнием йолдызым.; Сагыну. ......................................................... 136
130. Фәрхетдинова Гөлназ, (Алабуга шәһәре). Тылсымлы чәчәк (әкият)............. 140
131. Филипова Юлия, (Мөслим районы Яңа Усы авылы). Туган тел.; Туган җирдә мин бик бәхетле!.......................................................................................................... 141
132. Хадиева Алия, (Алабуга шәһәре). Нигә?; Урамда яз......................................... 142
133. Хамидов Лазиз (Башкортостан Республикасы Салават районының Нәсибаш) Төшемдә күргәннәр.... ................................................................................................ 142
134. Хафизова Регина, (Әлмәт шәһәре). Тормыш, буран, кеше. ............................ 145
135. Хәлиуллин Адел, (Әлмәт шәһәре). Җәннәт – әниләрнең аяк астында............. 146
136. Хәмәдишина Алсу, (Мөслим районы Баек авылы). Күңел дәфтәреннән.; Кыш.; Февраль.; Күңел........................................................................................................... 147
137. Хәсаншин Айназ, (Чирмешән районы Иске Кади авылы). Хыялларым минем канатлы.........................................................................................................................148

138. Хөсәенова Гөлназ, (Алабуга шәһәре). Зирәк песи баласы (әкият).....................149
139. Хөсәинова Камилә, (Әлмәт шәһәре). Фикерләр дөньясы.................................149
140. Хөснетдинова Клара, (Башкортостан Республикасы Бакалы районы Камышлытамак авылы). Озын толымлы кызлар.... ..................................................................150
141. Цыплина Ангелина, (Бөгелмә шәһәре). Хисләр ташкыны............................... 154
142. Шакирова Гөлфинә, (КФУның Алабуга институты). Җыр – шатлыктан, җыр – кайгыдан......................................................................................................................154
143. Шакирова Мәдинә, (Мөслим районы Баек авылы). Мин - авыл баласы........ 156
144. Шәйхулова Алсу, (Әлмәт районы Яңа Кәшер). Кояш, һава һәм су (әкият).....157
145. Шәкурова Гөлназ, (КФУның Алабуга институты). Сәгыйтьнең уйланулары......159
146. Шәрипова Алинә, (Алабуга районы Иске Юраш авылы). Сабак алу............ 161
147. Шәрипова Гөлүсә, (БДУның Стәрлетамак филиалы). Бәхет.; Туган ягым.; Шигырь язам..................................................................................................................... 163
148. Шәяхмәтова Миләүшә, (Мөслим районы Салавыз-Мухан авылы) Тукай!.; Бәйрәм җитсә...; Кошлар кайта туган ягыма.; Муса Җәлил – минем героем!....................... 165
149. Шигаепова Алинә, (Мөслим районы Салавыз-Мухан авылы) Горур шагыйрь – Муса Җәлил!, Каз бәбкәсе...; Укытучыма!.................................................................... 166
150. Шикаева Мария, (Норлат шәһәре). Тимурга нәрсә булган?; Төлкене дуслык җиңгән (әкият)................................................................................................................ 167
151. Якупова Диләрә, (Алабуга шәһәре). Безнең туган телебез..............................170
152. Якупова Ләйсән, (Казан шәһәре). Охшаш язмыш........................................... 170

**КАУРЫЙ КАЛӘМ:**
*Студентларның һәм укучыларның Бөтенрәсәй (халыкара катнашу белән) иҗади эшләр конкурсы материаллары*. – Алабуга: 2017. – 180 б.

20 март 2017 ел. Формат 60х90 1/16

Тираж 300 экз. Заказ № 135